**БУ САНДА**


БАШ РЕДАКТОР СҮЗЕ........................................................................................ 5

ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Ибраһимов Т.И., Сәйхунов М.Р.* Татар теле, татарлар һәм ассимиляция күренеше........................................................................................ 6

*Сафина Э.И.* Кешеләрне сыйфатлаучы орнитоним компонентлы фразеологик берәмлекләр........................................................................................ 15

*Вәлиева Л.Г.* Төрки телләрнең синтаксик берәмлекләре арасында пространство мөнәсәбәте........................................................................................ 20

*Гайнетдинова Г.Р.* Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» язма истәлегенең исем сүз төркеменә тарихи-лингвистик анализ («Лут пәйгамбәр кыйссасы» мисалында)........................................ 24

*Мирхәев Р.Ф.* Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә матур әдәбият һәм публицистик катламнар нисбәте........................ 28

*Мөхәммәтшин Ф.М.* Хәзерге татар вакытлы матбугатының тел үзенчәлекләре........................................................................................ 33

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Мусабәкова Р.Р.* Г. Тукай әсәрләренең рус теленә тәрҗемәләре (шигырь исемнәрен тәрҗемә итү аспекты)........................................ 36

*Хәсәнова Ф.Ф.* Равил Фәйзуллин шигырьләрен тәрҗемә итү үзенчәлекләре........................................................................................ 41

*Харрасова Р.Ф.* Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» фаҗигасе................. 48

*Червинский Гжегож.* Бүгенге Польша татарлары әдәбияты проблемалары хакында........................................................................................ 54

ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* XIX йөз татар әдәбияты һәм китаби дастаннар: тарихи янәшәлек........................................................................................ 69

*Дәүләтшина Л.Х.* Казан арты татарларында йорт-каралты тирәсендәге рух-ияләр........................................................................................ 74

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Заһидуллин И.К.* Мөселманнарның хокукларын киңәйтү турында Казан сәүдәгәрләренең 1879 елгы «программасы»............. 83

*Сәлахова Э.К.* Казанның Болгарга мөнәсәбәте.................................. 91

## ТӨГӘЛ ФӘННӘР

*Миңнаҗев М.Н., Миңнаҗев Б.М., Кыямова А.Г.* Татарстан геологик структураларының нефть бирүчәнлеге һәм җир кабыгының яңа геодинамикасы арасындагы бәйләнеш.................. 103

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Бустанов Ә.К.* Татар археографы Альберт Фәтхинең шәхси архивы.......................................................................................... 112

## ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Әхмәтҗанов М.И.* Татар әдәбиятында Алтын Урда поэзиясен фәнни нигездә тикшерүнең беренче тәҗрибәсе.............................. 127

*Шәрәф Г.* Беренче буын (иҗектәге) «о», «ө» авазларының үзеннән соңгы авазларга тәэсире һәм бу тәэсирне язуда күрсәтү-күрсәтмәү мәсьәләсе ........................................................... 141

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Әхтәмова А.В.* Педагогик тикшеренү үзәкләре (1960–1970 еллар)... 148

## ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Шкляева Л.М.* Самара өлкәсе татарлары авыл төзелешендә тәрәзә йөзлекләрен традицион орнаментлар белән бизәү (2014 елгы экспедиция материаллары буенча)................................ 153

## СӘНГАТЬ

*Москвина А.Р.* Татарстанда монументаль сынлы сәнгать үсешенең бүгенге тенденцияләре.................................................... 159

*Фәрдиева Д.Р.* «Инсаният» труппасының эшчәнлеге.................... 164

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Б. Корганбеков. «Шора батыр»: нөсхәләре, генезисы, тарихилыгы» ................................................. 167

*Галимҗанова Э.М.* З.З. Рәмиев. Әдәбиятчы-текстолог язмалары.. 172

*Әхмәтҗанов М.И.* Религиозный синкретизм и традиционная обрядность татар-кряшен Волго-Уралья (XIX – начало XX в.)...... 174

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## БАШ РЕДАКТОР СҮЗЕ

Татарстан Фәннәр академиясенең «Фәнни Татарстан» журналы редакциясе Россиядәге Әдәбият елы уңаеннан яшь галимнәрнең фәнни мәкаләләренә ачык конкурс игълан итә.

Бу бәйгенең максаты – яшьләрнең милли әдәбият белән кызыксынуын көчәйтү, иҗади активлыгын, яңалыкка омтылышларын арттыру, аларның фән дөньясында уңышка ирешүләренә ярдәм итү. Без сездә гадәти ярышта катнашучыларны гына түгел, булачак хезмәттәшләрне дә күрергә телибез.

Конкурста татар әдәбияты тарихын өйрәнү, текстология һәм чыганаклар гыйлеме, халык иҗаты, бүгенге әдәби тормыш һәм аның мәсьәләләре турында хезмәтләре белән 35 яшькә кадәр булган әдәбият, тел, тарих һәм башка төрле фән белгечләре, укытучылар, аспирантлар һәм төрле югары уку йортлары студентлары катнаша ала. Фәнни эшләргә куела торган гомуми таләпләргә җавап бирүче, тематикасы туры килгән, яңалыгы, актуальлеге белән аерылып торган тикшеренү эшләре (мәкаләләр) журналда дөнья күрәчәк.

Конкурска йомгак «Фәнни Татарстан»ның быелгы 4 нче саны басылып чыкканнан соң ясала.

Махсус жюрины «Фәнни Татарстан» журналының идарә рәисе, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, ТФАнең мөхбир әгъзасы профессор К.М. Миңнуллин җитәкли. Конкурс комиссиясе эшендә танылган галимнәр, югары уку йортлары укытучылары, язучылар катнашачак.

Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ел йомгакларына багышланган җыелышында булачак.

Мәкаләләрне «конкурска» дигән тамга белән «Фәнни Татарстан» журналы редакциясенә 1 ноябрьгә кадәр электрон почта аша җибәрергә кирәк: f_tatarstan@mail.ru. Аларның электрон версиясе белән журналның сайтында танышырга мөмкин булачак: fenni-tatarstan.ru Элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-76-59.

УДК 811.512.145

*Т.И. Ибраһимов, М.Р. Сәйхунов*

# ТАТАР ТЕЛЕ, ТАТАРЛАР ҺӘМ АССИМИЛЯЦИЯ КҮРЕНЕШЕ

Работа посвящена исследованию состояния татарского языка и ассимиляции языковой общности в советский период. На основе данных переписей населения 1979 и 1989 гг. анализируются изменения в численности носителей татарского языка, с психолингвистической и этнопсихологической позиций обсуждается явление перехода этнической общности на другой язык (языковой сдвиг).

**Ключевые слова:** татарский язык, этнос, этноопределители, народонаселение, перепись населения, этническое сознание, самосознание.

Татарлар – Россиядә таркалып яшәүче халыкларның берсе. Халыклар санын алу нәтиҗәләренә караганда, бүген татарлар Россиянең барлык өлкәләрендә һәм шулай ук БДБ илләренең һәркайсында диярлек тормыш итәләр. Күпләре инде җирле халыкның телен, гореф-гадәтләрен, көнкүреш тәртибен кабул иткәннәр. Мәктәпләре рус телендә укутуга күчерелгән. 1–2 нче таблицаларда китерелгән мәгълүматлар [Национальный...] югарыда әйтелгәннәрнең мисалы булып торалар.

*Таблица 1*

<table>
<tr><td rowspan="3">Татарлар яшәгән кайбер төбәкләр</td><td colspan="2" rowspan="2">Төбәкләрдә яшәүче татарларның саны</td><td colspan="2">1979 ел халык санын алу нәтиҗәләре</td><td colspan="2">1989 ел халык санын алу нәтиҗәләре</td></tr>
<tr><td colspan="2">Туган тел</td><td colspan="2">Туган тел</td></tr>
<tr><td>1979 ел</td><td>1989 ел</td><td>татар теле</td><td>башка тел</td><td>татар теле</td><td>башка тел</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Архангельск өлкәсе</td><td rowspan="2">4906</td><td rowspan="2">5391</td><td rowspan="2">2612</td><td>2294</td><td rowspan="2">2756</td><td>2635</td></tr>
<tr><td>46,76%</td><td>48,88%</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Ленинград өлкәсе</td><td rowspan="2">6247</td><td rowspan="2">7757</td><td rowspan="2">3430</td><td>2817</td><td rowspan="2">3787</td><td>3970</td></tr>
<tr><td>45,09%</td><td>51,18%</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Мәскәү шәһәре</td><td rowspan="2">132 388</td><td rowspan="2">157 376</td><td rowspan="2">84 982</td><td>47406</td><td rowspan="2">99 097</td><td>58279</td></tr>
<tr><td>35,81%</td><td>37,03%</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Оренбург өлкәсе</td><td rowspan="2">151 383</td><td rowspan="2">158 564</td><td rowspan="2">135 365</td><td>15 462</td><td rowspan="2">136 815</td><td>21 749</td></tr>
<tr><td>10,2%</td><td>13,7%</td></tr>
</table>

Беренче таблицада 1979 һәм 1989 елларда күрсәтелгән өлкәләрдә татарларның күпме булуы, шулардан күпмесенең татар телен ана теле дип санавы, күпмесенең кайсыдыр башка телне (нигездә рус телен) ана теле итеп тануы турында мәгълүматлар китерелгән. Саннардан күренгәнчә, 1989 елда бу төбәкләрдә яшәүче татарларның якынча яртысы (45%) ана телен туган тел дип

танымый. Икенче таблицада китерелгән мәълүматларга караганда, чит өлкәләрдә яшәгән татарларның саны үсә (үсеш проценты курсив белән язылган юлларда китерелә). Архангелск өлкәсендә ул – 9%, Ленинград өлкәсендә – 19,5%, Мәскәүдә – 16%, Оренбург өлкәсендә 4,5 % тәшкил итә.

Татарстан җирлегендә шушы еллардагы үсеш 7%. Димәк, бу елларда БДБ илләреннән күчеп киткән татарлар Татарстанга түгел, ә күбрәк башка төбәкләргә кайтканнар. Кызганыч ки: Татарстан милли мәдәният, милли мәгърифәт үзәге буларак татарларны үзенә тарта, дип әйтеп булмый.

*Таблица 2*

| Татарлар яшәгән кайбер төбәкләр | Төбәкләрдә яшәүче татарларның саны | | 1979 ел халык санын алу нәтиҗәләре | | 1989 ел халык санын алу нәтиҗәләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Туган тел | | Туган тел | |
| | 1979 ел | 1989 ел | татар теле | башка тел | татар теле | башка тел |
| Архангельск өлкәсе | 4906 | 5391 | 2612 | 2294 | 2756 | 2635 |
| *Үсеш* | | *9,00%* | | | *5,22%* | *12,94%* |
| Ленинград өлкәсе | 6247 | 7757 | 3430 | 2817 | 3787 | 3970 |
| *Үсеш* | | *19,47%* | | | *9.43%* | *29,04%* |
| Мәскәү шәһәре | 132 388 | 157 376 | 84 982 | 47406 | 99 097 | 58279 |
| *Үсеш* | | *15,90%* | | | *14.24%* | *18,65%* |
| Оренбург өлкәсе | 151 383 | 158 564 | 135 365 | 15 462 | 136 815 | 21 749 |
| *Үсеш* | | *4,5%* | | | *1,06%* | *33,5%* |

Таблицада күзгә ташланган хакыйкатьләрнең икенчесе – татар этносында үз телен туган тел дип танымау күренешенең тизрәк үсүе. 1979 – 1989 еллар арасында үз телен туган тел итеп таныган татарларның саны 5,22% ка артса, башка телне туган тел итеп тану 12,94% ка үсә. Ленинград өлкәсендә исә ул күренеш 51,18 % ка җитә.

Икенче таблицада чагылыш тапкан тагын бер күренеш – үзен татар дип таныган кешеләрнең саны «туган телем – татар теле» дип таныган кешеләр санынннан сизелерлек дәрәҗәдә күбрәк. Әйтик, Архангельск өлкәсендә татарларның саны 9,0% ка артса, «туган телем – татар теле» дип әйтүчеләрнең саны бары тик 5,22%. Димәк, 3,78% тәшкил иткән татарлар (9,00 – 5, 22 = 3,78) үзләрен (тел белмәгән хәлдә дә) татар дип санныйлар. Ленинград өлкәсендә исә 1979–1989 еллар арасында татарларның саны 19,47% ка үскән. Ә менә шул ук вакыт эчендә татар телен белүчеләрнең саны бары тик 9,43% ка арткан. Шулай булгач 10% чамасы кеше, телне белмәсә дә, үзен татар дип яздырган.

Нәтиҗә бер – кеше үзен тел белүдән чыгып кына аерым

милләт вәкиле итеп танымый. Аны шулай ук демографиягә караган гомуми хисапларда да күрергә мөмкин. Россиядә 1989 елда уздырылган халык санын алу нәтиҗәләре буенча, татарларның саны 6 млн 550 мең, шуларның 1 млн 300 меңе (гомум күләмнең 17% ы) ана теле буларак рус телен күрсәтә [Хакимов]. Күренә ки, якынча 5 татарның берсе, туган телен белмәсә дә, үзен татар итеп күрә.

Татар кешесе милләтеннән түгел, ә беренче чиратта татар теленнән читләшә. Рус телендә сөйләшү сөйләм әгъзалары өчен җиңелрәкме? Башка телләр фикерне тыңлаучыга төгәлрәк җиткерәме? Әллә кайбер тел стильләре татар телендә формалашмый калганмы? Сораулар бу әйтелгәннәр белән генә чикләнми, бәлки аларны тел яссылыгында чишеп тә булмый торгандыр. Шулай да, бабаларыбызның телен яклап, берничә мисал китереп үтәбез.

Татар сөйләм теле, һинд-европа телләре белән чагыштырганда, артикуляцияләү өчен берникадәр җайлырак. Икенче төрле итеп әйткәндә, ул азрак күләмдә энергия сарыф итүче система тәшкил итә. Сүзне әйтеп бетергәнче (ул уртача 5,5 аваздан тора) телнең иң авыр җире – тамыр өлеше – алга-артка күчерелми. Беренче иҗек калын әйтелсә, тел тамыры сүз азагына чаклы арткы (бугаз куышлыгына тартылган) хәлдә; нечкә әйтелсә, сүз азагына чаклы алгы (авыз куышлыгына тартылган) торышта саклана (борабыз, бөрәбез).

Моннан тыш, татар теле ияләренә көч куеп бер иҗектә рәттән килгән ике тартыкны әйтү хаҗәт түгел. Әгәр алар алынма сүзләрдә очрасалар, сөйләүче сүзгә сузык өстәп яңа иҗек булдыра (стол – өстәл, бокс – бокыс). Стол, бокс сүзләрен әйтү өчен басым ясау (өстәмә көч кую) таләп ителсә, *өстәл, бокыс* сүзләрен әйткәндә көч куюның кирәге калмый.

Авазлар әйтелешен өйрәнү фәнендә әйтү өчен иң җиңел буларак «сузык+тартык»тан торган иҗек күрсәтелә (ка, са, мы, те). Бу калыптагы иҗекләр татар телендә 46,5% күләмендә файдаланыла. Боларга өстәп, татар теленең сузыкларга бай булуын һәм, ниһаять, сүз басымының даими булмавын күрсәтергә мөмкин.

Сүзләрне әйтүдә татарча сөйләүчегә: «Кайсы җирдә басым ясыйм икән?» – дип уйланулар хаҗәт түгел. Ул автоматик рәвештә (үпкәсендә һава күп чагында – күкрәк мускуллары киеренке торышта) хәлле генә беренче иҗекне әйтә, бераз сүрелеп икенче иҗеккә күчә һәм берникадәр хәлсез хәлдә, ягъни мускулларның үпкәгә басымы бераз кимегәч, соңгы иҗекне әйтә. Нәкъ менә шушы рәвештә көч сарыф ителү сәбәпле татар телендә иренләшү гармониясе тулы хәлдә күзәтелми. «Болынлык, өстенлек» кебек сүзләрне әйткәндә кеше, ияген өскә күчереп, бер үк вакытта иреннәрен бөрергә кыенсына, аларны киеренкелектән арындырып, нейтраль әйтелештәге ы/е ләрне әйтүгә күчә. Кыскасы, татар теленең авазлар системасы төзек, әгъзалар өчен уңай һәм, энергия саклау аспектыннан чыгып караганда, бәрәкәтле.

Бәлки тегे яки бу төшенчәләрне тыңлаучыларга, йә булмаса укучыларга җиткерү өчен телнең сүзләре (терминнар) җитеп бетми торгандыр. Бу бер дә гаҗәп хәл түгел. Һәрбер тел ул төбәктә яшәгән халыкның мәнфәгатьләренә

мөнәсәбәттә барлыкка килә һәм үсә. Әгәр күрше халыклар мәдәниятеннән тормыш-көнкүреш өчен файдалы корылмалар, фән-техника төшенчәләре алына икән, халык аларга яңа исемнәр куша яки күрше халыклар файдаланган исемнәрне үзләштерә. Телләр, кагыйдә буларак, ата-бабалардан калган тел системасына яраклаштырылган алынма сүзләр хисабына байыйлар.

Әйтергә кирәк, татар теле күп гасырлар буе 20–25 ләп төрки халыклар белән аралашуда, гарәп, фарсы, рус халыклары белән алыш-бирешләрдә шомарган, төзекләнгән, үскән. XI–XII гасырларда әлифбалар булдырып, дөнья мәдәниятен чагылдырган атамалар белән баюга, әдәби стилен төзеп матур әдәбият үрнәкләре иҗат итүгә ирешкән. Бүгенге көндә ул теләсә кайсы тел дөньясын татарча тасвирлауга сәләтле система тәшкил итә. Кыскасы, татар шәхесенең башка телгә тартылуында телебез гаепле түгел.

Югарыда татар телен белмәгән татарларның: «Милләтем татар», – дип яздыруларын күреп үттек. Шулай ук бер телдә сөйләшкән халыкларның үзләрен төрле милләт кешеләре итеп күрүләре дә мәгълүм (Англия – Австралия, Германия – Австрия һ.б.). Әгәр этнолингвистикада тел югалту күренеше «деэтнизация» дип атала икән, димәк, тел алыштыру – ул телне югалту гына түгел, ә тел белән бергә милләтне бар итүче башка сыйфатларның да зәгыйфьләнүе дигән сүз.

Хезмәтебездә «деэтнизация» күренешен өйрәнү түгел, ә телне алыштыруга китерүче сәбәпләрне ачыклау күздә тотыла.

Этнолингвистикада этнос күп төрле билгеләр – этноаергычлар (этноопределители) – системасы буларак өйрәнелә. Билгеләр саны, составы әдәбиятта төрлечә күрсәтелә. Шулар арасында иң мөһимнәре түбәндәгеләр: 1) яшәү төбәге (территория), 2) туган тел, 3) этник үзаң, 4) традицияләр һәм гореф-гадәтләр, 5) рухи мәдәният (моң, халык җырлары, халык биюләре, фольклор), 6) дин, 7) этник аң, 8) эндогамия, 9) профессиональ сәнгать (авторлары булган әдәбият, музыка, җыр, бию), 10) материаль мәдәният (йорт-җир, кием-салым, аш-су) 11) тарих.

Әйтергә кирәк, этноаергычларның берсе дә берүзе генә җәмгыятьне этнос итеп оештыра алмый. Югарыда саналып киткән этник билгеләрнең йә һәммәсе дә, йә күбесе хас булганда гына җәмгыять этнос буларак телгә алынырга, өйрәнелергә мөмкин.

Бәхәс юк, санга кергән этноаергычлар бүгенге татар милләтендә чагылыш тапканнар. Тик менә алар ни хәлдә сакланалар, телебезгә хас күчену (языковой сдвиг [Вайнрайх]) процессы кичермиләрме?

Танылган этнолог А.С. Герд китергән мәгълүматлар буенча, 1992 елда катнаш гаиләләр төзү күләме (эндогамия күренешенең имгәнү дәрәҗәсе) Бөгелмәдә – 28,1%; Алабугада – 34,9%; Лениногорскида – 38,8%; Яр Чаллыда – 33,9%; Казанда 27,8% тәшкил иткән [Герд, с. 27]. Бу саннар, билгеле, эндогамиянең бүгенге хәлен генә түгел, ә бәлки җәмгыятьтә ислам диненең хәлен дә чагылдыра. Шулай ук «этник аң», «этник үзаң» кебек этноаергычларның сау-сәламәт булуында берникадәр шик туа. Әгәр алар җитәрлек дәрәҗәдә халык күңелендә саклансалар, тел алыштыру бүгенге күләмдә күзәтелмәс иде.

Социолингвистикада телнең барлыкка килүе, үзгәреше, кулланыштан чыгуы җәмгыятьнең яшәеш шартларына бәйләнештә өйрәнелә. Сүз юк. Әгәр фәнни җәмәгатьчелек тел сәясәтен өйрәнү, бәяләү мәсьәләләрен күтәреп чыга икән, димәк, социолингвистика фәне хаклы. Шулай да бу очракта без татарның тел алыштыру күренешен тел ияләренең психологиясенә бәйләнештә өйрәнүне мәгъкуль күрдек.

Казан лингвистика мәктәбенә нигез салган дөньякүләм танылган тел галиме Бодуэн де Куртенэ болай дип яза: «Язык существует и изменяется... по законам психическим и социологическим, причем социологию мы отождествляем с так называемою психолгией народов» [Бодуэн де Куртенэ, с. 94]. Күренә ки, галим телнең яшәү һәм үзгәреше өчен тел ияләренә хас психик һәм халыкларга хас психологик закончалыклар җаваплы дип таба.

Түбәндә аерым тел төркемнәрен гәүдәләндергән этносларның холкын чагылдырган тасвирлама китерелә. Тасвирламалар чит ил һәм СССР галимнәре башкарган тикшерү нәтиҗәләре нигезендә төзелгәннәр.

1. Японнарга хас сыйфатлар: эш сөючән (трудолюбый), игътибарлы (осторожный), әзерлекле (организованный), җитди (серьезный), үҗәт (упорный), борчылучан (озабоченный).

2. Инглизләргә хас сыйфатлар: әдәпле (тактичный), тыныч (спокойный), тәнкыйтьчән (критичный), акыллы (умный).

3. Немецларга хас сыйфатлар: эшлекле (практичный), тотнаклы (организованный), эш сөючән (трудолюбивый), инанган (уверенный), нык ышанган (твердый), төгәл һәм үз вакытында үтәүчән (пунктуальный).

4. Русларга хас сыйфатлар: ачык (откровенный), юмарт (щедрый), гамьсез (бесшабашный), ярлыкаучан (прощающий), тынычлык сөючән (миролюбивый).

5. Грузиннарга хас сыйфатлар: ярсулы (возбужденный), импульсив (импульсивный), дәртле (боевитый), дәгъвачыл (претенциозный), агрессив (агрессивный).

6. Татарларга хас сыйфатлар: горур (гордый), үзбелдекле (самоуверенный), тапкыр (сметливый), эш сөючән (трудолюбивый), хәйләкәр (хитрый), тиз кабынучан (вспыльчивый), тиз сүрелүчән (отходчивый). [Платонов, с.193]

Татарга карата төзелгән тасвирлама уңай тәэсир калдыра. Әмма ул тулы түгел. Анда татарларның «Татар барда – хәтәр бар» мәкаленең нигезендә яткан бер-берсеннән шикләнеп яшәве дә, «Татар түрә булса, чабатасын түргә элә» мәкаленең нигезен тәшкил иткән үзен түрә итеп күрсәтергә тырышу сыйфаты да исәпкә кермәгән. Кыскартып әйткәндә, тасвирламада Газиз Гобәйдуллин, Индус Таһиров, Илдус Әмирханов кебек галимнәребезнең хезмәтләрендә ачыну хисләре белән бәян ителгән татарларга хас «көнчелек» һәм «масаючанлык» сыйфатлары урын тапмаган.

Димәк, татар, тасвирламада күрсәтелгән башка сыйфатлардан тыш, «көнчелек» (зависть) һәм «масаючанлык» (заносчивость) сыйфатларына да ия халык.

Шулай булгач, ата-бабаларга хас уңай сыйфатлар хәзерге һәм киләчәк буыннарда ничек тәрбияләнергә мөмкин?

Мәгълүм ки, кеше – иҗтимагый җан иясе. Туган көннән башлап адәм баласы иҗтимагыйлашу (социализация) процессын кичерә. Этнопсихолог Л.Г. Почетбут фикеренчә, иҗтимагыйлашу түбәндәге өч процессның бер-берсенә керешеп кешегә ясаган тәэсире нигезендә башкарыла:

а) җәмгыятьләшү (социумизация) – адәм баласы үз эргәсендәге кешеләргә, аларга хас булган гореф-гадәтләргә, кагыйдәләргә яраклашып, үзен тәрбияләүчеләрнең рухи кыйммәтләрен үзләштереп яшәүгә өйрәнә;

б) этнолашу (этнизация) – үз милләтенең рухи кыйммәтләре, алдагы буыннар туплаган тормыш тәҗрибәсе белән таныша, үзендә шушы милләткә хас сыйфатлар тәрбияли һәм үзен шушы милләт белән тиңләүгә (идентификацияләүгә) ирешә;

в) мәдәниятләшү (культуризация) – башка халыкларга хас гореф-гадәтләр, рухи кыйммәтләр белән таныша, аларның тормыш тәҗрибәсен мәдәниятен үзләштерә, үз милләте белән башка милләтләр арасындагы аермалыкларны таный һәм алар белән аралашу кагыйдәләрен үзләштерә [Бодуэн де Куртенэ, с. 187].

Беренче төр гамәлләр ярдәмендә кеше үзендә аерым бер милләткә хас гадәт, тәртип тәрбияли. Тугандашлык, күршелек, дуслык, якташлык мөнәсәбәтләре белән таныша, аларны үзләштерә. Җәмгыятьнең төрле социаль катламнарга бүленгән булуын, алар белән аралашу кагыйдәләрен ачыклый, кайсы катлам белән нәрсә турында һәм ничек сөйләшү күнекмәләре ала.

Икенче, өченче төр гамәлләр нигезендә шәхес үз халкына хас кыйммәтләр системасы белән таныша, аларны үзләштерү нәтиҗәсендә социаль-мәдәни җәмгыять (җәмгыятьләр) әгъзасы булуга ирешә. Үзен кайсыдыр иҗтимагый төркем яки төркемнәр (социумнар) белән тиңли (идентификацияли). Социаль-мәдәни җәмгыять диндәшләр бердәйлеге дә, якташлар, авыл-дашлар бердәйлеге дә, аерым телдә сөйләшүчеләр бердәйлеге дә, рухи һәм матди мәдәниятләр бердәйлеге дә, аерым бер һөнәр бердәйлеге дә хасил итәргә мөмкин. Шәхес шуларның йә берсе, йә бер үк вакытта берничәсе белән үзен тиңли. Алар белән аралаша, уртак тел табуга ирешә. Күбрәк социаль һәм мәдәни бердәйлекләр белән тиңдәшлек тапса, шулкадәр күбрәк дәрәҗәдә милли рух белән сугарыла, милләт белән тыгыз бәйләнеш булдыра.

Өченче төр, ягъни мәдәниятләшү, гамәлләре нигезендә шәхес башка халыкларның милли кыйммәтләре, гореф-гадәтләре, әхлакый үзенчәлекләре белән таныша, милләтләр арасындагы аермалыкларны күрергә, алар белән аралашырга өйрәнә.

Милләтне, этноаергычларны саклауга кагылышлы төп сыйфатлрның берсе – халыкта, аның аерым вәкилләрендә үзаң, үзхөрмәт тәрбияләү. «Кеше булган кешенең кешедә дә эше булыр» дигән өлкәннәр. Икенче төрле әйткәндә, башта милләттә, аерым шәхесләрдә үзаң (үзенең аң-белем дәрәҗәсен бәяләү), соңрак үз-үзен, милли мәдәният, гореф-гадәтләрне, әхлакны хөрмәт итү сыйфаты тәрбияләнергә тиеш.

Түбәндә Казанга күчеп килгән татар кешесенең тормыш-көнкүреше этнолингвистик планда анализлана. Анализ тулы хакыйкыйлыкка дәгъва итми, бары тик бер юрама булашрак тәкъдим ителә.

*Таблица 3*

| Аралашу теле | Казанга күчеп килгән татарларның яшәү дәвамына бәйле рәвештә тел сайлау күренеше (%) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1–5 ел | 5–10 ел | 10–15 ел | 15–20 ел | 20 ел һәм күбрәк |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Хезмәттәшләр белән аралашуда | | | | | |
| Русча | 22,0 | 47,4 | 36,0 | 20,0 | 33,1 |
| Татарча | 17,8 | 7,15 | 10,0 | 6,9 | 3,25 |
| Татарча-русча | 59,7 | 45,0 | 54,0 | 73,1 | 63,5 |
| Милләттәш дуслар белән аралашуда | | | | | |
| Русча | 13,3 | 23,7 | 14,5 | 21,05 | 18,0 |
| Татарча | 44,5 | 40,3 | 44,0 | 7,2 | 28,3 |
| Татарча-русча | 42,15 | 35,9 | 41,5 | 70,7 | 53,7 |
| Гаиләдә аралашуда | | | | | |
| Русча | 7,2 | 18,5 | 10.0 | 8,6 | 12,4 |
| Татарча | 60,8 | 71,8 | 85,0 | 55,7 | 55,8 |
| Татарча-русча | 18,5 | 8,5 | 5,0 | 31,9 | 30,1 |
| Әдәби китаплар укуда | | | | | |
| Русча | 20,9 | 25,1 | 17,25 | 36,7 | 35,1 |
| Татарча | 21,1 | 18,3 | 27,25 | 27,0 | 17,45 |
| Татарча-русча | 57,25 | 56,6 | 60,6 | 36,35 | 48,05 |

Искәрмә: таблица А.С. Гердның «Введение в этнолингвистику» исемле китабыннан алынды [Герд, с. 28].

Таблицаның икенче һәм өченче баганаларында китерелгән саннардан күренгәнчә, күчеп килгән һәм Казан шартларында 6–10 ел яшәгәннәр эш урыннарында, милләттәш дуслары белән һәм гаиләдәге аралашуларда күченеп 1–5 ел яшәгәннәрдән рус теленнән ике тапкыр күбрәк файдаланалар.

Нинди сәбәпләр аркасында күчеп килгәннәр татарларның милли мәдәният үзәге булган Казанда 5 ел яшәү дәвамында татарча сөйләшүләрен ике тапкырга киметәләр?

Казанга күчеп килүчегә 20 яшь дип фараз кылыйк. Ул белем үстерү, йә булмаса, армиядә хезмәт иткәннән соң эшкә урнашу максаты белән килергә мөмкин. Яшьләргә хас максимализм, дөнья белән якыннан танышу, үзен таныту аны кытыклап тора. Ул урамга ашыга. Әгәр урамда танышларын очратса, ул үзен аларга тиңләр иде. Алар белән чәйханәгә кер-

сә, милләттәшләр бердәйлегенә кушылып китәр иде. Әмма аны Казанда, Үзбәкстан урамнарындагы кебек, тезелеп киткән чәйханәләр дә, 1970 нче елларда кунакларны токмачлы аш белән сыйлаган, кавыштырган, сөйләштергән «Татар ашлары йорты» да чакырып тормый. Ул да – беркемне, аны да беркем белми. Ул – дөнья гражданины, үзен ничек тели, шулай тота. Ул иректе! Әмма аның сөйләшәсе килә. Казан каласының урам теле русча. Аның башка чарасы юк, ул шул телдә сөйләшүчеләргә тартыла. Бер уңайдан ул урам телен генә түгел, урамча сөйләшү формасын да үзләштерә.

Югарыда әйтелгәннәр Л.Г. Почетбут тәкъдим иткән иҗтимагыйлашу формасыннан бераз аерыла, әмма безнең тасвирлама хакыйкатькә якынрак.

Өченче баганадагы саннарны, Казанда 10 ел яшәп, 30 га җиткән татарларга хас күренеш дип карый алабыз. Ул инде үзе кебек шәхесләр бердәйлегенең әгъзасы буларак тамырланган, дөнья гражданины буларак үз тормышыннан канәгать халәттә – эшләп, табып, ашап, эчеп телевизор карап – вакытын уздыра. Бәлки башка милләт кешесе белән тормыш коргандыр, чөнки эшендә, дуслары белән аралашуларда, гаиләсендә ике мәртәбәдән артыграк күләмдә русча сөйләшүгә күчкән (А.С. Герд хезмәтендә Казанда катнаш гаиләләрнең саны 27,8% тәшкил итә), гадәттә русча сөйләшә, русча газеталар укый.

Дүртенче баганадагы саннар чама белән 35 яшькә җиткән шәхесне сыйфатлыйлар: сөйләшендә татарчалык сизелерлек арткан. Күчеп килүченең Казанда яши башлаганда татарча сөйләшү, татар социаль бердәйлегенең әгъзасы булу омтылышын чагылдыра бу саннар (милләттәшләре белән сөйләшүенә игътибар итегез). Аны моңа нәрсә этәргән? Әти-инисенең картаюымы, әби-бабасының вафат булуымы, бала-чагасының тормыш юлы сайлавымы? Ничек кенә булмасын, өченче һәм дүртенче баганадагы саннар аермалыгы очраклы түгел.

Бишенче баганада китерелгән саннар Казан шартларында 40 ел яшәгәннәрне тасвирлыйлар. Бу баганада китерелгән саннарны аңлату кыен. Милләттәшләр белән татарча сөйләшү – алты тапкыр, ә гаиләдә татарча сөйләшү 30% ка кимегән. Бәлки, бу яшьтәге әти-әниләр ул-кызларына туй ясый торганнардыр һәм шул уңай белән, яңа кардәшләр табып, русча сөйләшүгә күчәләрдер. Бу чарасыз ясалган фараз гына.

Икенче баганадагы саннарны алтынчы баганадагылар белән чагыштыру күчеп килүчеләрнең Казан шартларында ана телләреннән читләшүен күрсәтә. Чарасыздан «Казанга күчеп килгән милләттәшләр шәһәрдә этник бердәйлектән читләшәләр» дигән фикер туа. Әйтелгән фикер, мөгаен, хактыр. XX гасырның 90 нчы елларында татарның инсани фәннәр хезмәткәрләре белән техник фән хезмәткәрләре арасында нindидер якынаю булып алган иде, әмма ул уртак бердәйлек табуга китермәде. Бүгенге көндә татар этносы төрле социаль катламнарга, һөнәри, мәдәни, территориаль, туган-тумачалык бердәйлекләренә бүленгән хәлдә көн күрә. Әмма бу күрсәтелгән бердәйлекләрдә аларны

төзүче затларның үзара берләшүе (бер милләт вәкилләре булган очракта да) этник кыйммәтләргә нигезләнмәгән.

Әйтергә кирәк, бүгенге Россиянең милли сәясәте этник берлекләр бердәмлеге төзүгә юл тоткан. Бу сәясәт кысаларында халыкта этник аң һәм этник үзаң тәрбияләү көн тәртибенә куелган мөһим бурычларның берсе булып тора.

## Әдәбият


Национальный состав населения РСФСР. По данным Всесоюзной переписи населения 1989 г. М.: Республиканский информаионно-издательский центр, 1990.

*Хакимов Р.С.* Не привилегии, а защита. Языковая политика в Республике Татарстан. Казань: Магариф, 1999. 342 с.

*Вайнрайх У.* Одноязычие и многоязычие. Зарубежная лингвистика. Т. III. Избранное. М: ПРОГРЕСС, 1999. 350 с.

*Герд А.С.* Введение в этнолингвистику: учеб. пособие. СПб.: С.-Петерб. ун-т: 1995. 91 с.

*Бодуэн де Куртенэ И.А.* Язык и языки. Избранные труды по общему языкознанию. М.: Наука, 1963. Т. 2. 388 с.

*Платонов Ю.П.* Основы этнической психологии: учеб. пособие. СПб.: Речь, 2003. 452 с.



***Ибраһимов Тәүзих Ибраһим улы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты доценты;*
***Сәйхунов Мансур Рәфкать улы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Информатика институты хезмәткәре.*
*e-mail: tatcorpus@gmail.com*

УДК 811.512.145'373

*Э.И. Сафина*

# КЕШЕЛӘРНЕ СЫЙФАТЛАУЧЫ ОРНИТОНИМ КОМПОНЕНТЛЫ ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘР

В статье рассматриваются фразеологизмы татарского языка с компонентом орнитонимом, характеризующие людей. Будучи устойчивыми по составу и структуре, такие фразеологические единицы передают сведения о национальном характере, мировоззрении и культуре народа.

**Ключевые слова:** лексикология, орнитоним, фразеологизм, фразеологические единицы, орнитология, названия птиц, терминология.

Кеше кайда гына яшәсә дә иң элек әйләнә-тирәлегенә игътибар иткән, аны үзенчә аңлатып бирергә тырышкан. Теге яки бу әйберне, кешене, хәтта күренешләрне дә тирә-ягындагы кош-кортлар, хайваннар, предметлар белән чагыштырып, ассоциатив фикер йөртеп бәяләгән.

Телебездә кулланыла торган тотрыклы сүзтезмәләр – фразеологизмнар да, беренче чиратта, гади халыкның көндәлек мәшәкатьләре һәм кызыксынулары белән бәйле. Шуңа, элек-лектән каз, үрдәк, тавык кебек йорт кошлары асраган, карлыгач, сыерчык, сандугачларга карап сокланган, аларны мактаган, зурлаган халыкның фразеологик әйтелмәләрендә кошлар символикасы күп булу гаҗәп түгел. Мондый фразеологизмнар образлылыкка бик бай һәм алар халыкның мәдәнияте, гореф-гадәтләре, йолалары, милли үзаңы, ышанулары хакында сөйлиләр.

Чынбарлыктагы күренешләрне тәэсирле, сурәтле һәм сәнгатьле итеп чагылдыручы бу төр милли байлыгыбызны тел белгечләре дистә еллар дәвамында теркәп килгәннәр. Л. Җәләй, Ш. Рамазанов, Л. Мәхмүтева, Н. Борһанова, К. Сабиров, Г. Ахунҗанов, Х. Курбатов, Г. Әхәтов һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә меңләгән тотрыклы сүзтезмәләр урын алган, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә фразеологик әйтемнәргә шактый киң урын бирелгән. Татар теленең фразеологизмнары Н.Исәнбәт тарафыннан ике томлык фразеологик сүзлеккә тупланган, ә «Русча-татарча фразеологик сүзлек»тә (Ф.С. Сафиуллина), «Татарча-русча идиомалар сүзлеге»ндә (Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова) исә образлы сүзтезмәләр рус теленә тәрҗемәсе белән үк бирелгән. Әлеге мәкаләне язу өчен материал ролен үтәгән орнитоним компонентлы фразеологизмнар Н. Исәнбәтнең ике томлы «Татар теленең фразеологик сүзлеге»нә кертелгән берәмлекләр арасыннан сайлап алынды.

Нәкый Исәнбәт җыйган фразеологик әйтемнәр арасындагы орнитоним компонентлы тотрыклы сүзтезмәләрнең йорт кошлары белән бәйлеләре дә, киек кошларга хас билге-сыйфатларны нигез итеп алганнары да шактый. Йорт кошларын белдергән иң актив орнитонимнар: *тавык, әтәч, каз, үрдәк* булса, йорт тирәсендә еш күренә торган кошлар арасыннан фразеологик әйтем

составында актив кулланыла торганнары дип, *чыпчык, саескан, карга* һ.б.ларны атый алабыз.

Сөйләмнең эчтәлегенә, нинди стильдә язылуына бәйле рәвештә фразеологизмнарның бер төре язма әдәбият, ягъни китап телендә (*асыл кош, кәгазь сандугачы*), ә икенчеләре сөйләү телендә зур урын алган (*аңгыра күке, бүрекле карга, калай әтәч*). Моннан тыш, башка телләрдән сүзгә-сүз тәрҗемә итеп алынган фразеологик калькалар да бар (*давыл кошы*; русчасы: *буревестник*).

Нинди сыйфатларына игътибар юнәлдерүләренә карап, орнитоним компонентлы фразеологизмнар кешеләргә төрле яклап бәя бирәләр. Мәкаләдә китерелгән образлы гыйбарәләр арасында кешенең тышкы кыяфәтен, холкын, интеллектын, физик һәм рухи халәтен сыйфатлаучы фразеологизмнар күбрәк булып чыкты. Аларга аерым тукталып үтик.

Кешеләрнең тышкы кыяфәтен кошлар белән чагыштыру нәтиҗәсендә туган фразеологик әйтемнәр арасында аеруча актив кулланыла торган берәмлекләр кешенең комплекциясенә һәм буена кагыла. Мәсәлән, үтә ябык, арык тәнлеләргә *карга чукырлык та ите калмаган*, кечкенә гәүдәле, тиктормас, кыбырсык кеше яисә бала-чага турында *кычыткан чыпчыгы* дигән әйтемнәр таралган. Бик таза, симез хатын-кызларга карата *тутырган тавык* дип әйтү татар халкының милли ашы – тутырган тавык (тавыкның ит белән тиресе арасына чи йомырка өреп тутырып пешерелгән тавык) атамасыннан килә.

Төс-кыяфәт турында сүз барганда, аерым әгъза-органнарны образлы сурәтләгән фразеологик әйтемнәрне мисал итеп китерергә була. Мәсәлән, озын борынлы кешегә карата *ләкләк борын*, карлыгач койрыгы кебек аеры, очлы мыекка *карлыгач мыек* дию шундыйлардан. «Кешене киеменә карап каршы алалар...» дип әйтергә яраткан халык, килеш-килбәтен ошатмаган кешесенә *карга куркыткычы* (бик алама, ямьсез киенгән, кыяфәтсез кеше турында), *карчыгадан калган тавык шикелле* (кыяфәте калмаган, өтек, йолкыш, хәчтерүш, сәләмә мәгънәсендә), *койрыксыз тавык* (акылы-фигыле, хәтта тышкы кыяфәте белән дә тәгәлләнеп җитмәгән өтек кешегә карата) дияргә дә мөмкин. Тик, күңеле, уйлары матур булмаса, кешене матур кием генә дә бизәп бетерә алмый бит әле. Шуңа күрә, гомер-гомергә кунакчыллыгы, киң күңеллелеге белән дан тоткан халкыбыз кара янып, кәефсезләнеп йөрүне бер дә хупламый, чытык йөзле, төксе чырайлы кешеләрне ябалакка ук тиңләп, *чырайсыз ябалак*, ә интеллекты түбән мәгънәсез кешеләрне *ала кош* дип йөртә (ала карга, саескан кебек сайрый да, җырлый да белмәүче «ала» кошларны атаудан килеп чыккан фразеологизм).

Кеше холкының күп төрләре, төсмерләре булган кебек, әлеге сыйфатларны күпертеп сурәтләү өчен дә төрле-төрле кош образлары нигез итеп алына. Мисал өчен, *авызына саескан төкергән* (юкны сөйләүче, такылдык), *ала каргадай алдан-ала кычкыру* (булмаган эшне «була» дип, яки «булды» дип, алдан шаулап шапырынырга яратучыларга карата әйтелә) һ.б.

Характерга бәйле сыйфатлар охшашлыгы нигезендә барлыкка килгән тискәре коннотацияле орнитоним компонентлы фразеологизмнар, уңай бәя би-

рүчеләренә караганда, күбрәк очрый. Мәсәлән, кирелек, ялкаулык, куркаклык кебек сыйфатлар түбәндәге фразеологизмнарда тәнкыйтьләнә: *сүздә – сандугач, эштә – эшләки, тавык йөрәк, чыпчык йөрәк, тавык сыман кирегә тырмый* (тискәрегә эшли, кирегә сөйли). Алдакчы, кеше серен саклый белмәүче, башкалар хакында сөйләп йөрүчеләр *тере саескан очыра* (алдый, бергә бишне кушып сөйли), *сер тотмас үрдәк* (сер тотмый торган, бар белгәнен теләсә кая чәчеп-түгеп йөрүче), *урман шаулегәне* (гәүдә-кыяфәтенә килешмәгән яки ямьсез киемнән йөрүче) әйтемнәрендә алгы планга чыга, ә саран кешеләр *аннан алган йомырканың эчендә сарысы булмас* (алыш-бирештә бик саран, башкалар өлешенә керүче, һәр очрактан үзенә файда гына эзләүче), *аннан әйбер алганчы, тавыктан сөт саварсың* (беркемгә бернәрсәсен дә биреп тормый, игелексез кеше турында; комсыз, кысмыр, хәсис кеше мәгънәсендә) һ.б. әйтемнәр ярдәмендә сыйфатлана.

Уңай сыйфатлар түбәндәге образлы әйтемнәр белән билгеләнә: *авызында кош уйната* (бик оста телле, уңган кеше турында), *агачтан сандугач кына ясамый* (кулыннан килмәгән эше юк, үтә оста куллы, һөнәрләр иясе димәктән) һ.б. Уңыш казанган, башкалардан өстен саналган кешеләргә карата кулланыла торган фразеологизмнар төрлелеге белән аерылып тора: [аның] *сандугачы сайрый* (эше уңышлы бара, даны шаулый), *[аның] тавыгы юргалый, [аның] әтәче дә кубыз уйный* (аның эше алга киткән, һәрнәрсәсе башкаларныкыннан өстен, шәп, дигәнне аңлата), *[аның] әтәче дә күкәй сала* (тормышы алга киткән, байый башлаган), *аның үрдәге дә каз кебек, йомыркасы баш кебек* (байның, хәлле кешенең һәрнәрсәсе гади кешенекеннән мул, эре) һ.б.

Ниндидер бер өлкәдә уңышка ирешкән, танылган, билгеле кешеләрнең масаеп, эреләнеп китүчеләре дә була. Бу очракта, артык тәкәбберләнүчеләрне сүз белән чеметеп алу, яисә, кирәк чакта, «урынына утырту» өчен дә кош образлары ярдәмгә килгән. Мәсәлән, *йомыркадан чыкканчы әтәч булган* (әдәбият, сәнгать йә гыйлем мәйданына аяк басу белән үзеннән элгәреләрне бәреп егарга, «мин!» дип кычкырырга ашыгучы, дәгъвачыл яшь кешеләргә карата әйтелә), *әтәч баш* (баш булырга яратучы, тәкәббер кешегә карата). Булмаган таланты белән үзен шәптән санап, мактанып, масаеп йөрүче турында, ике кошны – карга һәм сандугачны чагыштырып, *карга көйгә «сандугач мин» дип йөри*, дию – шундыйлардан. Киресенчә, әле генә дөньяга чыккан, тәҗрибәсез кешеләр турында *йомыркадан чыккан гына, йомырка сарысы кипмәгән, йомырка эчендәге чебеш* тезмәләрен кулланалар.

Кешенең үз-үзен тотышы, әлбәттә, аның холкына, темпераментына бәйле. Мәсәлән, тыныч, пошмас, шау-шу яратмый торган кешеләр ялгыз калуны, басылып эшләүне, күбрәк өйдә булуны артыграк күрергә мөмкиннәр. Шуңа, урыныннан кузгалмыйча гел утырып торучы хакында *күкәй баскан күркә шикелле (утыра бирә),* гел өйдән чыкмый, урындыктан төшми утырып эшләүче турында *оя тавыгы, оя баскан каз (тавык),* беркая бармыйча, өендә генә утырырга яратучы кеше турында *оя тавыгы* һәм, киресенчә, тиктормас,

түземсез кеше турында *чыпчык кебек бер ботакта тормас* дигән образлы әйтемнәрне дә әлеге төркемгә кертә алабыз.

Кешенең интеллектына, ягъни аңлау, фикерләү дәрәҗәсенә, белеменә кагылышлы фразеологик әйтемнәрдә иң актив компонент – *тавык* орнитонимы. Мәсәлән, аңгыра, зиһенсез кешеләргә мыскыллап, тиргәп, *тавык мие эчкән, тавык баш, тавык бәкәленнән йөзә*, диләр. Начар хәтерне (хәтерсезлек, зиһенсезлек) дә тавык хәтере белән тиңлибез.

Гыйлем дәрәҗәсен сыйфатлаганда башка кош образларына игътибар юнәлткән фразеологизмнар да очрый: *бүрекле карга* (башы бүрекле кеше булып йөрсә дә, аңсыз, аңгыра, надан кеше димәктән), *кара карга* (аңсыз, кара надан), *карга маен эчкән* (башы эшләми, аңгыра, исе-хәтере юк димәктән), *колаклы ябалак* (аңгыра), *кәгазь сандугачы* (кеше алдына чыгып үз теле белән үз фикерен әйтү урынына, кәгазьгә язып бирелгәнне генә сөйләүчегә карата). Ахмак, тинтәк кешеләрне мыскыллап характерлау өчен *чәберчек йомыркасы чүмергән, чәүкә мие эчкән нәрсә, чыпчык баш* дигән тезмәләр кулланыла. Нишләгәнен үзе дә белми аптырап, аңгыраеп йөри торган кешеләрдән көлеп *тиле кәккүк, аңгыра күке (аңгыра күкеләнү)* дию очрый. Кәккүкнең көзгә таба сакаулана башлавын аңгыравыннан дип уйлап әйтелгән. Әлеге әйтем, йомыркасын башка кошлар оясына салып, балаларын башкалардан каратып үстергәнгә, кәккүк ялгыз калу хәсрәтеннән шулай саташып кычкыра имеш, дип ышанудан калган булса кирәк.

Кешеләрнең сәламәтлегенә, үзен ничек хис итүенә бәйле физик халәте дә кошлар белән еш чагыштырыла. Мәсәлән, өшептуңып тора торган кешегә карата мыскыл итеп *бөрешкән тавык, каткан тавык;* озак авырудан ябыгып, хәлсезләнеп калган яки еш авырый торган кешегә карата *чирле чебеш; чирләшкә,* хәлсез, дәрмансыз кешегә карата *көзге чебеш* (көзгә калып туган чебеш бөрешеп, начар үсеп, чирләшкә булганга шулай әйтелгән) диләр. Салкын тиюдән яки җайсыз ятудан муены каерылып, йә булмаса муен сеңере тартылып, муенын бора алмаган кешегә *каз муен (булган)*; салкын су керү, коену, салкын яңгыр астында калудан тәннең тиресе күгәреп, вак бөрчекләр белән капланган очракта, *каз тәне чыккан*, дию дә шактый төгәл, образлы чагыштыру нигезендә барлыкка килгән. Якыннан гына күрүче, кичке эңгер-меңгердә күрмәүче кешеләргә *тавык күз* дисәләр, үткен күзле кешеләргә, ерактан яхшы күрүчеләргә сокланып *торна күз* диләр.

Кешеләрнең рухи халәтенә, эмоцияләренә бәйле (шатлану, борчылу, ачулану, ярсу, дулау һ.б.) орнитоним компонентлы фразеологизмнар да очрый. Мәсәлән, *тиле күркә* (юктан борчылган, ярсыган кешегә әйтелә), *калай әтәч* (көче җитмәстәй эшкә алынучы, бәйләнчек, сугышырга яратучы) шундыйлардан. Кечкенә генә сәбәптән дә шашар хәлгә җитеп ярсырга, кемгәдер ташланырга әзер торучы кешегә карата *бөркеткә кан* диләр. Телебездә уңай эмоциягә бәйле орнитоним компонентлы фразеологизмнар да еш кулланыла. Ул да булса, татар халык әкиятләреннән телебезгә кергән *алтын кош тоту (кош тоту)* әйтеме. Элек нәрсәгә дә булса чамасыз куанган, ниндидер бер вакыйганы, уңышны

зур бәхеткә санап җилкенгән кешенең халәтен сыйфатлап, *алтын кош тоткан кебек,* дия торган булганнар. Бу очракта алтын кош, әлбәттә, мифик кош. Ул – татар экиятләрендә батырның зур каршылыкларны җиңеп кенә кулына төшерә ала торган бәхет кошы [Н.Исәнбәт, 1989, б. 70]. Шунысын да искәртик, Нәкый Исәнбәт теркәгән вакытта әлеге тотрыклы сүзтезмә алтын кош тоткан кебек рәвешендә кулланылган булса, бүгенге көндә алтын сүзе әйтелми дә. Ул күпмедер үзгәреш кичереп, төгәлрәге – кыскарып, *кош тоткан кебек* рәвешен алган һәм гади сөйләм телендә дә, әдәби әсәрләрдә дә шактый актив кулланыла торган тотрыклы берәмлеккә әйләнгән. Бүгенге көндә еш кулланылучы *кош тоткандай* тезмәсе элек мыскыллап әйтелә торган фразеологик берәмлек булган. Хәзер ул юк кына табышка, йә сатып алган товарга, йә булмаса кечкенә генә шатлыкка да куанучыга карата әйтелә. Әлеге фразеологизмның *бәхет кошы тоткандай, асыл кош тоткандай, серле кош тоткандай* вариантлары да очрый (*Әнкәсе күршеләреннән бәхет кошы тоткандай елмаяелмая йөгереп тә чыкты.* Н. Гыйматдинова. *Бер көнне бу асыл кош тоткандай атылып кергән.* М. Хәсәнов) һ.б. *Кош тоткандай, кош тоткан кебек* әйтемнәр аеруча еш кулланыла торган фразеологизмнар рәтендә торалар.

Мисаллардан күренгәнчә, татар телендәге фразеологик әйтемнәр арасында орнитоним компонентлы берәмлекләр шактый. Кешене төрле яклап сыйфатлаган мондый образлы гыйбарәләр сөйләм телендә дә, әдәби телдә дә бик актив кулланылалар. Кошларның физиологиясенә, яшәү рәвешләренә һ.б. ларга бәйле күп кенә үзенчәлекләрен кешеләрдәге сыйфатлар белән чагыштыру, тиңләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән мондый тотрыклы сүзтезмәләр күптөрле булулары белән аерылып торалар һәм сөйләмебезнең образлылыгын арттырырга ярдәм итәләр.

**Әдәбият**


*Исәнбәт Н.С.* Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. I том. Казан, Татар кит. нәшр., 1989. 495 б.

*Исәнбәт Н.С.* Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. II том. Казан, Татар кит. нәшр., 1990. 365 б.



***Сафина Эльвира Ирфат кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре,*
*email: 7idillia@mail.ru*

УДК 811.512.145'367

*Л.Г. Вәлиева*

# ТӨРКИ ТЕЛЛӘРНЕҢ СИНТАКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ АРАСЫНДА ПРОСТРАНСТВО МӨНӘСӘБӘТЕ

В данной статье выявляются структурные и семантические особенности конструкций, репрезентирующих пространственные отношения, на материале тюркских языков.

**Ключевые слова:** языковые категории, пространственная семантика, пространственные отношения, тюркские языки.

Телдә барлык вакыйгалар, процесслар, хәтта кеше үзе дә вакыт һәм пространство яссылыгында карала. ‘Пространство’ категориясенең телдәге бирелешен тикшерү актуаль санала, чөнки ул синтаксик берәмлекләр арасындагы мөнәсәбәтләрне семантик анализлауга игътибар арту белән бәйле. Пространство, үз чиратында, каузаль, кондициональ һәм башка мөнәсәбәтләрнең барлыкка килүе өчен фон ролен үти.

Әлеге мәкаләдә, төрки телләргә нигезләп, пространство мөнәсәбәтен белдерүче конструкцияләрнең структур һәм семантик үзенчәлекләре ачыклана.

Кеше аңы предметларның формасын, күләмен, урнашуын аерырга сәләтле. Пространство белән кызыксыну борынгы чорда башлана, фикер ияләре антик заманнардан ук аны тикшерүгә игътибар итәләр. Пространство структураларын өйрәнүче фән буларак, Борынгы Грециядә геометрия барлыкка килә.

Пространство мөнәсәбәтләре турыдан-туры фәлсәфә белән бәйләнгән. Фәлсәфи аңлатма буенча, пространство – материянең яшәеш формасы. Тел структурасында исә пространство төшенчәсе, кагыйдә буларак, вакыйганың үтәлү чикләрен билгеләүче урынны атау формасында белдерелә.

Рус тел белемендә пространство мөнәсәбәте функциональ-семантик, когнитив юнәлештә А.В.Бондарко, М.В. Всеволодова, А.В. Кравченколар тарафыннан шактый тулы өйрәнелгән.

Тюркологиядә пространство категориясен А.Т. Додуева, И.А. Невская, Ю.У. Хочавова һ.б., башлыча, әлеге мөнәсәбәтнең белдерелүен өйрәнү юнәлешендә тикшерәләр.

Моннан тыш тюркологлар урын хәлләрен һәм урын мәгънәсен белдерүче килешләр, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләрне өйрәнгәндә, теге яки бу дәрәҗәдә пространство мөнәсәбәте мәсьәләсенә кагылалар. Пространство мәгънәсен белдерүче килешләрне тугандаш һәм тугандаш булмаган телләр белән чагыштырып анализлауга багышланган махсус хезмәтләр дә бар (мәсәлән, Р.Х. Есбаева, Э.Н. Кардашев тикшеренүләре).

Пространство лексикасы сүзләрнең ачык һәм ябык төркеме белән белдерелә ала. Пространство семантикасын белдерүче сүзләргә астрономик объектлар, административ-территориаль берәмлекләр, төрле биналар, учреждение атамалары, табигатькә ка-

раган сүзләр һ.б. керә. Болардан тыш, төрки телләрдә урын мәгънәсен юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше формалары, бәйлек сүзле конструкцияләр, рәвешләр, алмашлыклар белдерә ала.

Предметның билгеле бер пространствода урнашуы, эш-хәлнең үтәлеш урыны түбәндәге чаралар ярдәмендә белдерелә:

– урын-вакыт килеше формасындагы исемнәр белән: азәрб. *Гәһрәман **мәктәбдә** чәтинликлә үз-үзә кәлир, анчаг дөнмүрдү.* ‘Гәһрәман мәктәптә кыенлыклар белән очрашты, ләкин чигенмәде’; башк. *Үзебез **Өфөлә**, ә улыбыз **Мәскәүҙә** тора.* ‘Үзебез – Уфада, ә улыбыз Мәскәүдә тора’; каз. *Аспанда теңгедей бұлт жоқ.* ‘Күктә тәңкәдәй болыт юк’; *Сөмбелә **фойеда** сыенып торырлык буш урын тапмады...* (К.Кәримов);

– бәйлек сүзләр һәм исемнәр белән: азәрб. *Султанов чај ичмәк үчүн **столун башында** әјләшди.* ‘Султанов, чәй эчер өчен, өстәл артына утырды’; алт. *Менинъ **кӧзнӧгим алдында** чиби агаш ӧзип дьат.* ‘Минем тәрәзәм алдында пихта агачы үсә’; каз. *Салқындау ағаш **ішінде жата** тұрайын.* ‘Салкынча урман эчендә ятып торыйм’;

– рәвешләр белән: каз. ***Мұнда** Бөжей, Байсалдар да келеді.* ‘Монда Бөжей, Байсаллар да килә’.

Хәрәкәтнең гомуми юнәлеше түбәндәгечә билгеләнә:

– урын рәвешләре ярдәмендә: азәрб. *Әнвәр гајыдыб кәләндә Әбил дурбини көзүнә тутуб **ашағыја вә јухарыја** бахырды.* ‘Әнвәр кайтып килгәндә, Әбил, бинокльне күзенә куеп, аска һәм өскә карый иде’; каз. ***Біз ілгері** кеттік.* ‘Без алга киттек’; карач.-балк. *Эртде чыкъсанг, **аллынга** кюн чыгъар, кеч чыкъсанг, **аллынга** ай чыгъар* (Мәкаль). ‘Иртә чыксаң, алдыңа кояш чыгар, кич чыксаң, алдыңа ай чыгар’;

– юнәлеш килеш формасындагы исемнәр белән: *Ат, инде ялыкса да, тизрәк **авылга** керергә ашкына иде, ахрысы, юырта башлады* (Л. Хәмидуллин);

– бәйлекләр һәм исемнәр: алт. *Кулун **энезининъ дьанына** текшилеп манътап келди.* ‘Колын әнисе янына чабып килде’; каз. *Абай **әжесінің қасына таман** келді.* ‘Абай әбисенең каршысына килде’.

Хәрәкәтнең башлангыч ноктасы түбәндәгечә билгеләнә:

– чыгыш килешендәге исем белән: азәрб. ***Дәниздән** сәһәр күләји әсирди.* ‘Диңгездән иртәнге җил исә иде’; карач.-балк. ***Джуртундан** чыкъгъанны бёрю ашар* (Мәкаль). ‘Йортыннан чыкканны бүре ашар’;

– бәйлекле исемнәр ярдәмендә: башк. ***Тау артъяғынан** таң тыуҙы.* ‘Тау аръягыннан таң туды’; каз. ***Қар астынан** бұлдырап шыққан қою қара түтіндер көрінді.* ‘Кар астыннан күтәрелеп чыккан куе кара төтен күренде’.

Хәрәкәтнең соңгы пункты түбәндәгечә билгеләнә:

– юнәлеш килешендәге исем белән: каз. ***Москваға** келдік.* ‘Мәскәүгә килдек’; *Авылга беренче кайткан солдатны күрергә дип, **идарәгә** кыз-кыркын, малай-шалайлар кереп тула* (Г. Мөхәммәтшин).

Казакъ телендә хәрәкәтнең соңгы пункты дейін, шейін бәйлекләре белән килгән юнәлеш килешендәге исемнәр ярдәмендә дә белдерелә: *Ағам мені **Қостанайға дейін** шығарып салды.* ‘Абыем мине Кустанайга кадәр озатты’; *Есіктен **төрге шейін** жиылған қызыл жібек*

*кілемдер.* ‘Ишектән түргә кадәр кызыл ефәк келәм җәелгән’.

Башкорт телендә шушы ук мәгънәдә *тиклем* бәйлеге кулланыла: *16-сы башҡорт кавалерия дивизияһы Волганан алып **Эльбаға тиклем** героик юл үтте.* ‘Уналтынчы башкорт кавалерия дивизиясе Волгадан алып Эльбага кадәр героик юл үтте’.

Кешенең объектка карата урнашуы һәм хәрәкәт юнәлеше бәйлек сүзләр ярдәмендә белдерелә: *Нарат **төбенә** ял итәргә утырдык* (Г. Мөхәммәтшин); *Озын тәнәфестә алар мәктәп **каршына** футбол уйнарга чыгалар* (Р. Зәйдулла).

Төрки телләрдә пространство семантикалы лексиканың шактый зур өлешен рәвешләр алып тора. Урын рәвешләре, кагыйдә буларак, пространствоны аның төп үлчәмнәрендә белдерә. Мәсәлән: каз. *Айнадай төңкерілген **үстімде** аспан, **төменде** көк толқындар көбік шашқан.* ‘Өстә көзгедәй күк әйләнгән, аста кара дулкыннар тирбәлә’; ***Якында** гына булып күренсә дә, урман авылдан **ерак** икән* (Р. Хафизова).

Пространство семантикасын предметлашкан процесслар да белдерә. Җөмләдә алар, кагыйдә буларак, урын хәле функциясен, сирәгрәк тәмамлык функциясен үтиләр. Мәсәлән: карач.-балк. *Аныуар бюгюн ауруб **дерсге** баралмай къалгъанды.* ‘Бүген Аныуар, авырып, дәрескә баралмый калды’; ***Тойгъа** барсанг, тоюб бар, кир тонунгу къоюб бар* (Мәкаль). ‘Туйга барсаң, туеп бар, керле туныңны салып бар’; *Сени къабарыкъ джылан башламагъан **ишингде** болады* (Мәкаль). ‘Сине чагачак елан башламаган эшеңдә була’.

Төрки телләрдә бәйлек мәгънәсендәге җир сүзе белән килгән сыйфат фигыль ярдәмендә дә пространство белдерелә: башк. *Ярһыу арыҫландар ҡанға батып алышҡан **ерҙә** көсөк талаштырыу урынлымы?* ‘Ярсу арысланнар канга батып алышкан җирдә көчек талаштыру урынлымы?’; *Янган **җирдә** үлән тиз генә шытмый* (М. Хәсәнов).

Иярчен урын җөмләнең хәбәре хәл фигыль белән белдерелгәндә, пространство мөнәсәбәте вакыт мөнәсәбәте белән якыная. Мәсәлән: башк. *Мин уның артынан, ул халыҡ араһына барып **еткәнсе**, эйәреп барҙым.* ‘Мин аның артыннан, ул халык арасына барып җиткәнче, ияреп бардым’.

Шулай итеп, пространство мәгънәсе – үзендә чынбарлыкның вакыйгалылык сферасын чагылдырган мөһим тел категориясе. Физик пространствоны аңлау, башка фикерләү категорияләре кебек үк, тел чаралары ярдәмендә белдерелә.

### Әдәбият


*Алиев У.Б.* Синтаксис карачаево-балкарского языка. М.: Наука. 1972. 351 с.

*Балакаев М.Б.* Современный казахский язык (Синтаксис словосочетания и простого предложения). Алма-Ата: Изд-во АН Казахской ССР. 1959. 235 с.

Грамматика азербайджанского языка (Фонетика, морфология и синтаксис) / Под общ. ред. М.Ш. Ширалиева и Э.В. Севортяна. Баку: ЭЛМ, 1971. 413 с.

Грамматика современного башкирского литературного языка / отв. ред. А.А. Юлдашев. М.: Наука. 1981. 495 с.

**Кыскартылмалар**

Азәрб. – азәрбайҗан.
Алт. – алтай.
Башк. – башкорт.
Каз. – казакъ.
Карач.-балк. – карачай-балкар.

***Вәлиева Ләниза Газинур кызы,*** *филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

*Г.Р. Гайнетдинова*

# РАБГУЗИНЫҢ «КЫЙССАСЕЛ-ӘНБИЯ» ЯЗМА ИСТӘЛЕГЕНЕҢ ИСЕМ СҮЗ ТӨРКЕМЕНӘ ТАРИХИ-ЛИНГВИСТИК АНАЛИЗ
## («Лут пәйгамбәр кыйссасы» мисалында)

В статье сделана попытка историко-лингвистического анализа имени существительного лексики текста Рабгузи «Сказание о пророке Лоте» и сопоставления с лексикой современного татарского языка и его диалектов.

**Ключевые слова:** письменный памятник, лексика, имя существительное, Рабгузи, историко-лингвистический анализ.

Насретдин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» язма истәлеге 1310–1311 елларда Харәзмнең төньягында язылган. Авторның керештә язылганнарыннан Рабат Угызда югары хөкемдар булганлыгын беләбез. Аның Рабгузи псевдонимы шуннан килә. Әдипнең тормыш юлы, биографиясе турында хәбәрләр сакланмаган. 555 битлек бу эпик әсәр дини-дидактик эчтәлекле, пәйгамәрләр тормышына багышланган прозаик әсәрләрнең берсе [Нуриева, с. 48].

П.М. Мелиоранский, А.Н.Самойлович, С.Е. Малов, А.М. Щербак, Ә.Р. Тенишев, А.Н. Баскаков, В.М. Насилов кебек галимнәр хезмәтләрендә бу язма истәлекнең теле Урта Азия төрки теле, дип карала [Нуриева, с. 48]. Алтын Урда берничә мәдәни үзәкле булган. Шуларның берсе – Төньяк Харәзм, биредә Урта Азиянең төрки язма мәдәниятенең традицияләре сакланган; икенчесе – Сарай шәһәре (XII–XIII г.). XIV гасырдан башлап, Мисыр төрки дөньяның мәдәни үзәге буларак таныла башлый.

А.Н. Самойлович бу язма истәлекнең телен беренче дәвердәге бердәм Урта Азия төрки әдәби теленә кертә. Шул ук вакытта әсәр теленә кыпчак элементлары кергәнлеген дә искәртә: «Предварительно мое мнение сводится к тому, что язык его, с преобладанием в фонетике черт северо-восточной группы турецких языков (конечное γ и d вместо j) и с особой близостью в отношении словаря к языку первого периода, все же обнаруживает некоторую связь с языком второго (кыпчакско-огузского) периода [Нуриева, с. 49].

Бу мәсьәләгә карата Ә.Н. Нәҗип болай дип язган: «На территории современного Египта нашел свое дальнейшее развитие золотоордынский смешанный кыпчакско-огузский письменный язык» [Наджип, с.16]. Э.И. Фазылов XIV гасырда Алтын Урдада иҗат ителгән язма истәлекләрне үзбәк теленең үсеше тарихын өйрәнү чыганагы итеп карый: «Один из важных источников чагатайской (староузбекской) литературы непосредственно связан с хорезмийской эпохой, по отношению к которой и употребляется термин «староузбекский» [Гайнетдинова, с. 16].

В.М. Насилов фикеренчә, «Произведение Рабгузи представляет собой перевод с персидского на тюркский диалект, который сохраняя литературную традицию караханидских памятников, сложился в огузско-кыпчакской этнической среде в хорезмском монголо-золотоордынском ханстве» [Нуриева, с. 49].

Төрки язма истәлекләрен өйрәнгәндә аларның лексикасын тикшерү әһәмиятле. Хәзерге көндә борынгы һәм иске татар телендәге язма истәлекләрнең телгә, аның лексикасына, шул исәптән, конкрет бер төрки телнең хәзерге лексикасына мөнәсәбәте мәсьәләләре күтәрелә. Шунысын әйтергә кирәк, фонетика да, морфология дә, синтаксис та төрле чорларда һәм төрле территорияләрдә төрки телләрнең тарихи үсеш-үзгәрешләре турындагы мәгълүматны лексика бирә алган кадәр бирә алмый. Әлеге мәкаләдә «Лут пәйгамбәр кыйссасы» тексты лексикасының билгеле бер күләмдә исем сүз төркемен тикшерү максаты куелды. Исемнәр якынча 240 лап (шуларның 40 ы – ялгызлык исемнәре), башка сүз төркеме белән чагыштырганда, күпчелекне тәшкил итә. Мәкаләдә татар теленең хәзерге көндә дә сакланган лексикасы һәм ялгызлык исемнәре каралды. Тикшеренү өчен материал С.Е. Малов тәкъдим иткән тексттан (1951) алынды.

آزوقلوغ – azuqluγ [азуклуг] – азык, ризык, тәгам: azuqluγ aruq ermäs – ризыгы булган – юлда алҗымас. Хәзерге татар телендә *азык* үзенең мәгънәсен югалтмаган, нәрсәнең дә булса, нинди дә булса эшчәнлекнең чыганагы, эш өчен материал дигәнне аңлата.

اوعلى – ugly [угълы] – улы: ..uguzinin qadisi burhanaddin ugly nasaraddin allahi gajiba andagi itür.. – ... Борһанетдин улы Насретдин Угыз җирлегеннән – Аллаһ гөнаһларыннан арындырсын... Хәзерге татар телендә бу сүз үз мәгънәсен югалтмаган: ата-ананың ир баласы; ир затындагы яшь буын; кайсы да булса милләт вәкиле булган уңай характерлы, танылган кеше – *татар халкының улы*; тартым формасында – *улым*.

ييكتلآر – jigitlär [йигитләр] – егетләр, берлек санда – егет: bikimiz…biklär urugi jigitlär ariγi ulug atliγ…– безнең бәк (җитәкче) бәкләр нәселеннән, егетләрнең асылы, бөек, атаклы... Хәзерге татар телендә *егет, егетләр* – киң кулланыла торган сүзләрнең берсе. Казан диалектында – *җегет*. Күчерелмә мәгънәдә тәвәккәллекне, кыюлыкны, мактауны белдерә.

آدمىلآر – adamilär [әдәмиләр] – кешеләр: …adamilär inaǯi mu’minlär kuaniči…– кешеләрнең өмете, мөселманнарның горурлыгы... Хәзерге татар телендә *адәм – кеше* күп мәгънәдә кулланыла: 1) *адәм актыгы (калдыгы)* – кешене түбәнсетү, кимсетү формасында кулланыла; 2) *адәм булу* – кешелекле булу; 3) *адәм итү* – җәмгыяти тормышта яраклы кеше итеп тәрбияләү; 4) *адәм көлкесенә калу* – оятка калу һ.б.

عقلى – γaqly [гъакълы] – акылы, башлангыч формасы – акыл: …humti adiz γaqly tinkiz jikimiz…– көнчелеге югары, акылы тирән (диңгез кебек)... Хәзерге татар телендә *акыл* – фикер сәләтенә ия булу. Мәгънәләре: 1) *акыл бирү* – киңәш бирү; 2) *акыл ирешә алмаслык* – аңлау өчен катлаулы, күз алдына китерә алмаслык; 3) *акыл иясе* – акыллы (зирәк) кеше, галим һ.б.

تاريخقه – tarihqa [тарихка] – тарихка, башлангыч формасы –

тарих: tarihqa säkiz jüz tuquzinda it jil qasada bitlädi kim aniŋ üčün pigambärlär kijssalariga gait ragbatimiz bar…автор язган: 809 елда, эт елында, бездә пәйгамбәрләр тормышына игътибар зур булган... Хәзерге татар телендә *тарих* сүзе берничә мәгънәгә ия: реаль тормышта булган вакыйгалар; җәмгыять тормышының реаль үсеше; кешелек җәмгыятенең үсеше турындагы фән; башы һәм ахыры булган ниндидер вакыйга (*тарих арбасы / тәгәрмәче*).

تینکیز – tinkiz [тингиз] – диңгез: ...humti adiz ɣaqly tinkiz jikimiz nasrutdin tuqbuɣa…– безнең җитәкчебез Насретдин Ток-буга – көнчелеге югары, ә акылы диңгез кебек... Хәзерге татар телендә *диңгез* күчерелмә мәгънәдә дә кулланыла, нәрсәнең дә булса чиксез күп булуы, яисә зур территория, пространство биләп торуны аңлата: *хисләр диңгезе, гыйлем диңгезе.*

یردہ – jirdä [йирдә] – җирдә, башлангыч формасы җир: … tikmä jirdä kim ul kitab tabilur nikim tiläsä bulunur..– һәр җирдә бу китапны табарга була, теләге булган – таба. Хәзерге татар телендә җир, күпмәгънәле сүз: планета, Җир шары, җирнең өске өлеше, туфрак, чәчү өчен кырлар; т*уган җир – Ватан*, нинди дә булса предметның, әйбернең өлеше: *урта бер җир* һ.б.

سوزى – süzi [сүзи] – (тарихның) сүзе: ...bigadisinin süzi üzük, bigadisinin maqsudlari uksuk idi…– кайбер тарихларның сүзләре кыска (кыскартылган), ә максатлары җитәрлек түгел... Хәзерге татар телендә *сүз* берничә мәгънәгә ия: *сүзгә керешү* – сөйләмне башлап җибәрү; *сүз иреге; сүз ирештерү* – гайбәт сөйләү; *сүз куешу, сүздә тору* – вәгъдәне үтәү; *сүз алышу* – фикерләрне уртаклашу һ.б.

ایذیدین – [izidin] – Алла, илаһ: izidin taufiq istiganat tiläb kitab bašladim – ...Аллаһтан ярдәм сорап, мин (бу) китапны башладым. Хәзерге татар телендә бирелгән формада кулланылмый, әлеге мәгънәдә *Алла, Аллаһы Тәгалә, Ходай* сүзләре кулланыла.

آت – [at] – исем, атама: … qiyssas rabɣuzi at qujdum…– «Рабгузи кыйссасы», дип атадым (исем куйдым)... Хәзерге татар телендә *ат* формасы искергән булып санала: *син ни атлы*? Бу мәгънәдә *исем* сүзе кулланыла. *Ат* – сүз ясаучы тамыр булып тора: *атала, атаклы, атказанган.*

جواب – [žavab] – җавап: … käfirlärdin žavab išitkän…– кәферләрдән җавап ишеткән... Хәзерге татар телендә *җавап*: *җавап алу* – сораштыру; *җавапка каршы булу* – ризасызлык белдерү, бәхәсләшү; *җавап итеп* – ниндидер эшкә реакция; *җавапка тарту.*

اوروش – [uruš] – сугышу, көрәшү: käfirlär uruš qilgan…– ул кәферләр белән сугыш кылган (сугышкан, көрәшкән). Хәзерге татар телендә *сугыш, сугышу, көрәшү*. *Орыш* формасы искергән булып санала, талашу, сүз әйтешү мәгънәсен белдерә. *Орыш-талаш* – көчле сүз әйтешү, *орыш-кырылыш* – көчле сүзгә килү, әрләшү, зур бәхәскә килү.

کوچ – [küč] – көч, контекстта көч күтәрде: yarliɣ išitib küč kütärdi.. – боерык ишетеп, көч күтәрде. Хәзерге татар телендә шул ук формада һәм мәгънәдә кулланыла: *көч* – куәт; т*авышның (мәхәббәтнең) көче* – ниндидер эшнең интенсивлыгы мәгънәсендә; *акыл көче* – кешенең эчке мөмкинлекләре; *сәяси көчләр* – максатлары һәм эшчәнлеге белән

аерымланган җәмгыять оешмасы (төркеме); *көч бирү* – илһамландыру; *көч керү* – эчке ресурсларның тулуы; *көч сынау* (сынашу) – кайсы да булса өлкәдә үзеңнең сәләтеңне күрсәтү.

بتقه – [butqa], башлангыч. ф. but – идол: butqa tabinmaŋ kiriŋiz bu dingä...– сыннарга табынмагыз, бу (минем) дингә күчегез... Хәзерге татар телендә *пот, санам, тораташ, мәҗүси* сүзләре кулланыла.

يولغه – [julga], башлангыч. ф. jul – юл: anča čaүliq üzün ildä biri julga kirmäyin – ул шулкадәр күп еллар юлга башка илләргә чыкмады. Хәзерге татар телендә юл: *юл акчасы, юл киеме* – сәфәргә, сәяхәткә чыгу мәгънәсендә; *икенче юлга калдыру* – башка вакытка күчерү; г*омер юлы; качу юлын эзләү* – нәрсәдән дә булса качу; *юл адашу* – югалу; *юл бирү* – ниндидер эштә, хәрәкәттә бәхәскә кермәү һ.б.

اتاسي – [atasi] башлангыч ф. ата: lutniŋ atasi harun – Харун – Лутның атасы. Хәзерге татар телендә *ата, әти. Ата йорты* – туган нигез, *ата ягы* – әти ягыннан туганнар; *ата-ана; ата-баба; ата каз* һ.б.

Ялгызлык исемнәреннән берничә мисал:

برهانالدين – [burhanadin] – Борһанетдин;

ناصرالدين – [nasraddin] – Насретдин;

لوط – [lut] – Лут;

اليس – [il`yas] – Ильяс;

ابراهيم – [ibrahim] – Ибраһим;

ادريس – [idris] –Идрис;

ساره – [sara] – Сара һ.б.

Бу хезмәттә «Лут пәйгамбәр кыйссасы»ның исем сүз төркеменең бер өлеше генә каралды, чөнки әлеге тикшеренү шактый күләмле, аны бер мәкалә кысаларында гына тулысынча ачыклап бетерү мөмкин түгел. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, әлеге язма истәлек лексикасының зур өлеше татар телендә хәзерге көндә дә сакланып калган һәм бу алар арасындагы тарихи бәйләнешне күрсәтеп тора.

**Әдәбият**

*Гайнетдинова Г.Р.* Историко-лингвистический анализ тюрко-татарского письменного памятника XIV века Джамал ад-Дина ат-Турки «Китабу булгат ал-муштак фи лугат ат-турк ва-л-кифчак»: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 155 с.

*Наджип Э.Н.* Тюркоязычный памятник XIV века «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык. Алма-Ата, 1975. 284 с.

*Нуриева Ф.Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. Казань, 2004. 376 с.

***Гайнетдинова Гөлнара Рашат кызы,*** *филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

*Р.Ф. Мирхәев*

# МУСА АКЪЕГЕТНЕҢ «ХИСАМЕТДИН МЕНЛА» ӘСӘРЕНДӘ МАТУР ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИК КАТЛАМНАР НИСБӘТЕ

В конце XIX века в татарской литературе формируются новые жанры, одним из которых является просветительская проза. В функционально-стилистическом отношении в произведениях татарских писателей-просветителей наблюдается интенсивное проникновение публицистики в художественную ткань. В статье рассматривается соотношение художественного и публицистического начал в произведении М. Акъегета «Хисаметдин менла».

**Ключевые слова:** старотатарский письменно-литературный язык, язык татарской просветительской прозы, художественная литература, публицистика.

XIX гасыр ахыры татар әдәбияты публицистик башлангыч зур урын алып торган проза жанрларының барлыкка килүе белән характерлана. Публицистиканың матур әдәбият өлкәсенә үтеп керүе, әсәрдә авторның теге яисә бу күренешкә карата гражданлык позициясенең көчәюе турыдан-туры бу чор татар җәмгыяте өчен хас булган иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни ситуация белән бәйләнгән. Мәгълүм булганча, XIX гасырда татарлар арасында мәгърифәтчелек фикерләре тарала башлый, алар, үз чиратында иҗтимагый һәм мәдәни тормышта прогрессив үзгәрешләргә этәргеч бирәләр.

Баштарак татар мәгърифәтчеләре фәлсәфи һәм дөньяга караш проблемалары, фән һәм мәгърифәтне пропагандалау белән генә чикләнгән булсалар, соңга таба аларның эшчәнлеге тагын да киңәеп, татар халкы һәм аның мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган әдәби хәрәкәт булып үсеп китә [Татар..., б. 212–220]. XIX гасыр ахырында Европа мәдәнияте йогынтысында татар әдәбиятында яңа юнәлеш – рационализм, сентиментализм һәм мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган татар прозасы формалаша. 1886 елда татар теленде беренче зур күләмле проза әсәре – М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» повесте басылып чыга. Берникадәр вакыттан соң әлеге юнәлештә яңа әсәрләр – З. Бигиевнең «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә» (1886), «Гөнаһе кәбаир» (1890) һәм Р. Фәхретдиннең «Сәлимә, яки гыйффәт» (1899), «Әсма, яки гамәл вә җәза» (1903) романнары дөнья күрә. Әлеге әсәрләр белән мәгърифәтче язучылар татар әдәбияты тарихында яңа дәверне башлап җибәрәләр [Татар..., 1985, б. 291].

«Хисаметдин менла» повестена килгәндә, биредә автор чынбарлыкны һәм вакыйгаларны сурәтләгәндә, тормыш-көнкүреш, мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләләре белән генә чикләнеп калмыйча, татар тормышына XIX йөз алып килгән үзгәрешләргә һәм яңалыкларга да мөнәсәбәтен белдерә. Бу – әсәрнең эчтәлегендә дә, автор һәм персонажлар сөйләменең

бирелешендә дә күренә. Иҗтимагый һәм мәдәни тормышка кагылышлы мәсьәләләр әсәрдә публицистик стильдә тасвирлана. Үз вакытында күренекле тел галиме В.Х. Хаков билгеләп үткәнчә, «... вакыйгага һәм күренешләрне тулы сурәтләргә омтылыш, портрет, персонаж сөйләмен бирүдәге яңалыклар, матур әдәбият һәм публицистика әсәрләре теленә хас үзенчәлекләрнең аралашып килүе М. Акъегеткә хас язу алымнарын тәшкил итә» [Хаков, 1993, б. 247–248]. Болар барысы да язучы татар әдәбияты белән бергә татар әдәби теле үсеше тарихында да яңа дәверне башлап җибәргән дип әйтергә тулы нигез бирә.

Әсәрдә матур әдәбият һәм публицистик башлангычларның үзара үрелеп китүе берникадәр дәрәҗәдә аның теленә дә тәэсир иткән. Мәгълүм булганча, матур әдәбият өчен күренеш һәм вакыйгаларны гомумиләштереп сурәтләү хас. Конкрет бер фактка, фикергә нигезләнгән публицистикадан аермалы буларак, ул, чынбарлыкны типиклаштырып һәм образлар ярдәмендә сурәтләп, яңа бер дөнья тудыра. Икенче төрле итеп әйткәндә, матур әдәбият конкрет мәгълүматны сәнгатьчә сурәтләү чараларын, киңәйтелгән диалоглар һәм эчке монологларны кулланып, образлы рәвештә тәкъдим итә. Без моны М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә дә күрәбез. Мәсәлән:

*Atny saraj astynda järläšdergän zamanda menlanyŋ küzenä güzäl ber küreneš rast kälde: jort bujynča art xanäjä ber qyz kičijur. Qyz urta bujly, bašynda jaxšy qazan qalpağy kijelmeš, üstündäki jonly kük qamzuly nazik vä zifa bujyna jaxšy jaqyšur, bujnynda saf kömeš manitlar bağlanmyš, ufaq ufaq atlab käčän waqytda jumruq vä tağčyq šikelle ike göğsünä aqčalar čyldyr čyldyr orolor, ajağynda tamburly čitek bašmaq, sačy vä küzläre vä qašlary jaltyrawyq qara, jöze nurly, qyzğylt aq, borony kečkenä vä güzäl. Azbarda kemsä juq zan idüb, šälene omuzuna salub gäčdeğendän ütäre menlamyznyŋ küzläre ansyzdan bu cämiläjä baqub zävyqlandylar. Bu näzük bil vä cämilä qyz menlanyŋ küzenä tämamän köründü. Muma iläyha sahibe mösafirhanä qyzy güzäl vä kürkäm Xänifä nam ide. Nijä alla böjlä cämilälär jarata ikän! Bu inčä bile tamaša idäräk menlamyz xäjratda qaldy, mäğyjšätneŋ zäxmätlärene unudub üz üzene unutdy* [Акъегет, б. 9].

Публицистик текстларда исә, автор иҗтимагый вакыйгаларның асылын ачып бирергә һәм укучыга үзенең гражданлык позициясен җиткерергә омтыла. Бу очракта чынбарлык ничек бар шулай сурәтләнә. «Хисаметдин менла» повестенда әдәби башлангыч баштан ук публицистик чигенешләр белән аралашып бара һәм язучы татар иҗтимагый тормышындагы күренешләргә мөнәсәбәтен белдерү өчен монологлардан да (а), диалоглардан да файдалана (б):

а) *Xälbuki uqucylarym! Ul atasyny hič jadyna almady. Rusijada sakin un miliun islam qardäšlärene jadyna aldy. Atasy näjä lazym. Ul wafat, alla cännät virsün. Ama un ber miliun islam diri qaldy. Avrupadan bašqa Ğosmanlylar vä Mysyrlylar vä Hindlelär bezem nadanlyq vä gaflätdän kölürlär, häjhat! Ama mäğlümatly ulmaq ičün nä lazym?* [Акъегет, б. 5–7].

б) – *Menla säneŋ iğtiqadyŋ päk jaxšydyr, – süzä kerešde Äbüzär bäj, – tuğry äjtäseŋ, dine islam än xaqiqat din, än oluğ din, böjlä iğtiqadda min üzem dä toramyn.*

*Läkin bu Avrupa ädäbäseneŋ bäğzylary dine islamy tijüb noqsaniyätlär tabalar. Ničün anlar islamiyäte aŋlamazlar ikän?*

*– Sän bäŋa äjt, – dide menla, – nindäj noqsaniyät tabalar?*

*– Mäsälä, Avrupa ädäbäse där ki, islamiyät qadyn cenesene xur kürüb, noqsanlyqda tota imeš. Islam qadynlary uqu jazy az bilür imeš.*

*– Jalancydyr säniŋ Avrupaŋ, šäriğäte islamijä qadynlar xoququny hič näqys itmäz. Uqumaq xaqynda isä xäzräte räsül dimeš ki, ğyjlem öjränmäk häm möslimgä häm här möslimägä faryzdyr. Bezüm qadynlarymyz cahil ulsalar, bunda üzümez ğajeplemez, juxsa hič islamiyät dägel, – tăğrif bujurdy Xisameddin menla* [Акъегет, б. 21–22].

Матур әдәбият һәм публицистикага хас алымнарны куллану әсәрнең укучыга тәэсир итү көчен арттыра, авторга аларны үз чорының актуаль мәсьәләләре белән якыннан таныштырырга ярдәм итә. Әйтергә кирәк, мәгърифәтче язучыларының әсәрләрендә татар теле үзенчәлекле формада гәүдәләнеш таба. Татар җәмгыятенең рухи һәм мәдәни ихтыяҗлары XIX гасыр ахырында яңа төр проза әсәрләренең барлыкка килүенә этәргеч биреп кенә калмыйча, аларда тел чараларының кулланылышына да йогынты ясаган дип әйтергә мөмкин. «Хисаметдин менла» повестеннан күренгәнчә, биредә классик иске татар язма әдәби теленә хас традицион берәмлекләр гомумхалык сөйләм теле үзенчәлекләре белән бергә үрелеп китә. Галимнәр фикеренчә, бу – милли әдәби тел формалашу чоры өчен хас төп тенденцияләрнең берсе [Хаков, 1972, б. 55]. Шуның белән бергә автор госманлы-төрек теле үзенчәлекләреннән дә мул файдалана, хәтта аерым җөмләләрне төрек теле грамматикасы кагыйдәләренә буйсындырып бирә. Әлеге «чуарлык», «Хисаметдин менла» әсәренең теле өчен генә хас булмыйча, иске татар әдәби теленә караган башка язма чыганакларда да күзгә ташлана.

Әйтергә кирәк, М. Акъегет башка тел өчен хас лексик һәм грамматик берәмлекләрне очраклы гына кулланмый, ул алардан билгеле бер стилистик максатлардан чыгып файдалана. Мәсәлән, бүгенге көндә төрек телендә генә сакланып калган -jur хәзерге заман хикәя фигыль формасы, нигездә, әсәрдәге әдәби катламның үзенчәлеге булып тора. Язучы аңа түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә:

1) персонажларның психологик халәтен биргәндә: *Šu jerdä Xisameddin menla mötäässir ulub tuqtady vä küzläre beraz sulandy. Berike daqiqa fikerdän sonra uqumaja dävam idüb: «Ävät čoq tăğäccebder ki, ber adämen xälenä märxämät idärez dä, ber miljun adämä, ber millätä märxämätemez juqdyr...». Bu jirdä üzene zabt idämäjüb ağlamağa bašlady üze ağlyjur üze uqyjur* [Акъегет, б. 5–6]. *Gacäibder ki, ävväl waqytlarda menlamyz qyzy käčüb kidändä kürsä dä bik šad ulur ide, šimdi isä ber kürmäklä qänäğätlänmäjüb morady daha artdy. Vä his itde ki jäš jöräge qyz ilä xäbärläšmägeб kürešmäk vä küz küzä süzläšmäge estijur* [Акъегет, б. 21].

2) аерым очракларда пейзаж картиналарын сурәтләгәндә: *Kičä ğajät sükünät xäldä ide. Hičber xäräkät išedülmider. Ančaq jaqynda küčük ber su čereldäb aqyjur* [Акъегет, б. 37].

3) персонажларның сөйләмендә:

*– Sähärdä Ğabbas ağanyŋ qyzyny bik maxtajurlar, – süzä*

*kerešde Ğali bajnyŋ ticarätdä baš xadime vä süzenä dävam ilä: – Uqumyš päk kürkäm vä uqyğan dijüb söjlärlär.*

*– Qyzyny čoq kiši maxtajur, – dide Ğali baj ...* [б. 13].

*Mäzkür šäkerd süzenä dävam idüb dide:*

*– Awylymyzda söjlilär ki jätim Moxtarny xäbes itmešlär.*

*– Bäli tuğry xäbär, – cävap virde Xisameddin menla.*

*– Bälki tuğry, ama xäbes idülmäsenä sez säbäbce ulduğunyza bez hič inanmyjuryz...* [Акъегет, б. 15].

Шул ук вакытта татар теленең үз берәмлеге саналган -а хәзерге заман хикәя фигыленең «Хисаметдин менла» повестенда функциональ-стилистик кулланылыш даирәсе -jur формасына караганда киңрәк. Ул әсәрнең әдәби катламында да, публицистик катламда да очрый. Аерым алганда автор аны түбәндәге очракларда куллана:

1) пейзаж картиналарын тасвирлаганда: *Nun awylynda ike mäsced var. Ber uramly awyl bulub uramy uzun vä kiŋder. Uramy uzajub qyjbla tarafyndaki očynda burulub suğa jul čyqadur* [б. 2]. *Avgust ajynda räüšan ber könendä sabax waqytlarynda Nun awylynda hič xäräkät kürülmäjüb, sükünät kämal däräcäsendä ide. Ančaq berničä keše uram bujynča soly költälär ilä šyğyrdyj šyğyrdyj ütälär. Bu insanlar axry päk saran idelär, čünkä jökläre ağyr, ğaräbä očlarynda degetläre az ide* [Акъегет, б. 51].

2) персонажлар сөйләмендә:

*– Söylä küpme ajda tabasyn? – surdy Äbüzär bäj.*

*– Jegermedän jegerme üč manitqa qadar tabamyn, – cävab virde Moxtar.*

*– Soŋ ničük öjlä ulur. Jegerme üč sum tabasyn, aj xaqyŋ ancaq alty sum? – dide menla.*

*– I dustym menla. Ajlyq xaqny inde söjlämä. Izvoščiqlyqda ğajre jullar ilä tabalar. Ägär joqlamasaŋ här kön qazanursyn öč-dürt sum. Läkin sahibkä ančaq ike sum viräsen dä päk šad uladyr, šöjlä här kön ber-ike sum gizliseŋ dä aqča da qazanyla* [Акъегет, б. 44].

*– Sän qajda bolaj bik irtä barasyŋ tutaj? – surdy jäšräk qadyn.*

*– Ikmäklärümne pičkä qujğanda körägem jaryldy, köräk sorarğa baramyn balaqaj! – cävablandy qart qadyn* [б. 51].

3) көндәлек тормыш-көнкүреш вакыйгаларын сурәтләгәндә:

*Jäšlär oluğ xanäjä kermäjüb baqčaja ütübanda mävcüd baqyr xanäsenä kerdelär. Baqyr xanä iči tuzan vä baqyrčy xezmätkärlär ilä tulmyš. Anda sämovar tözätälär! Bunda lampa tözätälär. Ul ber tarafda molotoq berlä baqyrny čekček ulub bašny ağyrtalar* [б. 45].

4) публицистик характердагы диалогларда һәм монологларда:

*– Menla säneŋ iğtiqadyŋ päk jaxšydyr, – süzä kerešde Äbüzär bäj, – tuğry äjtäseŋ, dine islam än xaqiqat din, än oluğ din, böjlä iğtiqadda min üzem dä toramyn. Läkin bu Avrupa ädäbäseneŋ bäğzylary dine islamy tijüb noqsaniyätlär tabalar. Ničün anlar islamiyäte aŋlamazlar ikän?*

*– Sän bäŋa äjt, – dide menla, – nindäj noqsaniyät tabalar?*

*– Mäsälä, Avrupa ädäbäse där ki, islamiyät qadyn cenesene xur kürüb, noqsanlyqda tota imeš. Islam qadynlary uqu jazy az bilür imeš.*

*– Jalancydyr säniŋ Avrupaŋ, šäriğäte islamijä qadynlar xoquqyny hič näqys itmäz. Uqumaq xaqynda isä xäzräte räsül dimeš ki, ğyjlem öjränmäk häm möslimgä häm här möslimägä faryzdyr. Bezüm qadynlarymyz cahil ulsalar, bunda üzümez ğajeplemez, juxsa*

*hič islamiyät dägel, – tăğrif bujurdy Xisameddin menla* [б. 21–22].

*Ujğanynyz qardäšlär! Ujğanynyz, bunyn kebi ğaqylsyz dälilläreŋezlä üzeŋezdän köldermägez! Baqyŋyz bašqa millätlärä, istär fransyzlara, istär nimsälärä, bunlar dägel suda kimä ilä balyq kebi jözmäge, hawada qoš kebi učmaq mašinasyny düzä belälär. Ama bezneŋ suqalamaq ilä waq säüdädän bašqa hönäremez juq kebider…* [б. 46].

Йомгаклап әйткәндә, татар мәгърифәтчелек прозасы башка әдәби жанрлар кебек чынбарлыкны танып белү, укучының эчке дөньясына тәэсир итү, аның эстетик һәм этик идеалларын формалаштыру чарасы буларак барлыкка килә. Үз чорының иҗтимагый һәм мәдәни шартлары бу төр әсәрләрдә тел берәмлекләренең (лексик һәм грамматик) кулланылышына да тәэсир иткән: алар нәкъ менә югарыда телгән алынган максатка ирешү өчен хезмәт иткәннәр.

**Әдәбият**

*Акъегет М.* Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя / М. Акъегет. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1886. 70 б.

Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т. 2. XIX йөз татар әдәбияты. Казан: Татар кит. нәшр., 1985. 564 б.

*Хаков В.Х.* Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан: Казан университеты нәшр., 1972. 224 б.

*Хаков В.Х.* Татар әдәби теле тарихы / В.Х. Хаков. Казан: КДУ нәшр., 1993. 325 б.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,*** *филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре,*
*e-mail: mirhaev77@mail.ru*

УДК 811.512.145'373

***Ф.М. Мөхәммәтшин***

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫНЫҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье рассматриваются языковые особенности современной татарской прессы, в частности проблемы, связанные с чрезмерным употреблением заимствований. Автор придерживается мнения, что в большинстве случаев они могут и должны заменяться собственно татарскими словами.

**Ключевые слова:** современная татарская пресса, периодические издания, татарский язык, лексика, заимствования, термины.

Вакытлар узу белән газета-журналларның тематикасы гына түгел, сүз байлыгы да үзгәрә бара. Милли вакытлы матбугат үсешендәге, шул исәптән татар матбугатындагы үзгәрешләр, беренче чиратта, телнең лексик катламы белән бәйле. Чөнки нәкъ менә лексика җәмгыятьтәге үзгәрешләрне тиз тоя.

Татар вакытлы матбугатының хәзерге үсешендә төп тенденцияләрнең берсе – иҗтимагый сәяси терминнар ясау һәм куллану өлкәсендә төп эшчәнлек. Алай гына түгел, беренче нәүбәттә нәкъ менә татар вакытлы матбугаты терминнар ясау һәм камилләштерүнең эксперимент мәйданы булып хезмәт итте һәм хәзер дә шулай. Әйтергә кирәк, җәмгыятьтә барлыкка килгән теләсә нинди яңа күренеш, иң беренче булып, журналист мәгълүматында чагылыш таба, шушы күренешкә туры килүче яңа төшенчәне, сүзне дә беренче булып, күпчелек очракта, журналист уйлап табарга мәҗбүр. Яңа терминнар табу процессы тел үсешенә хезмәт итсә дә, еш кына, ул аның өчен катлаулы проблемалар да тудыра.

Бүгенге көндә татар теленең терминологиясе барлык фәннәр буенча да диярлек формалашкан. Әмма бу өлкәдә буталчыклар да яшәп килә. Бу бигрәк тә вакытлы матбугат битләрендә очрый. Моның сәбәпләре дә бар. Дөньядагы башка телләр кебек үк, татар теле дә үсештә, үзгәрештә яши. Шуңа бәйле рәвештә яңа үзгәрешләрне, төшенчәләрне белдерү өчен яңа сүзләр ясарга, кайбер чит сүзләрне тәрҗемә итәргә туры килә. Ләкин бу эш бар очракта да уңышлы бармый.

Узган гасырның 80 нче еллар азагында – 90 нчы еллар башында 1917 елга кадәрге вакытлы матбугатта кулланылган иҗтимагый-сәяси терминнар телебезгә янәдән әйләнеп кайтты. Әйтик, *җөмһүрият, мөхәррир, икътисад, инкыйлаб, ширкәт, ватанпәрвәр, әгъза, фирка, рәис* кебек терминнар шундыйлардан. Хәтта XX гасыр башында киң аудиториягә билгеле булмаган *икътисади, иганә* кебек сүзләр бүгенге матбугат текстларында иркен кулланыла башлады. Терминга әйләнгән бу сүзләр телебезгә гасырлар дәвамында кергән, татар теленең фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре нигезендә аңа яраклашканнар.

Бүгенге көндә дә татар теленең сүз ясалыш законнары нигезендә иҗтимагый-сәяси характердагы

яңа терминнар барлыкка килә тора. Болар бигрәк тә сәяси системадагы, икътисадтагы үзгәрешләр белән бәйле сүзләр: *илбашы, үзидарә, хакимият, торгынлык, эшкуар, алыпсатар, хосусыйлаштыру* һ.б.

Әйтергә кирәк, бу күренешнең берникадәр уңай ягы бар: телдә алынма сүзләр артык күбәеп китмәсен өчен, мөмкин булганда аларның кайберләрен туган телнең үз сүзләре яки халыкка якын башка алынмалар белән алмаштыру ярыйдыр. Ләкин тел ул – бик нәзакәтле, катлаулы нәрсә. Шуңа күрә аның белән сак эш итәргә кирәк.

Әлбәттә, вакытлы матбугат чараларының терминнарны яңартуда катнашуы җиңел генә бармый. Билгеле булганча, соңгы елларда татарча чыгучы газета-журналларның саны арта бара. Алар арасында төрлесе бар. Кызганычка каршы, кайберләрендә рус, башка чит телләрдән кергән сүзләр байтак очрый. Алар күп очракта бик урынлы кулланылмый. Югыйсә, әлеге алынмаларны кулланырлык үз сүзләребез дә җитәрлек бит. Ә кайбер матбугат чаралары рус, чит телләрдән кергән алынмаларны кулланмаска тырышып, гади халык сөйләменә бөтенләй ят, укучыга таныш булмаган сүзләрне кертә. Аларның күбесе саф татар сүзләре булмый, яисә искергән көндәлек сөйләмә телдән төшеп калган сүзләр була. Бу – терминнарны куллану өлкәсендә аңлашылмаучанлыклар китереп чыгара. Әмма кайбер каләм ияләре бу хакыйкать белән исәпләшергә теләмиләр.

Бай эчтәлекле, мәгънәле «Идел» журналының искергән, кулланылыштан чыккан сүзләрне (*моназара – диспут, гомсар – компонент, гамил – фактор, фикер хәяте – идеология*) тергезергә омтылуы аңлашылып бетми.

Кайбер газеталар, халыкка аңлашылмый торган сүзләрне куллану, аларны мәйданга чыгару буенча берсен-берсе уздырырга тырышалар сыман. Мәсәлән, «Әбүнәчеләр игътибарына», «Әбүнә вакыты башланды» дигәнче, «Газетага язылучылар игътибарына», «Газета-журналларга язылу вакыты башланды» дип язсалар, телебезгә нинди зыян килер иде икән? Хәзерге көндә «массакүләм мәгълүмат чаралары» дигән тезмәне дә «гаммәви мәгълүмат чаралары» дип яза һәм сөйли башладылар. *Профессионал* сүзен *һөнәрмәнд* сүзе белән алмаштыру да максатка ярашлы түгел. Профессионал үз эшен, һөнәрен бик яхшы дәрәҗәдә белүче кеше икәнлеге һәркемгә аңлаешлы бит.

«Шәһри Казан» газетасының 2007 ел, 25 август санында Госман Садәнең «Кулында каләм – каурый болыт» дигән мәкаләсе басылган. Язмадагы гарәп-фарсы алынмаларына килсәк, аларның күбесе урынлы кулланылган дияргә була. Ләкин бер кимчелеккә тукталмый мөмкин түгел. Әлеге сүз кулланылган җөмләне тулысынча китерәбез. «Әмма XX гасырда Балык Бистәсе *вилаятенең* дә татар мәдәниятенә күп саллы исемнәр бүләк итүен әйтергә кирәктер». *Вилаять* сүзенең аңлатмасы сүзлекләрдә «илдә эре административ-территориаль берәмлек, губерния, өлкә, ил, дәүләт», дип бирелә. Язылышында да аерма бар. Ә Балык Бистәсен без Татарстандагы бер район буларак беләбез. Мәкалә авторы бу очракта Балык Бистәсе районына карата *вилаять* сүзен урынлы кулланмаган.

Аңлашылганча, әлеге мәкалә мисалында гына да гарәп-фарсы

алынмаларының татар вакытлы матбугатында еш очравын әйтә алабыз. Аларның күбесе урынлы кулланыла. Ләкин кайбер очракларда алынмалар белән артык мавыгу, аларны тиешсез урында файдалану күзәтелә. Бу исә язманың тәэсир көчен киметеп кенә калмый, укучыны вакытлы матбугаттан читләштерә дә. Бөтенләй ят булган, мәгънәсе аңлашылмаган сүзләр кергән мәкаләне кемнең укыйсы килсен?! Кешегә кулына аңлатмалы сүзлек тотып укырдай мәкаләләр газета-журнал битләрендә азрак булсын иде.

Соңгы елларда массакүләм мәгълүмат чараларында татар телендә ныгып урнашкан алынма сүзләрне әйтү һәм язу нормаларын үзгәртү, ягъни татарчалаштыру күренешләре дә очрый. Әйтик, газета терминын «Татарстан яшьләре» – *гәҗит*, «Мәдәни җомга» *гәзит* дип кулланалар. Компьютер техникасына караган сүзләрне куллануда да эзлеклелек сакланмый. Газета-журнал битләрендә *компьютер, кампитер, санак, сан санак* вариантларын куллану очраклары еш кабатлана.

*Товар* термины кайбер матбугат чараларында *тауар* дип белдерелә. Газета-журналларда, хәтта мәктәп дәреслекләрендә дә *квартир* сүзе белән *фатир* сүзен бутап язалар. Норма буларак *квартир* сүзе кабул ителгән. Әмма, ни өчендер, гади сөйләм сүзе булган, әдәби телгә карамаган *фатир* сүзен кулланалар. Ф. Ганиев әйткәнчә, бу сүз арендага алынган квартирны гына белдерә.

*Презентация* сүзен еш куллана башладык. Газета-журналларда да шулай язалар, яки дөрес тәрҗемә итмиләр. *Презентация* – латин сүзе, татарча мәгънәсе – *тәкъдим итү, күрсәтү* фигыльләренә туры килә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: газета-журнал битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында, татар теленең тиешле төшенчәне белдерерлек үз сүзләре була торып та, чит тел сүзләрен кушып сөйләү, язу яисә татар теленең әйтелеш нормаларына яраклашкан, гасырлар буе кулланылып килгән сүзләрне үзгәртү очраклары шактый күп. Монда сүзләрне куллануның төп принцибы бозыла.

Алда зур бурыч – татар телен саклау һәм үстерү – торган хәзерге чорда, уйлап-нитеп тормыйча, телебезгә бөтенләй кирәксезгә йөзләрчә сүзләр кертү дөрес эш түгел. Әмма бер нәрсә бәхәссез: телнең үзендә кирәкле сүз була торып, аның урынына алынма сүз куллану гаять урынсыз.

Хәзерге милли-рус икетеллелеге шартларында тел, сөйләм культурасы, милли телнең сафлыгы мәсьәләләре үзәктә тора.

***Мөхәммәтшин Фәнис Мөхәммәтгали улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*«Н.И. Лобачевский исемендәге лицей»ның*
*(КФУ ның гомуми белем бирү мәктәп-интернаты)*
*югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

УДК 821.512.145

*Р.Р. Мусабәкова*

# Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘЛӘРЕ
## (шигырь исемнәрен тәрҗемә итү аспекты)

Статья посвящена анализу переводов названий стихотворений Г. Тукая при переводе их на русский язык. При проведении этого исследования автором было проанализировано несколько десятков стихотворений татарского поэта и вариантов перевода их на русский язык. Автор пытается дать объяснения тем или иным случаям переводов, предлагает свою интерпретацию.

**Ключевые слова:** стихотворение, поэзия, перевод, варианты, адекватность, буквализм, подстрочник, рифма.

Тәрҗемә кеше белән гомер бакый янәшә яшәп килде. Аның тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Тәрҗемә булган, ул бүген яши һәм киләчәктә дә яшәячәк. Тәрҗемә беркайчанда оригиналны кабатламаячак, чөнки, практика күрсәткәнчә, бу– аксиома. Ләкин һәр тәрҗемәче оригиналны мөмкин кадәр түкми-чәчми кабатлауга омтыла. Омтылу һәм булдыра алган хәтле аңа ирешү исә төрле факторлар белән бәйле. Тәрҗемә хакында төрле чорларда төрле карашлар, фикерләр йөрде. Алар бүген дә бар, чөнки камиллекнең чиге юк, ә тәрҗемә эше ул – чын мәгънәсендә бөек сәнгать [Миннибаев, с. 4].

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның иҗаты бүгенге көнгә кадәр тәрҗемәчеләрне үзенә җәлеп итә тора. Әйтерсең, тәрҗемәчеләр Тукай әсәрен рус теленә аударып, үзләренең осталыгын сынамакчы булалар. Әмма бу бөек иҗатка, билгеле бер дәрәҗәдә тәҗрибә тупламыйча якын килеп булмый. Шуңа күрә бүгенге көндә Тукайның барлык әсәрләре дә рус теленә тәрҗемә ителеп бетте дип әйтеп булмый. Бердән, әсәр тәрҗемәче күңелендә тәрҗемә итү теләген тудырырга, икенчедән, тәрҗемәченең осталык дәрәҗәсе аеруча югары (Тукайга «теше үтәрлек») дәрәҗәдә булырга тиеш. Бу эшкә алынучы, үзенә кадәр эшләнгән тәрҗемәләр белән канәгать булмыйча, әсәрне тагын да камилрәк тәрҗемә итү максатын куя. Шунысын да әйтмичә булмый, поэзия әсәрен фәкать шигырь яза белгән кеше генә тәрҗемә итә ала, димәк, тәрҗемәченең шагыйрь булуы уңышлы тәрҗемәгә ышанычлы адым, дигән сүз. (Тезмә әсәрне чәчмә итеп тә тәрҗемә итәргә була. Мәсәлән, мондый практика Франциядә киң таралган.) Тәрҗемә телен (бу очракта татар телен) камил белү дә, тәрҗемә сыйфатын бермә-бер арттыра, чөнки күпчелек очракта тәрҗемәче сүзгә-сүз (подстрочник) тәрҗемә белән эш итә. Димәк, сәбәпләр төрле. Шагыйрьнең аерым әсәрләре рус теленә берничә тапкыр (икедән алып бишкә кадәр) тәрҗемә ителгән.

Билгеле булганча, һәр тәрҗемә башкалардан аерылып тора. Төгәл фәннәр өлкәсендә генә ике икең дүрт була, тәрҗемәдә алай була ал-

мый. Тәрҗемә бик уңышлы килеп чыккан очракта да камил, адекват тәрҗемә барлыкка килде, дип әйтеп булмый, чөнки тәрҗәмә – ул барыбер югалтулар юлы. Гадәттә, йә форма (ритм, рифма) саклау бәрабәренә эчтәлек корбан итәлә, йә эчтәлек сакланып калган очракта, формага зыян килә. Бу, кызганычка каршы, тәрҗемә практикасының кануны. Бигрәк тә, шигъриятне тәрҗәмә итү турында сүз барганда.

Тәрҗемәчеләрдән оста, тәҗрибәлеләр сафында, беренче чиратта, П. Радимов, Р. Моран, С. Липкин, С. Ботвинник, В.Тушнова, С. Северцев, О. Дмитриев, В. Звягинцев, Д. Бродский, К. Липскеровларны атап үтәргә кирәк. Татарлардан Тукай иҗатына соңгы елларда, В. Ганиев, Р. Бохараев, Н. Әхмәров, В. Думаева-Вәлиева еш мөрәҗәгать иттеләр.

Аларны күзәтү кызык кына нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Күзгә беренче ташланганы – ул тәрҗемәдәге шигырь исемнәре. Беренче карашка, гадәттә бер-ике сүздән торган шигырь исемен тәрҗемә итү, бик гади генә эш кебек тоела. Ләкин аермалар нәкъ менә шуннан башлана да инде. Түбәндә китерелгән мисаллар моңа ачык дәлил булып тора.

Мәсәлән, Тукайның «Хатыннар хөррияте» (1909) шигыре исемен В. Тушнова, оригиналга тәңгәл итеп, «Свобода женщин» дип бирә, Л. Руст исә лозунг рәвешендә «Дорогу женщине!» дип тәрҗемә итә. Бер караганда, сүз бер үк күренеш турында барган кебек, ләкин аерма сизелерлек. Икенче исемдә басым һәм эмоция үзен нык сиздерә. Димәк, оригинал текст тәрҗемәчеләргә төрлечә тәэсир иткән. Менә тагын бер мисал. «Эш» (1909) шигыре исемен В. Думаева-Вәлиева туры һәм гади генә «Работа» дип тәрҗемә итә, С. Липкин исә аны «Дитя, работай!» дип боеру формасында бирә.

Кайбер очракта ике сүздән торган шигырь исемендә сүзләр, нигәдер, урыннары белән алышыналар. Мәсәлән, «Чын вә ялган» (1908) шигырен К. Липскеров һәм Н. Әхмәров оригиналдагыча «Правда и ложь» дип калдырса, В.Думаева-Вәлиева исә аларны «Ложь и правда» дип, урыннарын алыштырып куя. «Ай һәм кояш» (1919) шигыренең дүрт тәрҗемәсе бар. Туры тәрҗемәне «Луна и солнце» дип В. Думаева-Вәлиева гына тәкъдим итә, «Солнце и месяц» дип А. Королев һәм Н.Әхмәров тәрҗемә итәләр, С. Ойслендер исә «ай» сүзен «луна» дип бирә. Охшаш мисалның тагын берсе: «Яңгыр вә кояш» (1909) шигырен Вл. Соколов «Дождь и солнце» дип, ә С. Образович «Солнце и дождь» дип тәрҗемә итә. Нигә кирәк булды икән бу тәрҗемәчегә? дигән сорау туа. Бу очракның логикасын аңлау кыен, әлбәттә.

Аерым очракларда ике сүздән торган шигырь исемендә бер генә сүз калдырыла. Мәсәлән, «Дин вә гавәм»не (1912) М. Акчурин тулысынча «Религия и толпа» дип тәрҗемә итә, К. Липскеров һәм Н. Мальцева «Религия» сүзе белән генә чикләнәләр. Һәм менә киресенчә, «Шагыйрь вә һатиф» (1906) шигыренең исемен Л. Озеров төгәл генә итеп «Поэт и голос» дип тәрҗемә итә, Н. Әхмәров исә үзеннән бер сүз өстәп куя «Поэт и небесный голос».

Менә тагын бер кызык мисал. «Арба, Чана, Ат» (1910) шигыренең дүрт исемдәге тәрҗемәсе бар: «Арба, Сани и Лошадь» (С. Ганиев), «Арба, Сани и Конь»

(Л. Руст), «Лошадь, сани да арба» (Н. Әхмәров) һәм көтелмәгән очрак дәрәҗәсендә Алёна Кәримова аны «Судьба» дип тәрҗемә итә. Бу, билгеле, төгәллек төшенчәсеннән артык ерак китү, дип бәяләнә, һәм оригиналны тәрҗемә белән чагыштыру ихтыяҗы туган очракта, шактый кыенлыклар тудыра, чөнки шигырь исеме әсәрнең эчтәлегеннән чыгып тәрҗемә ителгән. Тагын шундый бер мисал. «Дәрдемәнд дәгелмием?» (1906) шигыренең тәрҗемәсен эзләп табу җиңел булмады, чөнки тәрҗемәдә Дәрдемәнд исеме юк: «Разве я не скорбящий!» (Г. Пагирев), «Не я ли тот, кто скорбит?» (Р. Моран). «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» (1913) фәкать В. Ганиев тарафыннан гына «Великий юбилей и связанные с ним чаяния народа» дип, төгәл тәрҗемә ителгән, Р. Бохараев һәм С. Липкин аны «На русской земле» дип, Н. Әхмәров «Надежды народа» дип бирәләр. Шушы ук күренеш «Кәҗә белән Сарык хикәясе»ндә дә (1909) күзәтелә. Р. Бохараев «Сказка про Козу и Барана», Н. Әхмәров «Сказка о козе и баране» дип тәрҗемә итәләр, ә П. Радимов кыскартылган «Коза и баран» варианты белән чикләнә. Билгеле, бу эш фәкать тәрҗемәченең үзеннән, аның теләгеннән тора. Бәхеткә каршы, андый очраклар әллә ни күп түгел.

Кайбер очракларда, тәрҗемәдә хаталар да очрап куя. Мәсәлән, «Сөеклемнең кабер ташында» (1906) шигырь исемен В. Тушнова гына дөрес итеп «Надпись на могильном камне» дип тәрҗемә итә, А. Ойслендер һәм Н. Әхмәров «Надпись на памятнике любимой» дип бирәләр. Памятник татар теленә һәйкәл дип тәрҗемә ителә, ләкин Тукай заманында татар каберенә фәкать таш кына куела торган булган. Шушы ук категориягә «Бер шәехнең мөнәҗәте» (1908) шигыре исеме тәрҗемәсен дә өстәп була, чөнки В. Любинның аны «Песнопение шейха» дип тәрҗемә итүе А. Чепуровның «Кодекс одного шейха»сыннан дөресрәк һәм уңышлырак килеп чыккан.

Аерым очракларда шигырь исемнәре сизелер-сизелмәс нюанслар белән генә аерылып торалар. Мәсәлән, «Авыл халкына ни җитми?» (1912) шигыре «Чего же не хватает сельскому люду? (С. Северцев), «Чего не хватает сельскому люду?» (В. Думаева-Вәлиева), «Чего еще не хватает сельскому люду?» (В. Цвелев) дип тәрҗемә ителә; шулай ук «Хәстә хәле» (1913) – «Больной» (Д. Бродский), «Участь больного» (Н. Мальцева); «Юк итәрсеңме?» (1906) – «Ужель погубишь?» (Г. Пагирев), «Уничтожишь ли меня?» (Р. Моран) һ.б.

Кайвакыт бер үк шигырьнең исеме төрле җыентыкларда төрлечә басыла, мәсәлән, «Поезд барган көйгә» (1911) шигыре Р. Моран тәрҗемәсендә «На мотив хода поезда» һәм «Под перестук вагонных колёс» дип, яки «Актык тамчы яшь» (1910) шигыре А. Тарковский тәрҗемәсендә «Последние слёзы» һәм «Последние капли слёз» дип, «Шәйтанның муенына» (1908) шигыре Н. Әхмәров тәрҗемәсендә «Пускай смеется» һәм «Пусть смеется» дип бирелә.

1913 елда «Кыйтга» исеме белән язылган ике шигырь исемнәрен тәрҗемә итү дә шактый кыенлык тудырган. Мәсәлән, «Мәктәп»нең 20 апрель санында басылганын В. Думаева-Вәлиева «Кытга» дип калдыра, ә В.Ганиев һәм Н. Әхмәров «Отрывок» дип бирәләр. «Аң»ның 1 март

санындагы икенче «Кыйтга»ны өч тәрҗемәче дә шигырьнең исеме итеп аның беренче юлларын тәрҗемә итәләр, ләкин өчесенеке өч төрле: М. Львов «Сил своих на черный день...», Н. Әхмәров «Не сберег я сил на черный день...», Л. Рустныкы исә «Про черный день» дип атала һәм шигырьнең махсус исеме итеп кабул ителә.

Тукайның 1907, 1908, 1910, 1911 елларда язылган «...га» исемле дүрт шигыре бар, шуларның 1908 һәм 1911 елларда язылганнары гына тәрҗемә ителгән. Билгеле, андый исемдәге шигырьнең исемен тәрҗемә итү проблема тудыра. 1908 елдагысын В. Бугаевский һәм Н. Әхмәров «Ей» дип тәрҗемә итәләр, В. Думаева-Вәлиева «К... (совет)» дип бирә. 1911 елда язылганын Н. Сидоренко һәм Н. Мальцева «К...» дип тәрҗемә итәләр, Н. Әхмәров «К***» дип бирә.

Еллар дәверендә гыйбарәгә әйләнгән «Тотса мәскәүләр якаң» (1908) шигыре исемен В. Думаева-Вәлиева, төгәл тәрҗемә ясап, «Если Москва возьмет за воротник» (1908) дип тәрҗемә итә, С. Ганиев исә, гыйбарәнең мәгънәсен кинәйтеп, «Если в Москве тобой займутся...» дип бирә. Күпмәгънәлелекне шигырь исеменең күп нокталарга тәмамлануы белдерә.

Тагын бер мисалга тукталыйк. «Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә?» (1906) шигыре исемен Р. Моран «Где муллы, что хотят омусульманить Японию?» дип тәрҗемә итә, В. Думаева-Вәлиева «Где ученые, которые омусульманят Японию?» дип бирә. Татар кешесендә галим белән мулла сүзләре синоним булып йөриләр. Рус кешесе өчен алай ук түгел.

Г. Тукайның «Син булмасаң!» (1907) шигырен өч тәрҗемәче тәрҗемә иткән, исемнәрен В. Тушнова «Если бы ты не была...», В. Микушевич «Когда бы ты...», Д. Бродский «Если б не был тобой приневолен» дип бирә. Боларның кайсы отышлырак, дигәндә, сайлап алуы кыен, чөнки өчесе дә шигырьнең эчтәлегенә дә, исеменә дә туры килә. Шулай ук «Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә» (1906) шигыре исеменең дә ике төрле варианты бар: С. Ботвинник һәм Н. Шәмсетдинов «Нашей молодежи, устроившей литературный вечер» дип тәрҗемә иткәннәр, С. Липкин исә «Юношам, организовавшим литературный вечер» дип бирә. Миңа калса, икесе дә уңышлы килеп чыккан. Шулай ук уңышлы мисаллар рәтенә «Өмидсезлек» (1910) шигыре исеменең тәрҗемәләрен кертергә була. Ул «Отчаяние» (С. Серевцев) һәм «Безнадежность» (Н. Мальцева) дип тәрҗемә ителгән.

Аерым очракларда тәрҗемәче шигырь исемендә өлешчә татар сүзләрен калдыра. Мәсәлән, «Туган авыл» (1909) шигыре исемен В.Тушнова «Родная деревня» дип, ә Р.Сәйдәшева «Родной аул» дип тәрҗемә итәләр. Икенче тәрҗемәче рус кешесенә авыл (аул, аил) сүзе таныш дип фаразлаган күрәсең. Чыннан да, бу сүз рус кешесенә күптән таныш, һәм киң кулланылышта йөри.

Гомумиләштереп әйткәндә, тәрҗемәләрне чагыштыру, тәрҗемәче лабораториясен күзәтү кызык кына нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә, һәм бу иҗади эшнең никадәр катлаулы икәнен аңларга ярдәм итә.

## Әдәбият

*Габдулла Тукай.* Избранное. Казань, Татар. кн. изд-во, 1978. 271 с.

*Габдулла Тукай.* Стихотворения, поэмы и сказки. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 415 с.

*Габдулла Тукай.* Стихотворения и поэмы. М.: Советский писатель, 1988. 431 с.

Тукай. Новые переводы. Перевод Н.Ахмерова. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1994. 53 с.

Габдулла Тукай. Перевод Н.У. Ахмерова. Казань: Таң-Заря, 1996. 31 с.

Габдулла Тукай. Избранное. Перевод В.С.Думаевой-Валиевой. Казань: Магариф, 2008. 223 с.

Казань. 2000. № 4.

Татарский мир. 2004. № 6–7.

Советский медик. 1990. 8 июня.

Советская Татария. 1987. 26 апреля; 1990. 22 апреля.

Казанские ведомости. 1995. 26 апреля; 2006. 26 апреля.

Известия Татарстана. 1994. 26 апреля.

***Мусабәкова Рәисә Рәшит кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Татар энциклопедиясе институтының өлкән фәнни хезмәткәре,*
*e-mail: musabekova@rambler.ru*

УДК 821.512.145

***Ф.Ф. Хәсәнова***

# РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН ШИГЫРЬЛӘРЕН ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье автор предлагает свои наблюдения в области литературного перевода стихов Р. Файзуллина.

**Ключевые слова:** афоризмы, моностих, медитативная лирика, успешный перевод, японский стих, стих-этюд, мастерство переводчика.

Равил Фәйзуллинның «Мәңгелек мизгел» китабыннан [Фәйзуллин, 2012] «Бер җавапка дүрт сорау» шигыре, исемен укыгач ук, укучыда бәхәс тудыра. *«Очкан килеш калырмы кош күк йөзендә?» – «Юк!» – дим. «Гел торырмы буй җиткән кыз ата нигезендә?» – Тагын «юк». «Менә алырмы һәр теләгән – шәп ияргә? Бер гомер җитәрме сине сөяргә?»* Җавап шул ук. Менә шундый фәлсәфи дүртьюллык шигырь. «Мәңгелек мизгел» китабы шундый дүртьюллык шигырьләрдән башланып китә. Китап ике телдә язылган. Шагыйрьнең кереш сүзе дә бар. Ул, күпме кереш сүз язып та, бу юлы нык дулкынлануын яшерми. Сәбәбе тәрҗемәдә булса кирәк.

Р. Фәйзуллин үзе, кыска шигырьне балачактан бирле яздым, ди. Аның «Җил – Вакыт ул…» [Фәйзуллин, 1996] китабына 600 ләп кыска шигырь тупланган иде. Шагыйрь, бар галим-тәнкыйтьчедән уздырып, аларның жанрын да билгеләгән: «парчалар, мәкальгә тартым тәгъбирләр, этюд-картиналар, табышмак элементлары булган сентенцияләр, робагыйлар, берәр хикмәткә ишарә ясаган ассоциатив чагыштырулар, көтелмәгән контрастка яки ярымкинаягә корылган тапкыр тезмәләр...»

Заман хәзер афористик фикерләүгә тартыла бара. Әзер җөмләләрне ятлыйсың да вакыты белән урынын сайлап кулланасың. Халык мәкальләре кебек. Акыл, тәҗрибә, фикер, мораль дә ачык. Татарда «борынгылар сүзе» дигән тәгъбир яшәп килә. Р.Фәйзуллинда ул «Картлар сүзе»нә әйләнә. Исеме шулай булган шигырь болай яңгырый:

*Ике хәзинә бар дөньяда:*
*саклагыз!*
*Каберстан аның берсе.*
*Гел гөлдә булсын!*
*Китапханә – икенчесе.*
*Күңелдә булсын!*
*Базар болай да калыр...*

Һәркемнең тел очында гына йөргән фикерләр. Хакыйкать – барыбыз да беләбез. Шулай да, шигырьдәге кебек үтемле итеп әйтү өчен, Р. Фәйзуллин кирәк булган. Шигырьдәге ике «аксиома» да шәрехләүгә мохтаҗ түгел. Әмма базар... монда инде кем ничек булдыра! Шигырьнең В. Бәширов тәрҗемәсендәге русча «игезәге» дә бик уңышлы чыккан. Автор шигыре сөйләм интонациясенә корылса, тәрҗемәдәге шигырь янәшә рифмалары белән

көнчыгыш робагыйлары формасына «утыртылган». Әмма юллардагы иҗек санының 10 нан гына торуы төрки гарузга кереп җитә алмый туктап калуны күрсәтә (димәк, чын робагыйга килеп җитә алмаган). Биредә төрки телләргә хас булмаган янәшә тартыкка башланган сүзләр «эшне боза» дип уйлыйк.

*Слова мудреца*
*Два клада драгоценных сохрани! –*
*Кладбище предков и собранье*
*книг!*
*Живи, святые ценности любя!*
*Базар не пропадет и без тебя...*

Әдәбият теориясе буенча, шигырьдә бер мизгел эчендәге хис урын алырга тиеш. Хисси шигырьдә бу шулай. Ә фикри шигырьдә? Дөрес, һәрбер шигырьдә дә хис һәм фикер катнаша. Хикмәт аларның пропорциясендә. Дүртьюллык «Җан исәбе алу»ны сәясәт белән бәйләп карау дөрес булыр: кыска шигырьнең икеюллык эпиграфы шуңа этәрә.

*Кемгәдер сан исәбе...*
*Кемгәдер җан исәбе...*
*Кемгәдер кан исәбе!..*
*...Ә синең ни исәбең?*

Монда сүзләр артык. Гомумән, Р.Фәйзуллин шигырьләрен анализлау кирәк микән? Шигырьгә зыян килер кебек. Нәкъ бу шигырьне аңламаган кешегә Р. Миңнуллинның «Татарларым!» оран-поэмасын укырга киңәш итәсе генә кала. Әлеге поэмада «сан алу» дип аталган сәяси вакыйганың татар халкына юнәлтелгән бөтен барлыгы ачып салына. Шуңа да Р. Фәйзуллинның чираттагы «Сарыкларны санаганда...» шигыре теманың дәвамы буларак кабул ителә.

Дүртьюллыклар арасында медитатив лирикага кагылганнары да очрый. «Мин ашыкмыйм» шигыре шундыйлардан. Ә менә шигырьнең В.Рощектаев тәрҗемәсе медитатив лирика интонациясеннән ераклашкан. Тәрҗемәдә хис юкка чыккан. Нәтиҗәдә – коры шигырь.

Дүртьюллыкларның коры афоризмга охшашлары да очрап куя. Шундыйлардан «Кыен бәхет кошын тоту, оя кору. Кыенрак – тоткач, коргач саклап тору»ны мисалга китерү дөрес булыр. Бу очракта тәрҗемәче М. Аввакумованың, афористик фикерне «киендереп», образлы шигырьгә өстенлек бирүе күренә.

«Бер күзәтү» шигыре үзе бер романга җитәрлек эчтәлекне чагылдыра. Уйландыра. Халык педагогикасы да күзәтүләрнең дөрес булуын раслый, әйтелгән фикер тормыш тәҗрибәсе белән дә исбатлана. Әйе, ятимлек кешене гомер буе озатып йөри. Шагыйрь сүзләре белән ныгытсак, болай килеп чыга:

*Таяну кыен ятим үскәнгә,*
*Сынаган бар яшен-картын да:*
*Җил кая иссә – ул шул якка ава,*
*Кайда җылы – шуңа тартыла...*

Ә менә А. Руденко тәрҗемәсендәге «Наблюдение» автор фикерен биреп җиткермәгән кебек тоела. Ятим үскән кешедә үз нәселе белән кызыксыну теләге көчлерәк тә булырга тиеш бит. Русча вариантта тулы гаиләдә үскән кеше дә күзаллана ала. Ә Р. Фәйзуллинда бу нечкәлекләр исәпкә алынган.

«Аңладым да...» шигыре – Көнчыгыш төсмерләре чагылган фикер шигърияте мисалы. Фәлсәфи фикер биредә робагый интонациясе белән дә көчәйтелә. М. Ав-

вакумова тәрҗемәсе шагыйрь фикерен төгәл дип әйтерлек дәрәҗәдә чагылдыра алган. Автор шигырь исемендә әйтеп бетермәү алымын файдалана. Монда артык сүз кирәкми дә, татар кешесе болай да аңлаячак. Шигырьнең русча вариантында исемгә нәкъ менә шул әйтелеп бетелмәгән сүз өстәп куелган.

*Аңладым да...*

*Акыл белән чаманы гел аңладым.*
*Тик шуны хисемә*
*аңлата алмадым.*
*Чеби чакта*
*филне екмак булып йөрдем.*
*Арыслан чагым җиткәч,*
*чебен ауладым.*

*Понял, но... поздно*

*Разум и Веру всегда почитал я.*
*Только напрасно их примерял я.*
*Шел на слона желторотым*
*цыпленком.*
*В льва превратившись,*
*мух истреблял я*

«Портрет» исемле шигырьдән совет чынбарлыгы «карап тора». Тексттан яңа заман җилләре китергән яшәешкә өмет һәм ышаныч югалу, материаль проблемалар, рухи төшенкелек, хәтта инфляция белән девальвация сәясәте дә күренеп тора. Нәкъ менә шуны аңлау тәрҗемәче А. Руденкога исемне «Старик» дип куюга китергәндер дә. Безнеңчә, автор фикере тәрҗемәдә төгәл чагылыш тапкан.

«Бергә чакта» шигыренә дә уйлану рухы хас. Шигырьне русчага Р. Кутуй тәрҗемә иткән. Уңышлы килеп чыккан. Әмма тәрҗемәдәге шигырь – исемсез. Р. Фәйзуллинның кыска шигырьләрендәге төп үзенчәлек чагылмаган, аның хәтта берьюллыклары исемле бит. Шигырь исеменә бик зур вазифа йөкләнә. Р. Фәйзуллинда ул тагын да көчәйтелә. Уңышлы дип саналган тәрҗемәнең шул җитешсезлеге аркасында кыйммәте кими төшә.

Аннан Р. Фәйзуллинның дүртьюллыклары япон шигыре үзенчәлекләрен дә чагылдыра. Аларда сүзне экономияләү, мәгънә тыгызлыгы, конкрет фәлсәфи фикер, гомуми иҗек санының 30 тирәсендә булуы күренә. Һәрбер шигырь билгеле бер этюдны хәтерләтә. Ә менә рус теленә тәрҗемәдә аз сүз белән күп мәгънә бирә алу сакланып бетмәгән дигән тәэсир кала.

Шагыйрь китапның икенче бүлегенә сигезьюллыклар урнаштыра. Тышкы формасы ягыннан әлеге шигырьләр ике яки өч строфалык итеп төзелгән, исеме булганнары да, исемсезләре дә бар. Болар да, нәкъ дүртьюллыклар кебек, эпитетларсыз гына язылган, ягъни фикергә өстенлек бирелеп, сүзнең тәэсир итү көченә таянылган. Андый шигырь автологик алымга нигезләнә. Югары фикер поэзиясенең бер үзенчәлеге инде бу. Шагыйрь нигездә шигырьне фигыль кулланмыйча яза. Язганнары рәсемне хәтерләтә, этюд-шигырь буларак кабул ителә. Шундыйларның берсе «Август. Авыл. Төнге бакча» дип исемләнеп, җәяләр эчендә тагын бер атама алган. Анысы «Тансык тынлык» дип куелган. Шигырьдә табигатьнең кабатланмас бер манзарасы сурәтләнә.

*Шундый тынлык!*
*Ишетелә кебек*
*Пәрәвезнең ятьмә үргәне!*
*Машиналы шау-шу заманында*
*Табигатьнең тансык бер мәле.*

*Чалкан ятып карыйм*
*төнге күктә*
*Йолдызларның талгын күчешен.*
*...Кинәт алма төште.*
*Сискәнмәдем.*
*Әйтерсең ул – тынлык җимеше.*

Русчага тәрҗемәдә М. Аввакумова шигырьнең исеменә үк үзгәреш кертә. Бакчаның «төнге булуы» югала, әмма икенче бер ачыклык кертелә: бакча, авыл янында «урнаша» да, алма бакчасы булып тәгаенләнә. Р.Фәйзуллинның лирик герое «пәрәвезнең ятьмә үргәнен ишетсә», тәрҗемәдә «пәрәвезне үрмәкүч үрә». «Пәрәвезнең ятьмә үрүе»н ничек аңлатырга да белмәссең. Бәлки, автор башта үрмәкүч пәрәвез үрә, аннан соң, шул пәрәвез ятьмә кебек нык була, дип әйтергә теләгәндер. Бу матур җөмлә аңлашылып бетми, шуңа тәрҗемәче төзәтә, дип кабул итик. Ни генә булса да, тәрҗемәдә Р. Фәйзуллин шигыренә хас гармония сакланып җитмәгәнлеген тану кирәктер.

Конкрет эчтәлекле шигырьләр тәрҗемәгә җиңел бирелә. «Шәһәрдә – авылныкы мин…» – шундыйлардан. Р. Кожевникова башкарган тәрҗемә төгәл килеп чыккан, башкача булмас кебек. М. Аввакумова тарафыннан башкарылган «Төнгә мәдхия» шигыре дә уңышлы гына күренә. Тик соңгы ике юл оригиналдан читкәрәк киткән. «Калам дөньям белән икәү ялгызлык кочагында!» – ди автор. Ә тәрҗемәдәге өч юл «Чудесно одинок… Когда струится по ногам Вселенной сквознячок…» булып чыккан. Р. Фәйзуллинда образлылык көчле: төн, ялгызлык кочагы. Көчле ярашу сизелә. Ә тәрҗемәдә төнлә «Бөтендөнья аягы»на үтәли җил сарыла. Безнең татарда төнлә җил тына иде…

Ә менә «Туктармы?» шигыре П. Серебряков тәрҗемәсендә рифма төрен дә саклап кала алган, хәтта аларны төрләндерүгә ирешкән, катлауландырган да.

***Туктармы?..***

*Җил – исүеннән туктармы,*
*Җилкән корганга карап?*

*Чирәм – үсүдән туктармы,*
*Очын кырганга карап?*

*Су – хәрәкәттән туктармы,*
*Буып куйганга карап?*

*Адәм – көрәштән туктармы,*
*Иреген тыйганга карап?..*

***Разве так будет?..***

*Уткнется ветер в паруса –*
*Но разве станет он покорней?*

*Пройдется по лугу коса –*
*Но разве луг утратит корни?*

*Перегородят русла рек –*
*Но разве остановят воды?*

*Смирится разве человек –*
*Когда лишат его свободы?*

Күренеп торганча, Р.Фәйзуллин шигырьнең исемен дүрт юллык строфаның һәр беренче юлы рифмасында градация рәвешендә кабатлап бара. Шигырьдәге икенче катлаулы рифма да, беренче компоненты гына үзгәреп, 4 тапкыр кабатлана. Шигырьдә куелган сорауларга җавапның «юк!» рәвешендә булуы, чиксезлеккә ишарә ясалган сорауларның кабатланып килүе, рифманың да шул тәртиптә сайлануын уңышлы килеп чыккан дип санарга кирәк.

Русча вариантка игътибар итсәк, «паруса – коса», «покорней – корни», «рек – человек», «воды – свободы». Аннан шунысын да искәрми калып булмый: рус телендә башта шарт килә, аннан соң гына шул шарттан сорау килеп чыга; шагыйрь шигырендә, объектны актуаль позициягә чыгарып, сорау формалаштырыла, сорауның сәбәбе ахырдан килә. Бу, билгеле, татар теленең синтаксис законнарыннан чыгып шулай эшләнелә.

Бик тирән мәгънәле, ирония-кинаяле, гармонияле яңгырашлы янәшә рифмалы шигырьләрнең берсе «Яшәлгән бит, кичелгән бит гомерләр!» дип атала. Биредә үткән гасыр башы да, репрессия чорлары, тоталитаризм да, дин сәясәте дә чагыла. Шигырьдә эзоп теле, киная, ирония дә бар. Рус теленә тәрҗемә дә бик төгәл, яхшырак итеп әйтеп булмас та шикелле. Әмма рифма системасы үзгә. Шуңа да Р. Фәйзуллин тарафыннан башта ук уйланылган интонация килеп чыкмаган, гәрчә В. Хәмидуллина аралаш рифмалар кулланса да.

Китапның 3 нче бүлеге җырларга багышлана. Биредә шагыйрьнең күптәннән халык теленнән төшмәгән «Аккошлар» җыры кебек популяр җыр текстлары да урын алган. Таныш шигырьләрне укыйсың да, шундук В. Кузнецов тәрҗемәсе белән чагыштырасың. Менә берсен игътибар беләнрәк карыйк әле:

*Кер чайкыйлар кызлар,*
*Тезләрендә – Кояш!*

*Полощут девушки белье*
*И складывают в ведра.*
*А солнце рыжей кошкой льнет*
*К их загорелым бедрам.*

Дөрес, елгада кер чайкау күренеше инде үзе үк тарихка кереп калды. Хәзер керне машина үзе уа, үзе юа, үзе чайкый һәм киптерә. Сиңа машинадан алып, элеп куярга гына кала. Кер юу тәртибен кинолардан карап өйрәнергә генә калды. Шигырьдә бу күренеш («мизгел» дип әйтергә тел бармый, мизгелдә генә эшләп булмый моны!) кызларның кояшта уйнаган ачык тезләре белән көчәйтелә. Шигырьдә «ялтыраган тезләр» детале башта һәм ахырда килә. Шуңа әлеге детальнең әһәмияте зур икәнлеге бәхәссез. Көнкүрешнең гади бер детале шагыйрьнең оста итеп тотып алган шул поэтик образлыгы нәтиҗәсендә шигырьгә әйләнә дә куя. Матур күренеш килеп чыга. Ә «тәрҗемәдәге кызларның» күлмәге бөтенләй юк, йә бик кыска, йә башка нәрсә кигән. «Бёдра» күзәткән кеше татар шагыйре булмас инде… Монда В. Кузнецов башкача тәрҗемә итә алмагандыр, нишлисең, «вёдрага» «бёдра» туры килеп тора, дип уйлыйсың. Безгә тәрҗемәдә татар менталитеты юкка чыкканлыгын танудан башка юл да калмый.

Тәрҗемә эшенең гаять кыен булуы башка шигырьләрне укыганда да күренә. Күңелгә Р. Фәйзуллинны төгәл тәрҗемә итеп булмый, ахры, дигән уйлар килә. Тәрҗемәчеләр менә дигән бит. В. Кузнецов бик күп татар шагыйрьләрен тәрҗемә иткән оста шагыйрь. Алыйк менә «Шатлыгы киләме бүген?..» дигән шигырьне.

*Шатлыгы киләме бүген?*
*Әллә кайгысы килә?..*
*Нигә әле бу уй башта?*
*Кыр казы исе килә!*

*Бу яз көнне, аяз көнне*
*Сөя, назлыйсы килә!*

*Җаны йокымсыраганнарга:*
*«Терел! Яз!» – дисе килә!*
*Бардыр... Бәлки, кемнәрнеңдер*
*Кабер казыйсы килә...*
*Бу чакта ничек үлим соң –*
*Кыр казы исе килә!*

***Журавлиный ветер***

*Мир бурлит, звенит вокруг,*
*Мир от нежности хмелеет.*
*Отчего такое вдруг?*
*Журавлиный ветер веет!*

*Журавли домой спешат,*
*К незабытому гнездовью.*
*Просыпается душа,*
*Загорается любовью.*

*Кто опасную игру*
*Затевать сегодня смеет?!*
*Как я в этот день умру?! –*
*Журавлиный ветер веет!*

Сүз дә юк, Вадим Кузнецовның шигыре бик матур яңгырый. «Тәрҗемә бу», дип әйтергә тел дә әйләнми. Автор шигыре дә түгел. Эш менә нәрсәдә. Татар халкы өчен каз – ул ит яки мендәр мамыгы гына түгел. Каз – йорт казы булмасын, кыр казы булмасын – ул символик мәгънәгә ия кош. «Каз канаты» җырыннан башлап, күпме көй язылган, уеннар уйналган. Шуңа татар шагыйрьләренең казга багышлап язылган күпсанлы шигырьләре бар. Р. Фәйзуллинның үзенең дә бар андый шигыре. Ә безнең шигырьдә төп мотив – яз исе – каз исе. Р. Фәйзуллин шигырендә менә шул татар менталитеты ярылып ята. Ә «Журавлиный ветер» татар шигыре түгел, Р. Фәйзуллин шигыре тәрҗемәсе дә булып чыкмаган. Дөрес, торна да безгә ят түгел, гәрчә татар халкы «һавадагы торнага өметләнеп, кулыңдагы чыпчыкны очырма» дисә дә. Алай дисәң, М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә»сеннән соң, анысы да якын була башлады...

Татар язучылары әсәрләре бүгенге көндә, туган тел белән генә чикләнеп калмыйча, рус, төрек, инглиз телләренә тәрҗемә ителеп, әдәбият өлкәсендә көннән-көн зуррак мәйдан яуларга омтыла башлады.

Дөньяның төрле якларына сибелеп яшәгән татарны эзләп табу, телен онытып бара торган татар баласының милли хисләрен уятып җибәрү максатыннан тәрҗемә әсәрләрне тәкъдим итү заман өчен кирәкле күренеш, билгеле. Бу эш әле киң колач җәеп җибәрә алмый. Тәрҗемә процессы бик күп көч, осталык сорый. Болар өстенә тәрҗемә ителә торган материалның милли эчтәлекле дә, нәфис тә, тапталмаган яңа да булуы мөһим. Проза әсәре булса, яңа сюжет, яңа герой тәкъдим итеп булыр иде. Ә шигырьдә? Бары тик яңа образ, яңа форма, үзенчәлекле ритмик система, йә булмаса яңа жанр гына уйлап чыгарырга мөмкин.

Татар шигърияте – үзенә генә хас традицияләре, тирән тамырлары булган зур тарихлы шигърият ул. Егерменче гасырның 60 нчы елларында булып узган «икенче шартлау»дан соң (Р. Фәйзуллиннар буыны истә тотыла), 90 нчы еллардагы сәясимилли-тематик үзгәрешләрдән соң (Р. Гаташ һ.б.), XXI гасыр башында нинди дер яңалык тәкъдим итү – бу инде шигъри батырлык саналырга хаклы күренеш.

Без бу язмабызда Р.Фәйзуллинның икетелле «Мәңгелек мизгел» исемле саллы китабының яртысына да җитмәдек. Шигырьләр күп. Һәрберсе тәрҗемә

ителгән. Һәр шагыйрь – үзе бер дөнья. Аны башка кеше тәңгәл итеп кабатлый алмас. Р. Фәйзуллин кебек, татар шигырендә революция ясый алган шәхесне бигрәк тә. Монысы – мәсьәләнең бер ягы булса, икенчесе тәрҗемә эшенең бик катлаулы эшчәнлек булуын күрсәтә. Бу өлкәдә эшлисе эш бик күп әле...

**Әдәбият**


*Фәйзуллин Р.Г.* Мәңгелек мизгел: шигырьләр = Вечность мгновения: стихотворения. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 287 б.

*Фәйзуллин Р.Г.* Җил – Вакыт ул… Казан: Мәгариф, 1996. 287 б.



***Хәсәнова Фәридә Фирдәвес кызы,*** *филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге җитәкчесе*

*e-mail: farida.5656@mail.ru*

УДК 821.512.145

*Р.Ф. Харрасова*

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «АДӘМНӘР» ФАҖИГАСЕ

Основной замысел «трагедии в прозе» «Адамы» («Люди») Г.Ибрагимова был в том, чтобы показать природные инстинкты человека, просыпающиеся в определенных нечеловеческих условиях. В повести сильный голод толкает героев к нарушению общественных и религиозных правил поведения. В голодные годы, до этого, казалось бы, очень нравственные, честные, добрые, мягкие советские люди становятся преступниками. Это приобретает массовый характер. Голод доводит детей Адама до людоедства, пишет Г.Ибрагимов. В основе трагедии общественo-социальный, а также нравственный конфликты, которые могут быть разрешены только сверху – выверенной внутренней политикой и принятыми мерами органов власти. Повесть «Адамы» рассказывает о невосполнимых утратах человеческих ценностей и тем самым утверждает веру в настоящего человека, который не переступит порог нравственности даже паеред лицом неминуемой смерти.

**Ключевые слова:** история литературы, трагедия, повесть, Г.Ибрагимов.

Г. Ибраһимовның 1921–1922 елларда Идел–Урал буйларындагы ачлыкны сурәтләгән «Адәмнәр» повесте инсанда, билгеле бер шартларга куелганда, үз-үзен саклау инстинктының көчәюен, хәтта ерткычларныкы дәрәҗәсенә күтәрелүен күрсәтә. Яшәү белән Үлем арасында көрәш барганда, кайберәүләрдә җәмгыять тәрбияләгән сыйфатлар, инанулар юкка чыга, һәм алар үзләрен кыргыйларча тота башлыйлар, ди автор. Әсәргә куелган исем, әйтерсең, тарихны кирегә әйләндерә һәм безне Кешелек яратылган чорга алып кайта. Ул, Адәм балаларының, ни өчен дөньяга килүләрен онытып, илаһилыкка омтыласы урынга, хайванилыкка таба атлауларына ишарәли дип тә әйтергә булыр иде. Кыскасы, «фаҗига»дә кешенең һәм иҗтимагый продукт, һәм табигать баласы булуы, анда яшеренеп яткан эчке кыргый хисләнекләр, көчләр бөтен тулылыгы белән ачыла, әнә шуңа күрә Адәмнәр сүзе ике мәгънә яссылыгына ия символик төшенчәгә әверелә дә.

Повестьның тәүге абзацы символ дәрәҗәсенә үстерелгән Үлем тасвиры рәвешендә оеша. «Үлем үзенең кара канатларын җәйде»,– ди Г.Ибраһимов. Каберлекләр, ләхетләр, җанлы мәетләр, хәлсез шәүләләр әлеге үлемнең чагылышы булып тора. Үлемнең кара кош рәвешендә тудырылуы барлык мәдәниятләрдә дә очрый. Кош – Адәм белән тыгыз бәйләнештәге символ, ул аның һәм тормышның ак-кара якларын чагылдыра ала, әмма әдип моның өчен әлеге образга кат-кат әйләнеп кайтмый. Шул ук вакытта Г. Ибраһимов «фаҗига»не шулай ук капма-каршы төшенчәләрнең берлеге принцибына кора. Без Кешенең Эчен-Тышын, Яшәү һәм Үлем арасындагы көрәшен, Чынбарлык һәм Хыял шартларына куелуын, Ак һәм Кара сыйфатлардан торуын күрәбез.

Алар арасында баланс югалдымы, адәм баласы һәлакәткә таба атлый башлый. Әйтик, үлчәү тәлинкәсендә тискәре яклары басып киткәндә, ул Инсан булудан туктый һәм Җанварга әверелә.

Кара төстәге кошлар хаос һәм караңгылыкны, акыл һәм хәтерне дә белдерә. «Адәмнәр»дә бу төшенчәләр һәрберсе тирәннән, вакыйгалар ярдәмендә ачыла. Әсәр башында әле үз агышыннан чыгып бетмәгән авыл-ил тормышы ахырга таба бөтен тәртибен югалта, буталчык, караңгы, билгесез, хәвефле бер яшәешкә әверелә. Һәркем һәр яктан үзенә Үлем янаганны аңлый, аннан ничек тә качарга, хәтта башкалар хисабына котылу турында уйларга керешә.

«Адәмнәр» укучыны иң элек Галим карт белән таныштыра, бераздан әсәргә Намаҗан һәм башка геройлар килеп керә. Игътибар үзәгенә куелган персонажларның бер-бер артлы сюжетка тартылуы һәм, үлү сәбәпле, вакыйгалар чылбырыннан төшеп калуы бик табигый бара. Дөрес, алда танышкан образлар, икенче персонажларга бәйле, хәтердә әледән-әле яңара. Г.Ибраһимов үзәккә аерым бер геройны куймый, Адәм төшенчәсе белән гомумиләштерелгән каһарманны чыгара. Әдип тасвирлаган һәркем әлеге образны тудыруда катнаша, шуңа күрә әсәр «Адәмнәр» дип исемләнә дә.

Язучының таланты шул дәрәҗәдә зур ки, фикерләү ноктасының еш кына үзгәрүе дә, игътибарда тотылган геройларның алмашынуы да үзен артык сиздерми, укучы бу хакта хәтта уйламый. Әлбәттә, әсәр Гәрәйнең һәм баласының үлеме белән тәмамланганга, Гәрәй гаиләсенә бәйле күренешләр күбрәк булганга, кемдер төп герой сыйфатында аны кабул итәргә һәм повесть бер гаилә тарихы рәвешендә оеша дип тә санарга мөмкин.

Г. Ибраһимов, «Адәмнәр»е белән, безгә шуны ачык аңлата: нинди генә шартларда да Кеше Кеше булып калырга тиеш. Һәм язучы шунда ук сорау да куя: ә бу реальме соң? Ачлык еллары вакыйгаларыннан чыгып фикер йөртсәң, юктыр кебек. Г. Ибраһимов, ул еллар белән генә чикләнмәскә, безне башка чорлар, эш-хәлләр хакында да уйландырырга телидер, әлбәттә. Гомер буе хәерчелектә яшәгән халыкның зур Күтәрелешләргә, Түнтәрелешләргә, Үлемгә һәм Үтерүгә баруы бик табигый, дип әйтә кебек әдип. Чишелештәге авылга ризык кайту күренеше белән ул, һичшиксез, «Ач үлемнең куркусы»ннан бары тик Совет власте башкарган чаралар гына коткарды, дигән фикерне уздыра. Бүгенге укучы Идел–Урал буйларында ачлык котырынуга хакимият алып барган эчке-тышкы сәясәтнең дә сәбәпче булуын белә инде, һәм ерак узгандагы вакыйгаларга башкарак күзлектән бәя бирә.

Повестьта ачлыкның чын иҗтимагый-сәяси сәбәпләре турында фикер йөрттерерлек урыннар да бар. Г. Ибраһимов, игътибарлы укучының табып алачагына ышангандай, аларны артык калкулатмый; илне камап алган ачлыкның, хәерчеләнүнең тарихын геройларның тәрҗемәи хәле белән бәйләп сөйли. Әйтик, Гәрәй хакында Г. Ибраһимов болай дип яза: «Гәрәй заманында тырышлык белән көн итүче адәм иде. Көтелмәгәндә Герман сугышына кудылар, үзе теләп, акларга каршы ике ел фронт кичерде. Эшләрлек ир-ат булмаганга

йорт җимерелде, мал калмады, шуңа күрә аның утын китерергә дә чамасы булмады. Ул быел кыш буенча үзенең абзарларын, өй түбәләрен якты. Хәзер бер нәрсә дә калмаган иде». Шул ук вакытта җәмгыять барышына коммунистик идеологиядән чыгып караган Г. Ибраһимов, хәтта ике төрле сугышка халыкта ике мөнәсәбәт булган кебек күрсәтә: кешеләрне берсенә мәҗбүри алганнар, икенчсенә алар ихтыярый киткән.

«Адәмнәр»дә совет хакимиятен ак буяуларда тасвирлауның икенче сәбәбе дә бар дип уйлыйк: соң дәрәҗәдә куркыныч илкүләм афәт хакындагы әсәрне, совет хакимиятенең халыкны исән калдырачак ризык олаулары кайтарган көнен тасвирламаганда, бастыру мөмкин булмас иде. Икенче яктан, аның билгеле бер максатлар куеп тудырылган натуралистик тасвирларын, сәнгатилек ноктасыннан түбән бәяләп, тәнкыйть тә кире кагар һәм әдәбият мәйданына юлын шулай ук бикләр иде. Хәер, «Адәмнәр»нең озак елларга киңкатлам укучы күзеннән еракка яшерелүендә бу сәбәпләр мөһим роль уйный да.

Повесть укучыга ясаган тәэсир көченең зурлыгы тәфсилле тасвирга барып тоташа. Чиркандыргыч хәл-күренешләрне, эш-гамәлләрне өс-өстенә өеп, язучы хайвани тотышка карата нәфрәт уята, шәхсән җәмгыятьнең паразит дип санаган катламнарыннан күңелен кайтара. Шул ук вакытта без хакимияткә хезмәт иткәннәрнең дә нормалардан тайпылышлы эш-хәрәкәтләрен күрәбез. Аларда ашау теләге шулай ук барыннан өстен; авылда тамырланган җинаятьчелек проблемасы һичкемне артык борчымый, җинаятьчеләрне табу турында шуның өчен җаваплы оешмалар да кайгыртмый. Мондый шартларда кеше ашу күренеше илкүләм төс ала бара.

Повестьтан аңлашылганча, Ачлык Үлеме канат җәйгәндә, бар кешене бер төрлерәк язмыш сагалый. Һәркем белеп тора: үлсә, мәете күмелмәячәк, әле баштарак кайдадыр – ябык ишекле келәт эчләрендә череп ятачак, аннан ул – этләргә, соңрак – кешеләргә ризык булачак. Г. Ибраһимов «Адәмнәр»дә акыл-аңга ия җан иясенең экренләп таркалуын, кешелек сыйфатларын югалта баруын бигрәк тә Гәрәй образы аркылы күрсәтә. Табигый инстинкт булган ашау теләге арткан, үзе физик көчсезләнә барган саен, инсанның фикерләү сәләте кими, аңы томалана, һәм ул хәтта баласын ашарга сәләтлегә әйләнә, ди автор. Әле кайчан гына кеше ашаучыларга каршы көрәшкән, дус-ишен, балаларын, танышларын Ач Үлем тырнагыннан соңгы ризыгын бүлешеп саклаган Гәрәй тора-бара кызы Нәфисә белән улы Зәйнигә дә ит сыйфатында гына карый.

Гәрәй – үзгәрешләр ноктасыннан фикер йөрткәндә, башка персонажлар арасында шактый үзенчәлеклесе. Ул тәүдә уңай герой буларак кабул ителә, соңыннан аны ничек бәяләргә белмисең. Әдип укучыны алдарак тасвирланган вакыйгаларга әйләнеп карарга еш мәҗбүр итә. Әйтик, Гәрәйнең кешелектән чыгуы «гаептә тотылган» авылдашларына җәза биргән, корал күтәреп барган көннәргә барып тоташа. Ачлыкка түзәр хәле калмагач, тирә-яктагы ерткычлыклардан күзе томалангач, ачуы ка-

барган һәм реаль сугышта каршы якны кызганмаска күнектерелгән Гәрәй, бераздан, икмәге бар килеш тә аны бүлешмәгән һәм күпләрнең сыйнфый дошманы кебек кабул ителгән, икейөзле, азгын Намаҗан картны үтереп, ризык табуны дөрес дигән фикергә килә. Шул ук вакытта автор аның кыргый, кешелексез адымнарны гаделлекне торгызу өчен ясамавын, үз-үзен саклау инстинкты белән башкарганын аңлата алган. Хәтта Гәрәй кебек әхлаклы кешеләрдәге рухи таркалыш илкүләм фаҗиганең бөтен тирәнлеген күрсәтә.

«Адәмнәр»дәге кайсы гына образга тукталсаң да, бертөсле генә бәя бирү кыен. Бер карасаң, каты бәгырьле күренгән Намаҗан карт та, ачлык елында кирәксез әйберләрен аз бәягә алып булса да, бик күпләрнең гомерен саклап калган, мәчет юлларын карап тота, үлекләргә мөнәсәбәте дә миһербанлырак. Ачлыктан тилмергән авыл халкы өчен болар инде мөһим түгел, ул, аның ризык ашавын белеп, эчтән ярсый. Ач, язмыш һәм җәмгыять тарафыннан кыерсытылган кешеләрдә һәрвакыт башкаларның байлыгын тартып алу, үч теләге көчле була.

Кан коюны дошманнарыннан һәм үзенә хезмәт иткән җан ияләреннән – этләрдән, мәчеләрдән башласа да, Гәрәй туктала алмый, ахыр чиктә үзе тудырган балаларга да кул суза. Дөньяда чын мәгънәсендә җанварлар һәм адәмнәр арасында барган көрәш, шулай итеп, кешеләрнең һәм бер токымнан булган хайваннарның үз арасына күчә. Г. Ибраһимов бу көрәш турында Актырнак исеменнән дә сөйли: «Ул моннан байтак вакытлар элек, Намаҗан карт белән талаша-талаша, Галим картның эчен-бавырын ашап, үзен бер ныгытты. Аннан соң атналар буенча эзләнеп йөрде. Бүген басу киртәсе төбендә кемдер төнлә үлеп калган икән, иснәнеп йөргәндә, шул яктан җил килде, аның зирәк борыны шунда ук бер нәрсә сизенде, адәмме, малмы, аера алмады, ләкин анысы барыбер иде: ит бар, кан бар, ризык бар. Тиз шул якка чапты, барса, җүнләп туңып та җитмәгән, шешенгән бер гәүдә – адәм гәүдәсе ята. Ашыгып эчен ярды, өзгәли башлады, ул арада әле үлеп бетмәгән башка этләр дә килеп җиттеләр. Үзара талаш башланды. Мәгәр үлек зур иде, вакытны әрәм итмәстән, ачу белән бер-берсенә ырылдаша-ырылдаша булса да, төрле яктан кимерделәр...»

Г. Ибраһимов, Гәрәйнең соңгы көннәре турында тасвирлап, әхлаксызлык гамәлләренең чын кеше күңеле, җәмгыять өчен эссез үтмәвен һәм җәзасын алуын күрсәтә. Гәрәйнең авылга ризык кайткан сәгатьтә яктырып киткән аңы анда яшәү теләген тәмам үтерә. Кылган гамәлләрен бөтен тирәнлеге белән аңлаган ата кеше үз-үзенә кул сала. Шулай итеп, Гәрәйнең бу адымга баруы автор тарафыннан һәм психологик, һәм социаль мотивлаштырыла.

Сюжет төрле каршылыкларны бер сызыкка сала, көчәйтә, үзара бәйли бара. Иман һәм имансызлык кебек күренешләр анда чиратлашып килә. Нинди генә вакыйганы һәм шул вакыйга барышында аерым бер геройның адымын тасвирламасын, уй-фикерләрен җиткермәсен, Г. Ибраһимов, адәмнәр туклыкта нинди булыр иде? дигән сораугa җавап биреп бара. Кемдер ачлыктан котылу турында уйлаганда,

икенчеләрдә җенси теләкләр котыра, берәүләр кызларын ризык хакына ир-атларга сатканда, иманлылар аларны үз өенә сыендыра... Тук тормыш акны – ак, караны кара янына куя.

«Адәмнәр» контрастлар, янәшәлекләр алымы белән иҗат ителә. Әдип «Адәм балалары»ның тормышын исемле геройлар кергән күренешләр янәшәсендә бирә. Укучы караңгы буяулы башлам белән чагыштырмача яктырак бетемгә, бүлек башламнарының үзара төрлелегенә, геройларның аңлы һәм аңсыз адымнарына, иманлылык һәм имансызлыкны чагылдырган күренешләрнең янәшә килүенә игътибар итә… Шул төрле чиратланышлар инсанның ике өлештән торуын ассызыкларга ярдәм итә дә. Әсәрдән ачык күренә ки, үзара мөнәсәбәтләрнең ниндидер кануннарга нигезләнүе, электә ныгыган әхлакый сыйфатлар гына Адәм балаларын кыска вакыт аралыгында, көн, атна, айлар эчендә, түбән тәгәрәүдән саклап тора, авырлыклар озакка китсә, җәмгыятьтә кабул ителгән нормалар барыбер җимерелә.

Г. Ибраһимов, чынбарлыкта хәлләр үзе тасвирлаганнан да яманрак булса да, иман дигән төшенчәне бөтен җаны-тәне белән ризык кайтачак көннәргә кадәр яшәтергә тырышкан шикелле тоела. Шул ук вакытта ул, авылны исән калдырырлык ризык китертелгәнне сурәтләгәннән соң да, әсәргә ачлыкка бәйле күренешләрне кертүдән туктамый. Аның өчен әле яңа гына чагыштырмача ныклы тормыш алып барган гаиләнең тәмам юкка чыгуын күрсәтү мөһим. Бу илнең дә таркалып бетәргә мөмкинлеге турындагы уйларга этәрә.

Повесть тамамланырга тиеш кебек булгач, атасы Гәрәй тырнагыннан качып, шәһәргә килеп егылган Зәйнинең үлеп тә бетмәгән тәненнән пилмән ясап саталар. Әсәрнең фаҗигаи тәэсире шул урында бермә-бер көчәя. Иң чиста күңелле, иң яшәргә сәләтле һәм шуңа җаны-тәне белән омтылган малайга үлемнең инде авылдашлары ачлык тырнагыннан котылгач кына килүе соң дәрәҗәдә тетрәндерә.

* * *

«Адәмнәр»дә антитеза алымының бөтен мөмкинлекләре ачыла. Ул кешеләр характерын тудыруда да, күренешләрне тасвирлауда да, каршылыклы хисләрне җиткерүдә дә, чынбарлыкка төрле мөнәсәбәтләрне чагылдыруда да... файдаланыла, сюжет-композиция алымы булып та тора.

«Адәмнәр» повестен укыганда, Үлемнең үзен күргәндәй буласың. Кылыч борынлы, таралып төшкән чәчле корткалар, пычак тоткан ач күзле ирләр... – һәммәсе төрле диннәрдәге һәм ышанулардагы Үлем образының Җирдәге чагылышлары булып тора. Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» повестенда, аерым бер кешенең рухи таркалуы гына да Кешелек җәмгыятен бетүгә таба илтәчәк, дип искәртә, шул ук вакытта хәтта үлеп баручы җанда да яшәүгә омтылышның нинди дәрәҗәдә зур икәнлеген әйтә. Әсәрнең фаҗига дип аталуы да юкка түгел, чөнки анда Үлем һәм Яшәү кебек югары метафизик проблема чишелә.

«Адәмнәр» әсәре белән Г. Ибраһимовның әйтергә теләгән иң мөһим фикере шулдыр: безнең камилләшүгә таба барган юлыбыздан түбәнлеккә таба атлап китүдә бер адым сагалый. Шуны атладыңмы – әхлак канун-

нарын бер боздыңмы – инде син инсаннарга хас барлык башка сыйфатларны югалтырга мөмкинсең. Кешенең әшәкелек потенцияләре шуңа тиешле шартлар тудырылганда баш калкыта, димәк, адәм балалары андый шартлар тумаслык, бары тик яхшылык чәчәк атарлык җәмгыять төзәргә тиеш, ди автор.

***Харрасова Рифә Фәтхрахман кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең баш фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145:811.162.1

*Гжегож Червинский*

# БҮГЕНГЕ ПОЛЬША ТАТАРЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ ПРОБЛЕМАЛАРЫ ХАКЫНДА

Данная статья является введением в проблематику современной польско-татарской литературы. На сегодняшний день среди этнических групп в Польше татары являются одними из самых малочисленных. Тем не менее, культура польских татар непрерывно развивается. Художественная литература польских татар является конгломератом западноевропейской и азиатско-мусульманской традиций, и ее изучение позволяет сделать ряд интересных заключений. Объектом исследования являются произведения выдающихся татарских писателей и поэтов междувоенного периода польской литературы (1918–1939), литературы Польской Народной Республики (1945–1989), а также современная польско-татарская поэзия.

**Ключевые слова:** польские татары, польско-татарская литература, ислам в Восточной Европе, Якуб Шинкевич (1884–1966), Леон Найман Мирза Крычинский (1887–1939), Муса Чахоровский (р. 1953), Селим Хазбиевич (р. 1955).

Татарлар Бөек Литва кенәзлегенә XIV гасырда күчеп урнаша башлыйлар. Алар, нигездә, Алтын Урдага каршы хәрби походлар оештырган Литва гаскәрләре тарафыннан әсирлеккә төшерелгән яки Литва, Польша (Речь Посполитая) җирләрендә сыеныр урын эзләп килгән татарлар булганнар. 1359 елда Бирдебәк хан үтерелгәннән соң, Урдада озак еллар дәвамында хакимлек өчен көрәш бара, Татар дәүләтенең хакимнәре еш алышына. Ә инде, бу бәрелешләрдә җиңелгәннәр илдән чыгып качарга мәҗбүр булган [Tyszkiewicz..., 2002]. Шуның нәтиҗәсендә аларның кайберләре Литва җирләренә килеп урнаша [Tyszkiewicz..., 2002]. Урдадан килүче татарлар Литвада хәрби хезмәт үтәргә тиеш булалар, ә инде анда иреклe килеп урнашучыларга шляхта титулы бирелә [Tyszkiewicz..., 2002]. Татарларның руслар белән сугышларыннан соң, анда Казан, Әстерхан ханлыкларыннан да качаклар килә башлый. XV–XVI гасырларда татарларның күпчелеге Вильно, Гродно, Ковно, Минск һәм Новогрудек шәһәрләре районнарында яши [Tyszkiewicz..., 2002, st. 15–16]. Бөек Ватан кенәзлегенә һәм Польша җирләренә килеп урнашкан Польша-Литва татарлары, караимнар кебек, хәзерге татар һәм Кырым татарларының нигезен тәшкил иткән кыпчак теленең төрле диалектларында сөйләшәләр [Borowski..., 1986]. Яңа җирләрдә яши башлагач, алар үз телләрен оныта, ассимиляцияләшә башлыйлар, әмма ислам динен саклыйлар [Borawski..., 1986. st. 257]. Польша-Литва татарлары йә белорус, йә поляк телен үз итәләр. Бүген инде алар өчен поляк теле уртак булып санала.

Хәзерге вакытта Польшада татарлар этник төркемнәрнең иң аз санлысы булып исәпләнә. Аларның саны 3-4 меңнән арт-

мый. Азсанлы булуына карамастан, бу этник төркемнең мәдәнияте һәм әдәбияты даими үсешкә ия. Аларда борынгы чорларда ук гарәп шрифты белән поляк һәм белорус телләрендә язылган тарихи кулъязмалар саклана [Łapicz…; Тарэлка..., Akiner…; Drozd…, 1994; Katalog…]. Алар, нигездә, дини характердагы текстлар. Кулъязмалар арасында матур әдәбиятка караган текстлар да бар. Тарихчылар Бөек Литва кенәзлеге татарларын Польша-Литва татарлары дип атыйлар. Ә менә 1918 елдан башлап, Польшада яшәүче татарларны Польша татарлары дип атау дөресрәк кебек, бу аларны Кырым татарларыннан, шулай ук Идел буе татарларыннан аерып карарга да җайлырак итәр иде [Miskiewicz...]. Шуңа күрә әлеге этник төркемнең XX гасыр әдәбиятын, «Польшада татарлар әдәбияты» урынына, «Польша татарлары әдәбияты» дип атау дөрес булачак [Czerwinski ..., 2012; 2013]. Чөнки, беренчедән, авторларның зур күпчелеге Польша мәдәнияте җирлегенә ярашып формалашкан, икенче яктан, алар, милләт буларак, үзләрен Польша татарлары (поляк-татар) дип саныйлар [Warminska…; Łyszczarz….].

XX гасыр Польша татарлары әдәбиятын өйрәнеп тикшерү – хәзерге әдәбият белемендә шактый яңа юнәлеш. Польшада чыгышы белән татар милләтеннән булган язучылар һәм шагыйрьләр алай ук күп түгел. Әйтик, репортаж һәм эссе кебек жанрларны да кушып исәпләгәндә, Польша татарларының әдәби текстлары саны сизелерлек арта. Бүгенге заман Польша татарлары әдәбиятына караган, поляк телендә язылган әсәрләрдә Польша-Европа мәдәни элементлары да, төрки мөселманнарныкы да киң чагылыш таба. Поляк укучыларына мондый «чиктәш» иҗатның асылын аңлау кайвакытларда кыенлык тудыра. Польша татарларының матур әдәбияты мәдәни рухтагы тәрҗемәгә мохтаҗ [Czerwinski..., 2012; 2013]. Шуңа күрә, мондый әдәбиятны тикшереп анализлау өчен, төрле өлкәләрдә эшләүче, аеруча, бер яктан – поляк һәм славян телләре, шулай ук, икенче яктан – төрки телләр һәм гарәп теле филолог-белгечләренең хезмәттәшлеге таләп ителә. Мондый хезмәттәшлекнең максаты – XIX һәм XX гасырлар поляк әдәбиятын анализлау процессында тупланган тәҗрибә белән һәм төрки, гарәп һәм фарсы поэзиясен, Үзәк Европа мөселман фәлсәфәсен (барыннан да бигрәк суфичылыкны), шулай ук Бөек Дала цивилизациясе варислары булган халыкларның традициясе варислары булган халыкларның традицияләрен өйрәнеп тикшерү барышында тупланган тәҗрибәләр белән уртаклашудан гыйбарәт [Гумилев..., 1970]. Польша татарларының Икенче Бөтендөнья сугышыннан соңгы әдәбияты, аерып әйткәндә, иң заманча әдәбияты Көнбатыш Европа һәм Азия мөселманнары традицияләренең кушылмасын тәшкил итә. Анда, бер яктан, Европа модернизмы, сугыш алды поляк поэзиясе, «хәтер археологиясе», Юнг психоанализы, Хайдеггер экзистенциализмы, ә икенче яктан, хәзерге Европа алымнары белән Көнчыгышның борынгы традицияләре диалогы, суфичыл ислам, Гомәр Хәйям һәм Җәлалетдин Руми поэзиясе, татар-монгол күчмәләре мирасы белән шаманлык йолалары чагылыш таба.

Польша татарлары әдәбияты Беренче Бөтендөнья сугышыннан

соң динамикалы үсеш ала. Ул вакытта Польша татарларының мәдәни үзәге Вильнада (хәзер: Вильнюс) урнашкан була. «Zycie Tatarskie» («Татар Тормышы») журналы да шунда дөнья күрә, анда мөселман дөньясына, ислам илләренә сәяхәтләр турында репортажлар һәм хатирәләр күп басыла. Алар арасыннан Якуб Шинкевич, Али Исмаил Воронович, Эдиг Шинкевич язмалары аеруча кызыксыну уята. Леон Мирза Крычинскийның Вильнада нәшер ителә торган көндәлек басма – «Słowo» («Сүз») басмасында Мароккога сәяхәте турында репортажы чыга. Кызганычка каршы, бу язмада иң танылган әсәрләрне генә анализлау белән чикләнергә туры килә. Түбәндә Я. Шинкевич белән Л. Крычинскийның, кыскача формада гына булса да, мәкаләләре һәм үзләре хакындагы мәгълүматлар китерелә.

Якуб Шинкевич (1884–1966), Берлин университетының фәннәр докторы, 1926 елдан Польша мөселманнары мөфтие, Мисырда уздырылган Бөтендөнья мөселманнары съездында (1926) катнаша, башка илләрдәге мөселман җәмгыятьләре вәкилләре белән халыкара элемтәләр урнаштыра. Мөфти Төркиягә, Фәләстыйнга, Сүриягә, Ливанга, Болгариягә, Югославиягә сәфәр кыла. Көнчыгыш телләренең берничәсендә иркен сөйләшә алуы аңа үзе булган илләрнең мәдәнияте белән якыннан танышырга ярдәм итә. Фашистлар кул астында калган елларда ул Остланд немецлар мөфтиятен җитәкли, литвалылар һәм немецлар хакимиятләре белән хезмәттәшлеккә риза була. 1944 елда Я. Шинкевич Германиягә китә, аннан – башта Мисырга, ә 1956 елда Америка Кушма Штатларына эмиграцияләнә.

1930 елда Якуб Шинкевич 18 марттан 18 июньгә кадәр (дүрт ай дәвамында) Мисырда, Хиҗазда, Сүриядә, Палестинада була. Бу сәфәрнең иҗади нәтиҗәсе итеп ул «Сәфәр турында хисап» («Sprawozdania z podrozy») репортажын яза [Szynkiewicz..., 2013]. 1936 елда Якуб Шинкевич Көнчыгыш Һиндстанга сәяхәт кыла. Аның бу хактагы истәлекләрен без «Татар тормышы» («Zycie Tatarskie») журналыннан укый алабыз [Szynkiewicz..., 2013]. Репортажларының икесе дә, укучы әсәр белән әкренләп таныша барсын өчен, басмаларда кисәпләп, дәвамлы итеп бирелгән.

Якуб Шинкевич, Польша мөселманнары җәмгыяте җитәкчесе буларак, әлеге илләргә Польша хөкүмәте вәкиллеге составында бара. Шуңа күрә аның бу сәфәре турындагы әсәре формасы белән гомуми максатларга буйсындырыла. Әмма Польша мөселманнары мөфтиенең рәсми сәфәр турында «Татар тормышы» журналында басылып чыккан ике репортажы да үзенә бер әһәмияткә ия: сәфәр хисабы турында гына язарга алынса да, ул кызыклы һәм сәнгати югарылыктагы әсәрләр иҗат иткән. Шул ук вакытта бу хезмәтләрдә автор стиленең үсеш процессын күзәтергә була. Язма Каһирәдә сәясәтчеләр һәм журналистлар белән очрашуны тасвирлауга нигезләнгән рәсми отчет рәвешендә башланып китә. Аның мөһим элементы итеп, авторның Польша хөкүмәте һәм Польша мөселманнары файдасына Мисырның зыялылары, танылган шәхесләре арасында «пропогандистлык» эшчәнлеге турындагы мәгълүматларын билгеләп үтәргә кирәк. Якуб Шинкевич репортажы текстына, фрагментлар рәвешендә, үзенең шәхси

күзәтүләрен һәм тәэсирләрен дә өсти. Бу хезмәтне тикшереп өйрәнүчеләр игътибарын аеруча авторның Хиҗазда[1] булуы, король ибне Согуд тарафыннан кабул ителүе һәм Мәккә белән Мәдинәгә баруы, табигый чүлнең кырыслыгы, төрле дәрәҗәдәге социаль катлау кешеләренең яшәешен күзәтүе турындагы фрагментлары җәлеп итә. Я. Шинкевичның Каһирәдәге мәчет манарасында символик азан әйтүе (репортаж авторы яңа манарадан беренче булып азан әйтүче була), шулай ук аның Көнчыгыш Халыкара Берләшмәсе әгъзалары алдында Польша мөселманнарынча Коръән укып күрсәтүе дә аерым игътибарга лаек.

«Сәяхәт турында хисап» дигән хезмәтендә Я. Шинкевич сөйләүче, вакыйгаларны тасвирлаучы сыйфатында чыгыш ясый. Укучы, Хиҗаз короленең тормышы, автор булган шәһәрдәге халык көнкүреше, Мәккә һәм Мәдинәдәге изге урыннарда яки Хиҗазның табигый чүлләрендә булу тәртипләре (кагыйдәләре) белән танышканда, еш кына, тексттаның аерым урынга яки билгеле бер вазгыятькә карата искәрмәләре (тәнкыйди карашлары) белән очраша. Я. Шинкевич текстында аның үзе булган илләр яки регионнар турында өстәмә мәгълүматлар бирелми, тасвирлама фәкать сөйләүченең (авторның) үз карашларына һәм тәэсирләренә генә нигезләнә. Р.Капущинский яки В.Ягельский кебек хәзерге заман поляк авторлары әсәрләре контекстында карaганда, бу бүгенге укучы өчен сәер булып тоелырга мөмкин. Сугышка кадәрге поляк репортажларын яки XIX гасыр – XX гасыр башы әдәби сәяхәтнамәләрен (Мельхер Ванькочив, Аркады Фидлер, Ксаверы Прушинский, Фердинад Гетель) укучы өчен Хиҗаз яки тексттагы башка шәһәрләрнең гомуми күренешен тасвирлауга омтылыш булмау әллә ни гаҗәп тоелмый.

Польша мөфтие су юлы белән Хиҗаз башкаласы Җиддәгә килә, 27 апрельдә шәһәр читенә юнәлә, ибне Согуд яраннары (мөритләре) аңа тукталырга тәкъдим итәләр. Юлда дала пейзажына игътибар итә. Иң элек Я. Шинкевич портта эленеп торган шаһадәле[2] – мөселманлыкны раслаучы әләмгә фикерен юнәлтә. Ул Исламның ваххабчыл асылын аңларга тырыша, аны исламның европача, либеральрәк булган концепциясе белән чагыштыра. Шинкевич Хиҗазда Тышкы эшләр министрлыгы вәкилләре белән Польша мөфтие вазифасында үзенең король ибне Согуд белән очрашуы нинди характерда булачагы турында сөйләшә. Шул вакытта ул аларга Польша президентының хатын, Польша турында китаплар һәм илнең картасын тапшыра. Ике ил вәкилләренең беренче рәсми очрашуы вакытында Шинкевич Польша президенты хатын полякчадан гарапчәгә тәрҗемә итә, гарәпләр короленең рәсми җавабын тыңлаганда, аны бик игътибар белән күзәтә һәм аның хакында репортажында болай дип яза:

Król siedział i słuchał nas spokojnie. Na twarzy jego odbijał się majestat, spokój, a w oczach wielki rozum. Ubrany był skromniej, niż jego otoczenie, bo miał na głowie zwyczajną kolorową chustkę, jaką noszą prości żołnierze i jeno podtrzymujące ją zwoje były za złotych nici, na ramionach płaszcz biało-żółtawy: na nogach – nic. Wówczas kiedy

p. Raczyński był w lakierkach, ja w żółtych półbucikach, a otoczenie królewskie w skarpetkach (obuwie zdejmuje się przy wejściu) – sam król bosy. Wzruszający był widok, kiedy przyszedł Kajmakam Dżeddy, staruszek siwowłosy i król na jego spotkanie podniósł się z miejsca, a starzec pocałował go w czoło między oczy.

*Король утырган хәлдә безне тыныч кына тыңлый. Аның йөзендә даһилык һәм сабырлык чагыла, ә карашыннан бөек гакыллылык бөркелә. Ул үз даирәсендәгеләрдән дә тыйнаграк киенгән: башында гади солдатларныкы сыман гадәти, төсле яулык (тик яулыкны тотып тора торган кысасы гына алтын җепләрдән эшләнгән), җилкәсенә аксыл-сары төстәге япанча салган, ә аякларында бернәрсә дә юк. Рачинский әфәнде лакланган аяк киеменнән, мин – сары туфлиләрдән, ә король даирәсендәгеләр оекбашлардан (кергән җирдә аяк киемен салып калдыралар), король үзе яланаяк иде.*

*Корольнең Җәddә каймакамы белән очрашуы аеруча дулкынландыргыч узды: Җәddә каймакамы – чал карт – килгәндә, король, аны каршылап, урыннан торды, һәм карт корольнең кашлары арасындагы маңгаеннан үпте* [Szynkewicz..., 2013].

Бу фрагмент мөфтинең, һичшиксез, әдәби таланты булуын раслый: ул теләсә кайсы очракның күзгә күренмәс детальләрен тотып алырга сәләтле, аның «каләме җиңел», «Хисап»ны хикәяләгәндә ул бу жанрга хас булган стильдән ерак тора. Автор фикеренчә, репортажның берничә фрагментында татарларның үзенә бер тарихи миссия үтәргә тиешлеге ассызыклана: ул да булса, Европа һәм ислам дөньялары цивилизацияләрен тоташтыручы чылбыр ролен үтәү. Польша татарлары мәдәнияте белән дөньяга традицион гарәби карашлар кисешкән ноктада без мөселман мәдәниятенең кайсы сыйфатлары гомум дини принципларга таянуын, ә кайсылары гарәпләрнең исламга кадәрге мәдәнияте калдыклары[3] булуын бик тиз тоябыз. Я. Шинкевич әйләнә-тирә дөньяны башка мәдәниятләр күзлегеннән кабул итәргә сәләтле шәхес. Ул Польша хакимияте белән Польшада яшәүче христианнар[4] арасындагы яхшы мөнәсәбәтләр турында даими яза, бер үк Аллага табынучы кешеләрнең үзара нәрсәдер бүлешеп яшәве түгел, аларны берләштерүче детальләрне табарга омтыла. Я.Шинкевич текстларында күтәрелгән темалар ике сугыш арасында иҗат иткән татар эшлеклесе Ольгер Крычинский[5] публицистикасында дәвам иттерелә.

Король аудиенциясеннән соң икенче көнне Я. Шинкевич хаҗ кылырга Мәккәгә китә. Аның истәлекләрен – европалы тарафыннан исламның изге урыннарына аяк басу турында иң сирәк тасвирламаларның бирсә, һәм поляк телендә дә беренче хезмәт, дияргә кирәк. «Хисап»ны укучы мөселманнар Мәккәгә хаҗ кылу процессындагы барлык элементларны да анда катнашучы кебек үк күзаллау мөмкинлегенә ия була, чөнки Польшадагы мөселман булмаган башка язучыларның китапларында аны очрату мөмкин түгел.

Мәккәгә сәфәр башлануга ук ул Гарәбстан табигатенең Европада аның турында сөйләгәннәрдән бик нык аерылуына игътибар итә.

Każdy z nas wyobraża sobie Arabię jako pustynię, a w rzeczywistości jest to step w wielu miejscach pełen życia. Nawet ptaki śpiewają.

*Гарәбстанны безнең һәркайсыбыз чүл дип күзаллый, ә чынлыкта ул дала икән, бик күп урыннарында тормыш кайный. Хәтта кошлар сайрый* [Szynkewicz..., st. 93].

Бу тасвирлама текстта аеруча мөһим функция үти, чөнки автор Европа цивилизациясе вәкиле буларак билгеләнә («безнең һәркайсыбыз», ягъни поякларның, европалыларның һәркайсы). Икенче яктан, Шинкевич, Мәккәдәге төп мәчеткә кергәч, андагы эчке җиһазларны һәм башкарылган йола-гадәтләрне мөселман күзлегеннән күрә. Автор андагы һәр нәрсәне, кемнеңдер сөйләве буенча түгел, үз күзләре белән күреп тасвирлау мөмкинлегенә ия була. Шинкевич Мәсҗид әл-Хәрам капкаларын, мәрмәр сукмакларны, изге Кәгъбәне һ.б.ны, гомумән, күзенә күренгән һәр нәрсәне игътибар белән карый, аннан соң шулар турында тәфсилләп яза. Хаҗ кылуның һәр элементын (Кәгъбә тирәсен, Гарәфәт тавына менүне, Минә үзәнлеген һ.б.ны), үзе шуларны үтәүче буларак, бәйнә-бәйнә бәян итә. Мәккәдән ул Мәдинәгә китә, һәм анда күргәннәрен дә үзенең укучыларына җиткерә.

Якуб Шинкевич «Көнчыгыш Һиндстанга сәяхәт турында истәлекләр»е репортажында, мөфти буларак, Варшавада мәчет салдыру өчен акча җыюны да максат итүе турында яза. Ә бу визитның төп максаты башта Франциягә, аннан Һиндстанга рәсми дипломатик миссия була. Якуб Шинкевич бу хезмәтендә, хисап формасыннан китеп, үзенең цикллап әзерләгән язмаларын «истәлекләр» дип атый. Текстта, барыннан да бигрәк, авторның шәхси искәрмәләренә игътибар итәргә кирәк. Рәсми очрашулар турындагы хисапларында Һиндстанның субконтинент климатын сурәтләп, ул Көнчыгыш белән Көнбатышның тоташуына багышланган репортаж-трактат формасына якынлаша; Польша татары, Польша мөселманнары мөфтие шушы ике мәдәният тоташуының вәкиле рәвешендә чыгыш ясый. Һинд романнарын хәтерләткән язмасында Я. Шинкевич маҗаралары әдәби әсәргә хас элементлар куллана. Моның белән әсәр гади генә фактларны да маҗаралы формада бирә белгән Рышард Капущинский һәм хәзерге заманның башка авторлары иҗатларына охшаган. Кызганычка каршы, сугыш башлану сәбәпле, «Татар тормышы» журналы 1939 елның сентябрендә үзенең эшчәнлеген туктата һәм Я.Шинкевичның бу хезмәте тулысынча басыла алмый кала.

Якуб Шинкевич иҗаты турында әйтелгәннәргә йомгак ясап әйткәндә, аның репортажларында, танып белү перспективасыннан чыгып караганда, иң мөһиме – мөселман идеологиясендәге (модернизм, панисламизм, панарабизм, ваххабизм һ.б.) һәм мөселман традицияләрендәге (җирле йолалардагы зур аерма, мәсәлән, автор күзәткән Хиҗазда һәм Һиндстан Бомбеенда) бик көчле төрлелекнең оста тасвирлануы. Автор буларак, ул югары дәрәҗәдәге халыкара дипломатиянең эчке якларын да бик мавыктыргыч итеп яктырта. 1918–1939 елларда иҗат иткән башка поляк

язучылары белән чагыштырганда, мөфти әсәрләре үзләренең оригинальлеге белән игътибарны җәлеп итә.

Леон Найман Мирза Крычинский (1887–1939) Вильнада Россия генералы гаиләсендә туа [Jakubauskas..., 2009]. Ул Петербург университетында хокук фәннәрен өйрәнә һәм 1911 елда кулына диплом ала. 1912 елдан Варшавада яши, Беренче Бөтендөнья сугышы елларында Петроградта була, анда ул контрреволюцион эшчәнлек алып бара, ә соңрак Кырымда һәм Азәрбайҗанда яши. Симферопольдә ул татарлар парламенты эшләрендә катнаша, Бакуда хөкүмәтнең милләтчелек канцеляриясендә эшли. 1920 елдан Вильнада, Замосць (Замостье) шәһәрендә судья вазифасында. Леон Крычинский Вильнюста татар Халык Музее һәм Татар халык Архивы оештыра. 1932 елдан аның инициативасы белән татарларның еллык басмасы «Rocznik Tatarski» чыга башлый. Аның I томы шушы елда чыкса, II се – 1935 тә, өченчесе 1938 елда дөнья күрә. IV томы 1939 елда башланган сугыш аркасында басылмый кала. Леон Крычинский үзенең мәкаләләре белән, бу басмадан тыш, «Słowo», («Сүз»), «Wschód», («Шәрык»), «Lud», («Халык»), «Przegląd Islamski» («Ислам күзәтүе») һ.б. журналларда чыгышлар ясый. 1933 елда ул хезмәтләре өчен Алтын Хач белән бүләкләнә, 1936 елда Польша әдәбияты Академиясе аңа Көмеш Академик Лавр тапшыра. Леон Мирза Крычинский 1936 елда фашистлар тарафыннан үтерелә.

«Rocznik Tatarski» басмасының редакторы буларак, Леон Крычинский 1932 елда Польша Шәрыкны өйрәнү җәмгыяте әгъзасы булып сайлана һәм шуңа бәйле рәвештә 1932–1934 елларда Төркиягә, Мароккога сәфәр кыла. Аның Төньяк Африка сәяхәте турындагы «Марокко кояшы астында» дигән репортажын «Сүз» көндәлек басмасының 1934 елгы 13, 14, 15 июнь саннарыннан укый алабыз [Podroze..., 2014].

Крычинский Мароккога Польша кораблендә юл тота. Касабланкага – 13 апрельдә иртүк «күк йөзен кызгылт-кан төсендәге нурлар телгәләгән, аннан караңгылык югалып, кояш чыккан вакытта» килеп җитә [Podroze..., st. 56]. Крычинский Марокконың Касабланка, Рабат, Мекнес һәм Фез шәһәрләрендә (җәмгысе 4 көн) була. Крычинскийның 14 апрельдә солтан сараенда солтан Мөхәммәд V тарафыннан кабул ителүе «Марокко кояшы астында» дигән репортажның төп элементын тәшкил итә. Автор солтанга Польша һәм андагы мөселманнар турында мәгълүмат җиткерә, шунда ук Польша хөкүмәте вәкилләре белән ислам дәвамчылары арасындагы мөнәсәбәтләрнең яхшы булуын да әйтергә онытмый. Кырык минутка сузылган әңгәмә ахырында солтан, һиҗри белән яңа ел (1353) башлану уңаеннан, истәлек имзасы салып, үзенең фотосын Крычинскийга бүләк итә. Солтан белән очрашудан тыш, автор Мароккода башка рәсми визитлар да ясый (алар хакында ул тәфсилләп язмыйча, искә генә алып үтә), шулай Төньяк Африка иленең борынгы шәһәрләрендәге истәлекле урыннар белән таныша. Шуңа игътибар итәргә кирәк, автор Мароккода булганда андагы вакытын мөмкин кадәр нәтиҗәлерәк уздырырга омтылган. Гарәп танышлары белән аралашканда ул анда туган тәэсирләренең бер мизгел генә булуын,

ә бер-ике көннән инде бик еракта булачагын аңлап, болай яза:

Przy drzwiach hotelu, prawdziwego pałacu w orientalnym stylu, żegnam swoich arabskich przyjaciół. Czy na zawsze? Bo już jutro o tej porze będę daleko od Rabatu...

*Шәрык стилендәге менә дигән сарайның, кунакханәнең ишеге төбендә мин гарәп дусларым белән саубуллашам. Бөтенләйгә микән? Чөнки иртәгә бу вакытта мин Рабаттан бик еракта булачакмын...* [Podroze..., st. 64].

Рабатка килгән кичтә үк мәчеттәге кичке намазга игътибар итик: автор тасвирлаган бу күренешне без Польша мөселманы белән Мөхәммәт пәйгамбәр динен дәвам итүче гарәпләр очрашуының шаһитләре кебек кабул итәбез. Мәчеткә керү юлында европалыны күрү намазга җыелган җирле халыкның игътибарын җәлеп итә. (Ул чорда Мароккода мөселман булмаган чит ил кешесенә мәчеткә керү тыелган була.) Крычинскийның европача спорт киемнәре гарәпләр киемнәреннән бик нык аерылса да, рухи мөселманлык бердәмлеге өстенлек ала. Репортаж авторы үзен мөселман кардәшләренең зур бер гаиләсендә итеп тоя. Ул Кырымда һәм Азәрбайҗанда татарлар арасында йөргән чакларын исенә төшерә, мәчеттән чыкканда гыйбадәтханәгә кергәндә калдырган киемнәрен һәм башка шәхси әйберләрне карап торучы гарәпләр белән әңгәмә кора.

Польша кунагы белән саубуллашканда гарәпләр күз яшьләре белән:

– Allah jest wielki, wiele narodów wyznaje Islam! [...]

– Teraz mogę przysiąc, że widziałem polskiego muzułmanina!

*– Аллаһ бөек, бик күп халыклар исламга табына! [...]*

*– Хәзер мин Польша мөселманын күрүем хакында ант итеп әйтә алам! – дип калалар* [Podroze..., st. 63]

Бу хезмәттә Польша татарларының ике сугыш арасы (1918–1939 еллар) чоры репортажлары гомуми рәвештә генә анализлана. Киләчәктә алар 20–30 нчы еллар поляк репортажлары фонында, антропологик күзлектән чыгып, тәфсиллерәк өйрәнелергә хаклы. Әлеге әсәрләрне тирәнрәк итеп тикшергәндә Польша мөселманнарының үзләренең тарихларында беренче тапкыр мөселман илләренә сәяхәт кылуын да истә тотарга кирәк. Бу текстларның һәркайсында Польша мөселманы карашы белән, әйтик, гарәп исламы традицияләре каршылыкка керүе чагыла. Авторның җирле халык белән әңгәмәләре (һичьюгы шундый диалогларның нәтиҗәсе) турында укыганда, Польша-Европада формалашкан карашлар белән Азия илләре (мәсәлән, Һиндстан) халкының менталитеты арасындагы аерманы чагыштырырга мөмкинлек туа, гәрчә тегесе дә, бусы да бер үк диндә булсалар да.

Станислав Крычинский (1911–1941) шигырьләр, кыска хикәяләр һәм эсселәр авторы [Kryczynski..., 2014]. Шагыйрь Яңа Сонч шәһәрендә, чыгышы белән шәрыкка бәйле поляк гаиләсендә туа (Станислав Леон Крычинскийның ерак туганы була [Tyszkiewicz..., 1987]). Белеме буенча тарихчы, ә һөнәре белән архивчы Станислав Польша татарларының әдәби мирасын тикшереп өйрәнә, «Pocznik Tatarski» (татарларның еллык басмасы) редакциясе белән хезмәттәшлек итә. С. Крычинский «Литва Татарлары» монографиясенең авторы да (1938). Сугышка кадәр

аның әсәрләре «Znicz» («Шәм») журналында һәм «Pocznik Tatarski» басмасында дөнья күрә. Крычинскийның шигырьләренике сугыш арасында иҗат иткән поляк шагыйрьләре Юзеф Чехович, Чеслав Милош һәм, барыннан да бигрәк, Ежи Либерт әсәрләре белән чагыштырырга була. Моннан тыш, Крычинскийда Яшь Польша дәверендәге һәлакәтле поэзия (мәсәлән, Ян Каспрович иҗаты) кайтавазын очратырга була. Аның «Lirnik», «Kruki» («Каргалар») яки «Dzwony» («Чаң») кебек шигырьләрендә, бер яктан, Кресс (1939 елга кадәр Литваның һәм Белорусиянең Польша өлеше) табигатенә соклану хисе чагылса, ә икенче яктан, котылгысыз үлем якынлашуын тоюдан бу табигатьнең ничек итеп «пычраначагы» күзаллана.

Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Польша татарлары арасыннан күтәрелеп чыккан шагыйрьләрдән Сәлим Мирза Хәзбиевич белән Муса Чахаровскийны әйтеп үтми мөмкин түгел. Сәлим Хәзбиевич 1955 елда Гданьскида туган. Шул ук шәһәр университетында поляк филологиясен үзләштергән. Ә кандидатлык һәм докторлык дәрәҗәләренә ул сәяси фәннәр өлкәсендә ирешә. Сәлим Хәзбиевичның, фәнни хезмәтләре белән бергә, Кырым, Польша-Литва татарларына багышланган китаплары да бар. Хәзер ул Ольштын университеты профессоры. Моннан тыш, ул Речь Посполитая Татарлары Берлегенә (кырым-татар. Polonya Tatar Birligi) нигез салучыларның (Мачей Конопацкий һәм Стефан Мухарский белән бергә) берсе һәм 1999–2007 елларда бу оешманың рәисе була. 1986–1991 елларда Сәлим Хәзбиевич кварталга бер мәртәбә «Мөселман тормышы» журналын чыгара, 1993 елдан Польша татарларының еллык басмасы баш редакторы вазифасын үти. 2003 елга кадәр Сәлим Хәзбиевич Гданьскидагы мәчеттә имам да булып тора, 1998 – 2008 елларда – Польшадагы Католиклар һәм Мөселманнар Советының рәистәше. Сәлим Хәзбиевич Гданьскига Вильнадан килә, анда аның карт бабасы (бабасының әтисе) – Ибраһим Смайкевич Икенче Бөтендөнья сугышына кадәр җирле татарлар җәмгыятенең имамы вазифасын алып барган була. Гаилә традицияләре, шулай ук татар тарихы һәм мәдәнияте Сәлим Хәзбиевич иҗатына зур йогынты ясый. Аның автобиографик шигырендә мондый юллар бар:

Jestem Tatarem. Ostry powiew stepu
Twarz moją pieści. A moja ojczyzna
mieszka w rycinie starego meczetu,
w mieście Wilnie.
(«Melancholia»)

*Я татарин. Резкое дуновение степи*
*моё лицо ласкает. А моя родина*
*живёт в гравюре старой мечети,*
*в городе Вильне.*
(«Меланхолия») [2, 53]

Сәлим Хәзбиевич фән дөньясында һәм татарлар бергәлегендә мөһим урын тотса да үзен, иң элек, шагыйрь дип саный. Аның беренче шигырьләре 1973 елда Польшадагы әдәби журналда басыла. Хәзер инде автор шигырьләре сигез китапта: Ольштында – 1978, 2005 елларда, Гданьскида 1980, 1989, Лодзьда – 1981, Белостокта – 1990, Гдыняда 1997 елда дөнья күрделәр.

Сәлим Хәзбиевич бүгенге Польша татарлары даирәсендә киң танылган шагыйрь. Аның әсәрләре

Яшь Польша дәвере поляк әдәбияты традицияләре белән дә, ислам мәдәнияте мирасы белән дә тыгыз бәйләнгән. Хәзбиевич иҗатында бу традицияләр бер-берсен инкарь итмиләр. Автор Көнчыгыш белән Көнбатыш мәдәнияте синтезын тәшкил иткән, үз әсәрләрендә суфичылыкны, экзистенциализмны (субъектив фикерләүне), феноменлаштыру һәм гнозисны, Юнг психоанализын берләштергән заманча Европа татар әдәбиятын булдырырга омтыла. Иҗатчы үзенең «мин»ен төшендә, хатирәләрендә, хыялында эзли. Башта шагыйрь үзенең балачагына кайта. Үз гаиләсендәге татар традицияләре турында уйлана. С. Хәзбиевич шигырьләрендә без мөселман зиратына баручы малайны күзәтәбез, яшь кешенең тулысынча «үз-үзенә бирелергә» кирәк чакта үз-үзе белән ничек көрәшүе турында укыйбыз. Болардан тыш, Хәзбиевич әсәрләрендә без Польша татарларының матди мәдәнияте белән танышабыз, шулай ук татарларның традицион ашамлыклары турында беләбез. Әйтик:

A więc – kołduny ciężkie
tatarskie kołduny
zawijane w ząbki, podawane
w rosole,
od których zaczyna się czas i
cmentarz,
do których wraca się po modlitwie
(«Kołduny»)

*Итак – пельмени, тяжёлые*
*татарские пельмени,*
*свёрнутые зубчиком –*
*их подают в бульоне,*
*с них начинается время*
*и кладбище,*
*к ним возвращаются*
*после молитвы,*
(«Пельмени») [Хазбиевич, с. 53]

Автор поэзиясенең соңгы томнарында аның лирик героеның күңелендә Юнгка хас индивидуальләштерү процессы баруы күзәтелә. «Шәһәр азиаты» җаны бер мизгелгә үлеп тора, бу арада ерак далада борынгы герой-татар – Чыңгыз ханның рухи варисы туарга тиеш була. Хәзбиевичның «Кресс татарлары мистикасы» шигырен укыганда без борынгы шаманчылык һәм суфичылыкның мөселман варислары йолаларының шаһите булабыз. «Мәчет» шигырендә манара бәреп төшерү вакыйгасын күзаллыйбыз. Монда да суфичылык идеологиясе йогынтысы сиземләнә. Анда үзәкне тышкы тирәлектән аерып кую символы, Аллаһ белән реаль булмаган элемтәгә керү формасы саналган намаз урынын җимерү тасвирлана:

Niech Allah
spojrzy na mnie w kropli darni
niech kilka drzew zaprzeczy moim
ruchom
zamknę parę nie ociosanych bali
w dwie krople rozmodlonych ścian
minaret
na bakier przekrzywię –
ptakom na gościnę
(«Meczet (2)»)

*Да взглянет на меня Аллах*
*в этой капле дёрна*
*да возразят деревья*
*моим движеньям!*
*я замкну пару нетёсаных брёвен*
*в две капли погруженных*
*в молитву стен*
*минарет*
*набекрень –*
*птицам приют*
(«Мечеть (2)») [Хазбиевич, с. 53]

Сәлим Хәзбиевич поэзиясендә өстәмә тикшеренүләр таләп итә торган проблемалар шактый.

«Кырым һәм Вильна» авторы иҗатына берничә мәкаләм багышланды, алар әдәбият белеме өлкәсендәге Польшада чыга торган журналларда нәшер ителде. Алар арасыннан «Сәлим Хәзбиевич – Польша татары шагыйре» [Czerwinski..., 2013], «Польша татарлары поэзиясе урыннары-архетиплары» (Сәлим Хәзбиевич белән Муса Чахоровский мисалында)» [Czerwinski..., 2012].

Муса Чахоровский 1953 елда Вроцлавта борынгы татар нәселе, әмма ассимиляцияләшкән гаиләдә туа. Сугыштан соң шагыйрь гаиләсе үзәк Польшадан элеккеге немец җирләренә күчә. Мусаның әти-әнисе өйдә татар-мөселман йола-гадәтләрен бөтенләй диярлек кулланмасалар да (җитмәсә, әтисе коммунистлар Польшасында хәрби хезмәткәр була), ул кечкенәдән үзен башкача хис итә. Үзенең ярымазият кыяфәтле булуы белән дә ул сыйныфташларыннан аерылып тора. Автор бу хакта автобиографик язмасында болай яза:

*Мин малай чакта ук ялгыз булдым, юаш идем. Мәктәп дусларым минем хакта «кытай малае», «монгол», «пинг-понг» дип әйтәләр иде. Шуннан соң мин әниемнән, ни өчен алар миңа шулай диләр? дип сорый идем. Мин бит кытай малае түгел.* [Чахоровский..., 2008].

Бу юллардан аңлашылганча, Муса Чахаровский өчен «Польша монголы» чыгышы турындагы мәсьәлә бик мөһим була, гәрчә аның беренче шигъри җыентыкларында бөтенләй башка тема өстенлек итсә дә. Күрәсең, автор балачагында ук башына килгән сорауга җавапны бик озак эзләгәндер. Ниһаять, ул үз гаиләсенең үткәне хакында үзе көткәннән дә киңрәк мәгълүматка тап була. Чахоровский борынгы бабаларының – татар гаскәриләре нәселенең Польша үзәгенә нинди юллар белән килеп чыгуы турында белә.

*Минем гаиләм чыгышы белән Польша короле Ян III Собенскийның Венага экспедициясе вакытында әсир ителеп, поляклаштырылган татарлар нәселеннән. Гаиләбезнең икенче тармагы XIV гасыр Литва татарларының борынгы Мазовецки шляхталары нәселеннән. Минем татар бабаларымны король җирләренә күчереп урнаштырганнар, тиздән алар, ассимиляцияләшеп, христианлыкны кабул иткәннәр. Аһ, чал хәтерсезлек! Мин тугач ук, беренче көнемнән ук белдем: мин – башка, мин – татармын!* [Чахаровский..., с. 23.]

Димәк, Муса Чахоровский үз-үзен тапкан һәм һәрчак үзенең борынгы бабалары традициясенә омтылган. Бүген ул «Przeglad Tatarski»ның («Татар күзәтүе») баш редакторы, Литвада нәшер ителә торган «Lietuvos totoriai» («Литва татарлары») журналы хезмәткәре. Аның шигъри җыентыкларының берсе ике телдә: полякча һәм русча язылган («Na zawsze. Навсегда»). Шагыйрь шулай ук Польша Республикасы Мөселманнарының дини берлеге әгъзасы. Моннан тыш, Муса Чахоровский, үзе әйткәнчә, «дала баласы» да, һәм ул аның поэзиясенең нигезен билгели.

*Дала баласы... Тирәкләр һәм һәрвакыт зәңгәрсу күк йөзе – болар барысы да миндә мәңгелеккә калыр...* [Чахоровский..., с. 23].

Бүгенге көнгә М. Чахоровскийның «Ягымлы түгел» (1987), «Күпме яшим» (Клодзко, 1988), «Салкын ноябрь» (Вроцлав, 1990), «Миңа кагыл» (Вроцлав, 1998), «Гомерем болай гына»

(Вроцлав, 2006), «Ялгызлык» (Вроцлав, 2008), «Мәңгегә» (Солечники – Вроцлав, 2008), «Дала робагыйлары» (Вроцлав, 2009), «Горизонт артында» (Вроцлов – Белосток, 2010) җыентыклары бар. Аның шигырьләрендә үзәк фигураны дала тәшкил итә. Үз фамилиясенең этимологиясен автор ике версиядә күрсәтә. Аның берсе – Чахоровский – татарлардан кергән төрек сүзе – «чахар» (ягъни «болын», «дала») дигән сүздән алынган, дип фаразлый.

Муса Чахоровский әсәрләрендәге дала романтизм дәвере поляк һәм рус әдәбиятларыннан (А. Мальчевский. С. Гощинский) билгеле булган дала сүзеннән аерыла. Моңа параллельләр Ярослав Ивашкевич һәм Антон Чехов әсәрендә табыла. Поляк романтизмында мондый атмосферага Богдан Залеский, Юлиуш Словацкий («Бенёвский» поэмасы) һәм, барыннан да бигрәк, Густав Зелинский («Кыргыз», «Дала» поэмалары) әсәрләрендә юлыгасың.

Муса Чахоровский үзенең әсәрләрендә, аның шигырьләрен Сәлим Хәзбиевич поэзиясеннән аерып торучы күренеш буларак, төрки халыклар традицияләренә һәм Бөек Дала цивилизациясе мирасына турыдан-туры мөрәҗәгать итми. Авторның «Ялгызлык» җыентыгында бу юнәлеш аның шәхси уйлануларында чагыла. Шагыйрь үз тормышын һәм гаиләсенең яшәешен шигъри формада сурәтли. Дала аның әсәрләрендә лирик геройның эчке дөньясын ачып сала – үзенең генә түгел, ә татар халкының үткәнен сагынуын, юксынуын символлаштыра. Бу – шулай ук чиксез киңлекне – Хәзбиевич иҗатындагы татар дала архетибын вербальләштерүдән үзгә пространствоны сагыну. Чахоровский шигъриятендә дала шәхси бәйләнешләрне генә чагылдырса да, ул татар рухының нигезен-чыганагын, аның символик рәвештәге борынгы чыгышын һәм үз-үзенә кайтуын гәүдәләндерә.

Pochowaj mnie w stepie wnuku
wśród tatarskich koni
z ich dumnymi niegdyś grzywami
i ogonami
o twardych jak głazy kopytach
tam gdzie kolejną wiosną
tabuny ruszają na świeże pastwiska
abym mógł bezustannie wędrować
wciąż mi mało tego stepu
moje serce pozostaw w
Solecznikach
i zakop pod krzakiem oblepichy
pokaże ci go twój tata
(«Pochowaj mnie...»)

*Похорони меня в степи, внук,*
*среди татарских коней*
*с их гордыми когда-то гривами*
*и хвостами*
*с твёрдыми как камни*
*копытами,*
*там, где очередной весной*
*выходят табуны*
*на свежие пастбища.*
*Чтобы я мог безустанно*
*путешествовать.*
*Всё мне мало этой степи.*
*Моё сердце оставь в Солечниках*
*и закопай*
*под облепиховым кустом,*
*его тебе покажет папа*
(*** «Похорни меня...»)
[Czachorowski..., st. 28]

Польша татарлары авторларының башкалары да хәзер үз әдәби җыентыкларын туплыйлар. Белосток мөселманнары җәмгыяте рәисе Галина Шахидевич инициативасы белән 2010 елда, нигездә, һәвәскәр авторлар

әсәрләреннән торган җыентык басылып чыкты. Анда Польша татарларыннан егерме шагыйрьнең (Сәлим Хәзбиевич, Муса Чахоровский, Анна Кайтохова һәм башка профессиональ булган яки яшь иҗатчыларның) шигырьләрен укырга була [Tatarskie..., 2010]. Китапка әдәби таләпләрдән чыгып бәяләгәндә әллә ни зур кыйммәткә ия булмаган шигырьләр тупланса да, Польша татарларының мәдәни һәм әдәби казанышлары буларак, аларны антропологик һәм социалогик яктан өйрәнеп тикшерү зур әһәмияткә ия [Łyszczarz..., 2013].

Әлеге мәкаләне Польша татарларының XX һәм XXI гасыр әдәбияты тематикасына кереш дип кенә исәпләргә кирәк. Монда искә алынганнар һәркайсы киләчәктә аерым хезмәтләрдә үстерелеп бирелергә тиеш. Польша татарлары мирасын өйрәнеп анализлау иң мөһим проблема санала, чөнки алар Польшаның күптөрле мәдәни юнәлешләрен яңача бәяләргә мөмкинлек бирәчәк. Шул ук вакытта ул хезмәтләр Европада берничә йөзьеллыклар дәвамында исламның үз, европачыл варианты булуын раслый. Кызганычка каршы, әлегә кадәр Польша татарларының XX – XXI гасыр матур әдәбиятын фәнни өйрәнеп тикшерү белән беркем дә шөгыльләнмәде. Моны поляклаштырылган милләттәшләребез арасында татар әдәбияты темасының бик азларга гына билгеле булуы, шулай ук Польша татарларының әдәби мирасын өйрәнү өчен, аның чыганакларына үтеп керү мөмкинлегенең артык та катлаулылыгы белән аңлатырга кирәктер.

**Әдәбият**

*Akiner Sh.* Religious language of a Belarusian Tatar kitab: a cultural monument of Islam in Europe, Wiesbaden: Harrassowitz Verlag, 2009.

*Borawski P., Dubiński A.* Tatarzy polscy. Dzieje, obrzędy, legendy, tradycje. Warszawa: Iskry, 1986.

*Czachorowski M.* Na zawsze. Навсегда, Солечники–Вроцлав: MZR, 2008.

*Czerwiński G.* «Miejsca–archetypy» poezji polsko-tatarskiej (przykład Selima Chazbijewicza i Musy Czachorowskiego) // «Rocznik Komparatystyczny» 2012, nr 3.

*Czerwiński G.* Selim Chazbijewicz jako poeta polsko-tatarski // «Pamiętnik Literacki» 2013, nr 2.

*Drozd A.* Staropolska poezja Tatarów // «Tytuł» 1995, №1.

*Drozd A.* Wpływy chrześcijańskie na literaturę Tatarów w dawnej Rzeczpospolitej. Między antagonizmem a symbiozą // «Pamiętnik Literacki» 1997, №3.

*Drozd A.* Zastosowanie pisma arabskiego do zapisu tekstów polskich (zarys historyczny) // Plenas Arabum domos. Materiały IV Ogólnopolskiej Konferencji Arabistycznej, Warszawa 25–26 marca 1993, red. M. Dziekana, Warszawa: Instytut Orientalistyczny UW, 1994.

*Dziekan M.M.* Drapieżnych stepów synowie // «Przegląd Tatarski» 2010, № 2.

*Jakubauskas A., Sitdykow G., Dumin S.* Lietuvos totoriai istorijoje ir kultūroje / Литовские татары в истории и культуре. Kaunas: Lietuvos totorių bendruomenių sąjunga, 2009.

Katalog zabytków tatarskich, t. 3: Piśmiennictwo i muhiry Tatarów polsko-litewskich, red. A. Drozd, M.M. Dziekan, T. Majda. Warszawa: Res Publica Multiethnica, 2000.

*Kryczyński O.* Ruch nacjonalistyczny a Tatarzy Litewscy // «Rocznik Tatarski» 1932, t. 1.

*Kryczyński S.* Wspomnienia. Utwory poetyckie. Eseje, wstęp, wybór i opracowanie G. Czerwiński, Białystok: Alter Studio, 2014.

*Łapicz Cz.* Kitab Tatarów litewsko-polskich. Paleografia, grafia, język. Toruń: Uniwersytet Mikołaja Kopernika, 1986.

*Łyszczarz M.* Młode pokolenie polskich Tatarów. Studium przemian generacyjnych młodzieży w kontekście religijności muzułmańskiej oraz tożsamości etnicznej, Olsztyn–Białystok: MZR, 2013.

*Miśkiewicz A.* Tatarzy polscy 1918–1939. Życie społeczno-kulturalne i religijne, Warszawa: PWN, 1990.

Podróże do serca islamu. Antologia międzywojennego reportażu polskich Tatarów, wstęp, wybór i opracowanie G. Czerwiński, Białystok: Alter Studio, 2014.

Polski słownik biograficzny, t. 15, z. 3, Wrocław: Zakład Narodowy im. Ossolińskich, Wydawnictwo Polskiej Akademii Nauk, 1970.

*Szynkiewicz J.* Sprawozdania z podróży // G. Czerwiński, Sprawozdania z podróży muftiego Jakuba Szynkiewicza. Źródła. Omówienie. Interpretacja, Białystok: Książnica Podlaska, 2013.

Tatarskie wierszowanie. Oto moje dziedzictwo, red. M. Czachorowski, H. Szahidewicz. Wrocław-Białystok: Agencja Wydawnicza Argi, 2010.

*Tyszkiewicz J.* Dorobek historyczny Leona i Stanisława Kryczyńskich // Środowiska historyczne II Rzeczypospolitej. Materiały konferencji naukowych w Cedzynie i Białymstoku w 1986 i 1987. Warszawa: COM SNP, 1987.

*Tyszkiewicz J.* Z historii Tatarów polskich 1794–1944. Pułtusk: WSH im. A. Gieysztora, 2002.

*Warmińska K.* Tatarzy polscy. Tożsamość religijna i etniczna. Kraków: Universitas, 1999.

*Гумилев Л.Н.* Поиски вымышленного царства (Легенда о «государстве пресвитера Иоанна»). М.: Наука, 1970.

*Тарэлка М., Сынкова І.* Адкуль пайшлі ідалы. Помнік рэлігійна-палемічнай літаратуры з рукапіснай спадчыны татараў Вялікага Княства Літоўскага, Мінск: Тэхналогія, 2009.

*Хазбиевич С.* Два стихотворения, перевод А. Базилевского // «Новая Польша», 2000, №12. С. 53.

*Чахоровский М.* Муса Чахархан, «Alta Bash. Die Internationale Zeitschrift von Tataren und Ihren Freunden» (Берлин) 2008, № 50/51, Dezember, 2008.

**Искәрмәләр:**

[1] Гарәбстан ярымутравының көнбатыш өлеше, бүген ул Согыд Гарәбстанына керә. Ислам барлыкка килгән урын. Анда мөселманнарның изге шәһәрләре Мәккә һәм Мәдинә урнашкан.

[2] Гарәпчә (латин транслит.): Араб. (латин. транслит.): ’ašhadu ’al lā ilāha illa l-Lāhu wa ’ašhadu ’anna muḥammadan rasūlu l-Lāh. В русском переводе: Свидетельствую, что нет божества, кроме Бога, и свидетельствую, что Мухаммед – посланник Бога. Тәрҗемәсе: Аллаһтан башка һичбер Тәңре юктыр. Таныклык кыламын ки: Мөхәммәд Аның колы вә илчеседер.

[3] Монда шуны өстәргә кирәк: Шинкевич «Татар тормышы» журналында басылган репортажында исламның либераль концепциясен куллана, әмма төп дини принциплардан тайпылмый. Журнал өчен, мәсәлән, хәзерге җәмгыятьтә эмансипация һәм мөселман хатын-кызлары азатлыгы проблемасы мөһим була.

[4] 1921 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча, Польшада яшәүчеләрнең күпчелеге (63,9%ы) Рим-католик чиркәве әгъзалары буларак исәпләнә.

[5] Ольгерд Крычинский үзенең бер мәкаләсендә болай дип яза: «Көнчыгыш белән Көнбатыш синтезына омтылган бу бөек идеологик хәрәкәтнең максаты – яңа цивилизация булдыру [...]. Шушы синтезның кечкенә бер өлешен тәшкил иткән Литва татарлары, тыйнак булса да, мактаулы роль уйнарга тиеш була. Литва татарлары Көнбатыш цивилизациясе ирешкән кыйммәтләрне Көнчыгышка күчерүчеләр [...], шул ук вакытта Көнчыгышның рухи бөеклеген һәм гүзәллеген [...] Көнбатышка ирештерүчеләр була алалар [...]» [Kryczynski..., 1932, st. 5–21].

*Мәкалә «1918 елдан соңгы поляк-татар әдәбияты» фәнни проекты кысаларында Польшаның «Милли фән үзәге» фонды финанславына нигезләнеп язылды (грант номеры DEC-2012/07/B/HS2/00292).*

*The article was written under a research project titled "Polish Tatar literature after 1918", funded by the Polish National Science Centre under decision no. DEC-2012/07/B/HS2/00292*

***Гжегоже Червинский,*** *Белосток университетының филологик тикшеренүләр кафедрасы өлкән хезмәткәре (Польша)*

УДК 821.512.145:398.22

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

## XIX ЙӨЗ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ КИТАБИ ДАСТАННАР: тарихи янәшәлек

В статье автор автор затрагивает проблему позднего периода книжных дастанов татарского народа, проводит параллели между татарской письменной литературой XIX века и книжным эпосом, продолжавшим функционировать в репертуаре письменной культуры народа вплоть до начала XX века; литература названного периода и книжные дастаны народа рассматриваются автором как симбиоз двух однородных явлений в духовной жизни татар.

**Ключевые слова:** дастан, эпос, литература, книжный, эпический текст, народ, форма, фольклор.

Кайсы гына халыкта һәм нинди генә формада булмасын, эпос ул – җеп очы текстка алып килә торган иҗат процессы. Сөйләмә характердагы, ягъни сүз остасы тарафыннан башкарыла торган дастан икән, бу – беренчел вербаль текст, китаби дастаннар белән эш иткәндә исә без вербаль эчтәлекле язма (язуга күчеп яши башлаган), ягъни икенчел аутентик фольклор тексты дигән төшенчә белән очрашабыз. Бу мәсьәлә фольклорда «икенчел» текст проблемасына алып килә.

Китаби дастаннарга хас «икенчел» текст ул – уртак борынгы төрки чорда туры функция үтәп, ягъни беренчел вербаль текст ролен башкарып, соңгы чор эпосында символик семантика белән сугарылган фольклор текстына әверелгән әсәр. Дастаннарга булган ихтыяҗ халкыбызга бик борынгы бабаларыннан ук мирас итеп тапшырылган. Бу ихтыяҗ аудитория каршында башкарыла торган вербаль формалы эпосның кайчандыр прагматик роль үтәгән булуыннан да килергә мөмкин.

Әлеге борынгы күренешне аңлату өчен М. Бакиров китергән түбәндәге мисалны файдалану урынлы булыр: «Этнограф Грей язмаларында, – ди галим, – мифологик табу белән бәйләнгән, ягъни тыелган кабырчыклар ашаганнан соң австралиялеләрнең куркып чыгарган җырлары китерелә:

*О, зачем он ел ракушки?*
*Теперь колдуны наведут*
*гром и молнию.*
*О, зачем ел он ракушки?*

Күренүенчә, ...башта җыршигырь чыгуга сәбәп булган ситуация бирелә, аннары шул ситуациянең нәрсәгә китерәчәге – нәтиҗәсе турында әйтелә. Ахырда инде, эмоциональлекне-психологизмны көчәйтеп, беренче юлга кабат әйләнеп кайтыла. Шул рәвешле әлеге җырлар каткат башкарылганнар, кабатланганнар» [Бакиров, б. 111]. Әлеге мисалдан чыгып, кат-кат кабатлану, шулай ук башка факторлар вакыт үтү белән сүзләрнең практик әһәмиятен эстетик функция

үтәү хаҗәтенә үзгәрткәннәр дип карарга мөмкин.

Эпик текстның гамәли функция үтәгән булуына мисалны төрки-татар тарихында сакланып калган риваятьтән дә табарга мөмкин. Үзенең тарихи хезмәтендә Әхмәдзәки Вәлиди түбәндәге вакыйганы бәян итә. Атаклы Чыңгыз ханның угылларыннан иң өлкәне, арада «иң гакыллы һәм игътибарлысы» Җүчи (Җуҗи) вакытсыз вафат була. Вәзирләре, бу хәбәрнең ата кешегә бик авыр тәэсир итәчәген аңлап, Чыңгыз ханга «аның бик якыны булган «олугъ җырчы»ны җибәртеп, хәлне җыр аша аңлатуын үтенәләр. Ул исә җыр белән ханга мондый шигъри юллар әйтә:

*Тиңиз баштыйн болганды,*
*кем тондырыр, и ханым!*
*Тирәк төптин җыгылды,*
*кем торгызыр, и ханым!*
Чыңгыз моңа каршы:
*Тиңиз баштыйн болганса,*
*тондырыр улым Җуҗидыр,*
*Тирәк төптин җыгылса,*
*торгызыр улым Җуҗидыр.*
*Күзең яшен йөгертер,*
*күңлең тулды булдыгый?*
*Җырың күңел өркетер,*
*Җуҗи үлде булдыгый?*
Олугъ җырчы:
*Сөйләмәккә иркем юк,*
*син сөйләдең, и ханым!*
*Үз ярлыгың үзеңә яп,*
*уй уйладың, и ханым!*
Чыңгыз егълап:
*Колын алган куландай*
*колынымдыйн айрылдым,*
*Айрылышкан анкудай*
*ир улымнан айрылдым*
[Вәлиди, б. 48–49].

Бу – эпик текстның билгеле бер вакыйгага багышлый чыгарылып, шул очракка бәйле кулланылуын ассызыклый торган һәм, тел-стиленә караганда, безнең җирлеккә якын төрки телле эпик мисал.

Иң борынгы эпик жанр яралгылары һәм иң архаик эпос йола-миф синкретизмы җирлегендә барлыкка килгән булса, алга таба акрынлап йола белән бәйләнмәгән иҗат башлангычы тернәкләнгән, җыр-шигырь-сөйләмнән гыйбарәт эпик үрнәкләр аерым очрак-хәлләр уңае белән чыгарыла башлаган. Ә тарихи үсешнең билгеле бер баскычында шул ук процесс символик церемония, ә тора-бара әдәби-эстетик функция үтәүгә күчкән.

Төрки бабаларыбыз тарихының Казан татарлары чорына якынлашкан саен утрак тормышлы мәдәни процесслар, язма культура, әдәби-мәдәни багланышлар һ.б. йогынтысында миф-йола синкретизмыннан гыйбарәт элеге иҗат символик церемония үтәүдән бөтенләй үк аерылып җитмәгән, әмма баштагы функциясен башкаруга инде хаҗәте калмаган сюжетлы текст булып үзгәргән. Эпосның сүз белән бәйле булмаган эмоциональ элементлары гасырлар дәвамында юыла килеп, текст үзе халык дастанының иң төп билгеләрен эченә сыйдырган бердәнбер жанр атрибутына әверелгән. Шулай булса да, әйтик, күчмә төркиләр эпосы өчен характерлы речетатив Идел буе татарлары китаби дастаннарында да элекке функцияләрен үтәгән очраклар юк түгел [Мухамедова, б. 248]. Кайбер дастаннарыбызның «шигъри өлешен дутар, думбра белән көйләп әйтү» [Урманче, б. 6] традициясе саклану да – шуңа дәлил. Кайбер сирәк чыганакларда зур әсәрнең кыска өзекләрен – сарын, тулгау, төп

каһарманның җыры һ.б.ны телдән әйтү гадәтенә дә юлыккалыйбыз [Татар..., б. 63–71]. Әмма алга таба, төгәлрәк әйткәндә, Идел буе татары булып формалашуга таба барганда, бездә башкаручы-чичән һәм кабул итүче аудитория катнашыннан гыйбарәт жанрда китабилык, язма иҗатка омтылыш интенсив төстә өстенлек алган. Казан татарларына хас дастаннарда иң зур әһәмият җырчы-бәян итүченең текстны башкаруына түгел, ә текстның барлыгына, шигъри сүзгә бирелгән һәм әсәр язмача теркәлгән. Бу исә Казан татарларының дастани иҗатында икенчел вербаль язма текстның гасырлар аша ныклы позицияләр алып урнашуы дигән сүз.

Эпос ул – халыклар һәм дәүләтләр формалашу процессы белән бергә үзгәрә һәм шулай ук формалаша торган гаять катлаулы күренеш. Структур трансформация аша бүгенге көнгә килеп ирешкән дастаннарның барысын да, – героик характерлы гомумтөрки сюжетлы текстмы ул, борынгы Шәрекъ язма ядкарьләреннән башлангыч алган романтик характердагы дастанмы, – язуга күчеп яши башлаган фольклор эчтәлеккә тугрылык берләштерә һәм бу эчтәлек һәрвакыт борынгы ритуал-мифологик контекстка ия булуы белән дә әһәмиятле. Мондый дастаннар, Идел буе татарлары дастани мирасының төп өлешен биләп торуы җәһәтеннән, татар һәм гомумән төрки фольклористикада гаять актуаль әсәрләр.

Идел буенда яшәүче татарларда дастан жанрына китап идеологиясе бик нык үтеп кергән. Индивидуаль иҗат белән халыкның күләмле эпик жанры үзара тыгыз керешкән өлкә буларак, алар арасына катгый киртәләрне куеп булмый. Әмма фольклорны һәм шул ук чор язма поэзияне генә алсак та, боларның һәр икесендә принципиаль аермаларны искәрми дә мөмкин түгел. Халык әсәре халык шигыренә, традицион ысулларга таянып үссә, индивидуаль иҗатта китаби тенденцияләр өстенлек алган була. Китаби тенденция образ-персонажлар системасында, тема-мотивлар күләмендә һәм аларның эшкәртелешендә, әсәрнең әдәби-оригиналь коллизияләргә бай булуында, индивидуаль стиль үзенчәлекләрендә һ.б.да чагылыш тапкан. Китаби дастаннарга сөйләмне яки әсәр телен авазлар ягыннан оештыру, халыкның саф традицион дастанына хас булган аллитерацияле фонетик чаралар куллану кебек ысуллардан читләшеп, язма әдәбият чараларына мөрәҗәгатьнең исә артуы хас. Шул ук вакытта китаби дастанга индивидуаль иҗатта гына очрый торган китаби элементлар да күпләп үтеп кергән, жанрның халык идеологиясеннән, чичән фикереннән ераклашу белән характерлана торган яңа бер төре барлыкка килгән. Формалашу һәм таралу җирлеге Идел буе регионы булган татар милли дастаннарын язмага әйләндерелгән эпик фольклор дип атарга мөмкин. Китаби дастаннар – фольклорга хас иң төп үзенчәлекләрдән вариантлылыкны – тулысынча, синкретик һәм күмәк иҗат булуны өлешчә саклап, телдән иҗат итеү һәм халык алдында телдән башкарылу кадәресеннән тайпыла төшкән специфик эпик иҗат.

Шул ук вакытта китаби дастаннарның, фольклордан ераклашып, индивидуаль иҗатка әверелеп китмәве аеруча игътибарга лаек. Әйтик, XIX йөз һәм XX йөз

башы – татар халкында китаби дастаннарның популярлыгы иң биек ноктасында булган чор. Моны шул заман вакытлы матбугатында дастан текстларының күпләп басылган булуы һәм күчерелгән кулъязма дастан нөсхәләренең саны ук раслый. «Русия мөселманлыгы чоры»нда (Г. Ибраһимов билгеләмәсе [Ибраһимов, б. 338]), ягъни Казан яулану вакыйгасыннан алып, якынча XIX йөз урталарына кадәрге гасырларны эченә алган дәвердә халык тарафыннан яратып укылган, күчереп таратылган әсәрләрнең татарлар тормышында үзенә бер урын алып торганлыгы мәгълүм. Бу әсәрләрнең күпчелеге теге йә бу халык эпосыннан турыдан-туры тәрҗемә генә булмыйча, аларның җирле милли версияләрен тәшкил итүе белән әһәмиятле. Ә бу чорда татар әдәбияты шулай ук ныклап аягына баскан, әллә кайчан профессиональ формалашып өлгергән өлкә буларак мәгълүм. Бу дәвердә татарларның оригиналь әдәбиятка йөз тоткан, индивидуаль әсәрләре белән киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм шагыйрьләре, язучылары күп булган. Габделҗаббар Кандалый (1797–1860), Каюм Насыйри (1825–1902), Гали Чокрый (1826–1889), Акмулла (1831–1895), Газизә Сәмитова (1862–1929), Муса Акъегет (1864–1923), Заһир Бигиев (1870–1902), Габдрахман Ильяси (1856–1895), Фатих Халиди (1850–1923), Риза Фәхретдин (1858–1936), Фатих Кәрими (1870–1937) кебек әдипләр иҗаты шул хакта сөйли. Шуңа карамастан, ягъни саф әдәби әсәрләр белән параллель рәвештә, татар җәмгыятендә берничә гасыр буена китаби дастаннар да гаять актуаль булып, мондый әсәрләргә карата халыкта аерым ихтыяҗ яшәгән. Авторы билгеле яисә билгесез дастаннар дистәләгән вариантта төрле нөсхәләрдә күчерелеп таратылганнар, китап басу чорында исә басма рәвештә зур-зур тиражлар белән дөнья күргәннәр. Шушы чор әдипләре арасында билгеле сюжетка дастанның үз вариантын иҗат итүне әдәби шөгыленең аерым бер юнәлеше иткән затлар да бар. Әйтик, Әхмәт Уразаев-Кормаши, Әхмәтҗан Тубыли, Мәүлекәй Юмачиков, Кыям Юлдаш, Рәхим Баязит кебек әдәбият әһелләренең, оригиналь иҗаттан тыш, язма характердагы эпосның шактый камил үрнәкләрен калдырган булулары мәгълүм [Мухаметзянова, с. 6–66]. Алар каләме белән үзгәртелеп, икенчел текст буларак кабат дөньяга чыккан «Таһир белән Зөһрә», «Бүз егет», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Чура батыр» кебек ядкарьләр татар китаби дастаннары арасында лаеклы үз урынын тапкан вариантлардан саналалар.

Шулай булгач, сюжет-мотивлары, типологиясе, билгеле бер карашларны чагылдыруы һ.б. яктан һичшиксез фольклор эчтәлек белән өретелгән китаби дастаннарны фольклордан әдәбиятка күчү дәверенең арадашчысы дип кенә билгеләү мөмкин түгел. Дөрес, татар әдәбиятында повесть, роман жанрының үсешенә «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Каһарман Катил», «Түләк китабы» кебек китаби дастаннар һәм гомумән дастан жанры ясаган йогынты биниһая. Әмма шулай да билгеле бер тарихи этапта, ассызыклап әйткәндә, XIX йөз – XX йөз башында, татар мохитендә китаби дастаннар оригиналь

әдәби әсәрләр белән параллель рәвештә яшәп, аларның һәр икесе иҗтимагый тормышта үз функциясен үтәгән. Сөйләмә һәм язма традицияләрнең, ягъни фольклор белән әдәбиятның үзара өзлексез йогынтысының катлаулы формасыннан гыйбарәт китаби дастаннарны халык кулдан-кулга күчереп укыган икән, димәк, бу жанр әсәрләре халыкның рухи азыгы булган. Казан татарлары этник традициясендә китаби дастаннар – билгеле бер чорда татар фольклорын массив төстә тәшкил иткән мөстәкыйль мәдәни феномен. Мондый ядкарьләр Мәскәү хакимияте составындагы мөселманлык чорының һәм аннан да алдагырак дәвернең чорга бәрабәр мәдәни дәрәҗәсен билгели торган әһәмиятле факт булып тора.

**Әдәбият**

*Бакиров М.* Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. 343 б.

*Вәлиди Әхмәд-Зәки.* Кыскача төрек-татар тарихы. Төзүчесе, төп текстның транскрипциясен әзерләүче, библиографик исемлек, искәрмәләр һәм ахыр сүз авторы Равил Әмирхан. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 181 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр. Сигез томда. Т. 5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910 – 1933). Казан: Татар. китап нәшр., 1978. Б. 338.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань, 2014. 380 с.

*Мухамедова Р.Г.* Татары-мишари: Историко-этнографическое исследование. Казань: Магариф, 2008. 295 с.

Татар халык мәкальләре. 3 томда. Т. 1. Җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 915 б.

*Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. Т. 2. (Д–С). Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,*** *филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398.34

*Л.Х. Дәүләтшина*

# КАЗАН АРТЫ ТАТАРЛАРЫНДА ЙОРТ-КАРАЛТЫ ТИРӘСЕНДӘГЕ РУХ-ИЯЛӘР

Данная работа посвящена изучению одного из аспектов традиционной культуры – мифологических представлений о духах-хозяевах домашнего пространства в традиции татар Заказанья. Ввиду широкого распространения веры в духов-хозяев в современной жизни татар Заказанья изучение данного вопроса представляется весьма актуальным. Основным источником нашей работы являются материалы, собранные автором и коллективом Республиканского центра развития традиционной культуры в ходе экспедиций в районы Заказанья в 2002–2008 гг.

**Ключевые слова:** обряд, обычай, мифологический персонаж, духи-хозяева.

Казан арты татарлары яшәешендә йорт-каралты тирәсендәге рух-ияләргә бәйле мифологик күзаллаулар бүгенге көндә дә киң таралыш таба. XXI гасыр башында Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге белгечләре һәм үзем тарафыннан тупланган экспедиция язмаларында табигать объектларының, кеше яши торган торак урыннарының хуҗасы буларак кабул ителгән ияләр хакындагы текстлар шактый урынны алып тора. Фәнни әдәбиятта кабул ителгән классификацияләү принципларына нигезләнеп, ияләр кеше тарафыннан үзләштерелгән һәм үзләштерелмәгән даирәләрдә яшәгән мифик затларга аерыла (Н.А. Криничная, Е.С. Ефимова, Ф.И. Урманчеев, М.Х. Бакиров хезмәтләре). Йорт-каралты белән бәйле рух-хуҗалар арасында өй (йорт), абзар һәм мунча ияләрен санарга кирәк. Әлеге хезмәтнең төп чыганагы буларак өй (йорт) һәм абзар ияләре турындагы мәгълүматлар сайланды. Беренчедән, алар мөстәкыйль буларак та, территориягә бәйле рәвештә бердәм персонаж рәвешендә дә күзалланалар. Икенчедән, мунча иясе турындагы карашлар бик аз һәм аны тулы бер персонаж буларак күз алдына китерерлек түгел.

Казан арты территориясе диалектологлар тарафыннан ашыт (төньяк-көнбатыш өлеш), мамадыш (көньяк-көнчыгыш өлеш), малмыж (төньяк-көнчыгыш өлеш) һәм лаеш сөйләшләрен (көньяк-көнбатыш өлеш) берләштергән дүрт төрле ареалга аерыла [Бурганова, с. 12–13]. Әлеге сөйләшләрне өйрәнгән галимә Н. Борһанова Казан арты татарлары теленең формалашуын бу территориядә барган катлаулы этник процессларга бәйли. Географик яктан Кама алды территориясенә кергән әлеге җирләрдә инде X–XI гасырларда ук Болгар дәүләтеннән күченеп килгән төрки телле халыклар күренә башлый. Җирле фин-угыр кабиләләре белән кушылган болгарлар, соңрак бу төбәккә килгән нугай кабиләләре Казан ханлыгының төп халкын тәшкил итеп, казан татарларының этнос буларак формалашуына нигез була [Татары..., с. 39–40]. Тел материаллары һәм традицион мәдәниятләре бу-

енча әлеге төбәк халкына Алабуга районының көнбатыш өлешендә яши торган керәшен татарлары да якын тора [Этнотерриториальные..., с. 77]. Югарыда әйтелгәннәрне истә тотып, территория шактый киңәйтеп, диалектологлар тарафыннан аерылган сөйләш чикләрендә алынды. Бу юнәлештә эш алып барганда, тикшеренү даирәсенә Татарстан Республикасындагы Яшел Үзән районының Иделнең сул ярындагы өлеше, Биектау, Питрәч, Теләче, Арча, Саба, Балтач, Кукмара, Балык Бистәсе, Әтнә, Лаеш, Мамадыш, Алабуга (көнбатыш өлеше), Мари Эл Республикасының Бәрәңге, Киров өлкәсенең Малмыж районнары кертелә.

Йорт-каралты иясенә ышану Казан артында киң таралган күренеш, аның турында һәр авылда ишетергә мөмкин. Бу иyләшелгән, гадәти персонаж әллә ни куркыныч хәлләр белән бәйләнмәгән, шуңа күрә аның турындагы текстлар катлаулы, киңәйтелгән сюжетка корылмый. Аларның күп өлеше кабатлаулы берничә мотивтан гыйбарәт, әмма алар тасвирлау детальләренә гаять бай. Кулга кергән материалларны анализлаудан мәгълүм булганча, өй һәм хуҗалык ияләре еш кына исемнәре ягыннан да, функцияләре белән дә берләшәләр. Бу төр персонажның төп билгеләренең берсе – яраткан йорт хайваннарына ярдәм итүдән яки үзе яратмаган җан иясенә зыян салудан гыйбарәт. «Безнең Микәй дә аны күрдем, ди. Иске җортта. Апак киенгән, ди. Атымны тарап тора, ди. Атын өйдә кундыра икән...» (Татарстанның Алабуга районы, Олы Шүрнәк авылында Чураева Вера Трофимовнадан (1930 елгы) язып алынды). Бу очракта күп кенә информантлар абзар иясе белән өй иясе төшенчәләрен аермыйлар, аларга бербөтен итеп карыйлар. Әмма кайбер очракларда өй иясе белән хуҗалыктагы башка корылмалар иясенең функциональ кыры аерыла. Казан арты татарлары традициясендә тамырланган мондый капма-каршы караш территориаль яктан да нигезләмә таба.

Шуннан чыгып, Казан арты татарларының өйне һәм хайваннарны яклаучы функциясен берләштергән йорт-хуҗалык иясе (җорт ияләре, йорт ияләре, җорт атасы, җорт анасы, яхшыларым), шулай ук функцияләре аерылып торган (нигез хуҗасы, өй хуҗасы, зат иясе) белән абзар иясе (мал иясе, лапас хуҗасы, Зәнги бабай, Мәхүбә түти) турындагы күзаллауларына аерым тукталыйк. *Өй* һәм *йорт* төшенчәләре белән бәйле ияләр төрле рәвешләргә кереп күренергә сәләтле. Абзар иясе, киресенчә, мөстәкыйль персонаж булганда күзгә күренми. Кулга кергән материаллар арасында абзар иясенең килеш-килбәте сурәтләнгән бер генә текст та юк.

Иң элек барлык рух-ияләрне берләштергән йорт (хуҗалык) иясенә тукталыйк. Йорт иясе бер үк вакытта антропоморф персонаж буларак та, зооморф персонаж рәвешендә дә гәүдәләнергә мөмкин. Антропоморф персонаж буларак аны Казан артындагы теләсә кайсы районда очратып булса, зооморф гәүдәләнеше исә территориягә бәйле. Йорт иясенең зооморф асылы Казан артының көньяк-көнчыгыш өлеше (Татарстанның Лаеш, Питрәч, өлешчә Биектау, Теләче, Балык Бистәсе, Мамадыш, Алабуга районнары) өчен хас. Йорт иясе нигездә тотрыклы ике образда – мәче (песи) һәм елан рәвешендә гәүдәләнә. Әгәр йорт иясе мәче (гадәттә ак төстәге) рәвешендә күзаллана икән, бу традициядә

ул кеше кыяфәтендә дә күренергә мөмкин. Шул ук вакытта әлеге персонаж, еш кына, кешегә зыян сала, ягъни йорт иясе күпчелек очракта кешеләрне борчый һәм куркыта. «Җорт иясе күренә, дип әйтә иде безнең әби. Берсендә генә әйтте Гөлкамал әби: «Әллә нинди нәстә ул, – ди. – Караватбашында песигә охшаган бер әйбер дип, куркып уянып киттем, дип әйтә» (Татарстанның Биектау районындагы Өлә авылында Шәрипова Илһамия Рәшит кызыннан (1965 елгы) язып алынды).

Йорт иясенең зарар китерү функциясе хакындагы ышанулар көнчыгыш районнар юнәлешендә көчәя бара. Мамадыш һәм Алабуга районнарында исә бу функция йорт иясенең антропоморф рәвешенә күчерелә: рух ир кеше кыяфәтендә хатын-кызларга бәйләнә, йоклаганда кешенең басырылуына сәбәпче була. Мондый очракларда аны гомумиләштереп, «җен» дип атыйлар. «Җорт хуҗасы баса, куркыта инде барыбер. Миндә эшчеләр тордылар. Шул Минзәлиф үлде инде. Җанымда гел кеше тора. Мәче сикергән шикелле була, ди. Хуҗага тими ул. Первый пич кырына аңа куймасаң, өстәлдә бернәрсә дә калмый» (Татарстанның Алабуга районындагы Олы Шүрнәк авылында Овечкина Ольга Захаровнадан (1931) язып алынды). «Җорт иясен Тәкәнештә берәү сөйләде. Җен дип сүләшә иде. Без бит аны җен дип сүлибез бит инде нәрсә күргәнбез» (Татарстанның Мамадыш районындагы Югары Тәкәнеш авылында Фәйзуллин Мәснәви Фәрхетдин улыннан (1927 елгы) язып алынды). Биредә йорт иясе функциональ яктан кешеләргә зыян салучы башка тискәре персонаж белән кушылып китә күрәсең, шуңа күрә аны «җен» дип атау да гадәти күренешкә әйләнгән. Ә моның сәбәпләре, әлеге төбәкне үз эченә алган Мамадыш ареалының формалашу үзенчәлегенә бәйле булырга тиеш.

Йорт иясенең икенче зооморф гәүдәләнеше булып елан (җорт җыланы) санала. Ул, киресенчә, йорт иясенең киләчәкне юрау функциясен үтәүче мөстәкыйль персонаж рәвешендә күзаллана. Йорт еланы, гадәттә, кеше күзенә күренми, әмма бәхетсезлек килер алдыннан, хуҗаны кисәтер өчен, юл уртасына чыгып ята. «Җорт җыланы бөтен кешедә дә бар диләр бит. Җорт җыланы чыкса, хәерлегә булмый, диләр. Ап-ак була. Һәр кешедә була. Менә бездә бер кеше бар. Җортына чыккан, диләр. Үзе дә үлде, иптәше дә. Идән астында тора ул» (Татарстанның Питрәч районындагы Янсуар авылында Скворцова Елена Ивановнадан (1935 елгы) язып алынды). Әлеге традициядә йорт еланына уңай функция йөкләнә: ул йорттагы бәхет һәм иминлек символы буларак күзаллана.

Казан артының көньяк-көнчыгыш өлешендә йорт иясенең зооморф гәүдәләнеше белән янәшә тәбәнәк буйлы кеше, кечкенә малай персонажы да очрый. «Дворга эти урынына ахранга төштем. Кечерәк кенә бер ир бала басып тора. Җукка чыкты аннары. Төшмәдем мин анда. Җорт иясе инде ул, хайваннарның иясе» (Татарстанның Питрәч районындагы Керәшен Сәрдәсе авылында Тапьянова Мария Михайловнадан (1932 елгы) язып алынды).

Йорт-хуҗалык иясенең бабай, өлкән яшьтәге ир кеше яки хатын-кыз рәвешендәге антропоморф гәүдәләнеше Казан артының барлык районнарына да хас.

Ул, еш кына, ак киемнәр кигән тере яки үлгән өй хуҗасы яисә хуҗабикә кыяфәтендә күренә. «Әни тора бит инде безнең иң беренче. Иң карт кеше булса да, ул тора. Менә ул берәр кая китә икән, кыш көнеме ул, җәй көнеме, җорт иясе дәшә. Әни тавышы белән «Илһамия, тор әйдә», ди» (Татарстанның Биектау районындагы Өлә авылында Шәрипова Илһамия Рәшит кызыннан (1965 елгы) язып алынды). Кайбер информантларның сүзләренә караганда, аның гаиләсе дә була. «Минем бәләкәй вакытта семьям белән ятып йокладым. Эссе булгач, бишмәтне ачып җибәрсәм, аяк очында карт карчык баласы белән җеп җегерләп утыра рәхәтләнеп шунда... Ул ут яндырганчы кадәр утырды, әни ут яндыруга баласын тотып мич арасына кереп китте» (Татарстанның Мамадыш районындагы Югары Тәкәнеш авылында Фәйзуллин Мәснәви Фәрхетдин улыннан (1927 елгы) язып алынды).

Йорт-хуҗалык иясенә эндәшкәндә, югарыда әйтеп үтелгән исемнәр белән берлектә, күплек санда мөрәҗәгать итү дә киң таралган. «Яхшыларым, әйдә безнең белән бергә яшәгез» (Татарстанның Питрәч районындагы Керәшен Сәрдәсе авылында Иванов Иван Васильевичтан (1929 елгы) язып алынды). «Йорт ияләре, йорт хуҗалары барыгыз минем белән» (Татарстанның Биектау районындагы Өлә авылында Габдрахманова Гөлчирә Мифтах кызыннан (1935 елгы) язып алынды). Мөгаен, элек йорт иясе хуҗалыкта тәртипне һәм иминлекне саклаучы рухларның гомуми исемен белдергән булса кирәк. Моңа мисалларны Идел буе, Урта Азия, Төньяк Кавказ, Көнбатыш Себер, Алтай һәм Саян таулары буенда яшәгән төрки телле халыклар мифологиясеннән табарга мөмкин. «Ия» төшенчәсе билгеле бер җирдәге рухлар төркемен – ата һәм ана рухларны берләштергән [Мифологический, с. 672].

Бүгенге көндә берничә персонажны бер исем белән атау аларның хуҗалыктагы функцияләрен бутауга китерә. Әйтик, йон эрләү, он иләү һ.б. кебек хатын-кызлар шөгылен, билгеле бер территориядә таралыш тапкан ир-ат персонажына күчерү дә очрый. Шул ук вакытта информантларның күбесе йорт-хуҗалык иясен хатын-кыз рәвешендә күзалласалар, ир-ат атрибутлары калкырга мөмкин. Биектау районының Зур Битаман авылында йорт иясе күпчелек очракта хатын-кыз кыяфәтендә күзаллана. Әмма биредә язып алынган тексттан аңлашылганча, йорт иясе җафаласа, сыерны балта белән кыйнарга кирәклеге ачыклана. Бер информант балта урынына себерке кулланган булган һәм аның куллары хәрәкәтсез калган (Татарстандагы Биектау районының Зур Битаман авылында яшәүче Миндубаева Луиза Зиннәт кызы (1938 елгы) сөйләве буенча). Вакыйгадан аңлашылганча, балта – ир-атка хас эш коралы, шуңа күрә, традиция буенча, хуҗа хатын йорт иясенә карата ир-ат атрибутын кулланырга тиеш булган.

Казан артының көньяк-көнчыгыш өлешендә йорт иясе төрле кыяфәтләрдә күренсә, төньяк-көнбатыш өлешендә (Татарстан Республиканың Кукмара, Балтач, Арча, Саба, Әтнә, өлешчә Биектау, Яшел Үзән районнары) өй иясенең антропоморф рәвеше генә билгеле. Нәкъ менә әлеге территориядә йорт-хуҗалык иясе

мөстәкыйль өй иясе белән абзар иясе персонажларына аерыла.

Әлеге территориядә яшәүче татарларның традицион күзаллавы буенча хуҗалыкта өй иясе белән бергә, мөстәкыйль персонаж буларак, абзар иясе дә (абзар хуҗасы, сарай хуҗасы, Мәхүбә түти, лапас хуҗасы, Зәнки бабай, мал хуҗасы, Хуҗа Баһаветдин) яши. Кайбер информантлар, һәр хайванның үз хуҗасы бар, диләр, әмма моңа мисаллар бик аз, күпчелек очракта аерма исемнәрдә генә күзәтелә, ә функциональ яктан абзар иясе аларның барысын бербөтенгә берләштерә. Бирәдә абзар иясе күзгә күренми торган зат дип исәпләнә, аның антропоморф гәүдәләнеше турында берничә текст кына бар. Әлеге персонажның тышкы кыяфәте хакындагы информациянең аз булуы «абзар иясе белән очрашсаң, аны качырасың һәм бәхетсезлеккә юлыгасың» дигән ышануга бәйле булса кирәк. Бу очракта билгеле бер таләпләр актуальләшә. Информантлар фикеренчә, һәркөн иртән абзарга кергәндә, хуҗа кеше, абзар иясенә качарга мөмкинлек бирер өчен, тамак кырырга тиеш. Шул ук вакытта аңа ниятләп дога уку һәм сәдака бирү дә гадәткә кергән. «Абзар хуҗасына сәдака бирәсең, көчеккә булса да, риза булсыннар дип. Мин үзем менә дога кылганда, бер дә әйтмичә калмыйм» (Татарстанның Балтач районындагы Нөнәгәр авылында Нәсыйхова Ләйлә Фасыйх кызыннан (1931 елгы) язып алынды).

Абзар иясе турындагы күзаллаулар комплексында Кукмара һәм Балтач районнарында киң таралыш алган Зәнги бабай атамасы игътибарны җәлеп итә. Әгәр башка исемнәр белән аталган абзар иясенә карата гомумкулланылыштагы магик хәрәкәтләр башкарылса, Зәнги бабайга мөнәсәбәттә ритуаллар комплексы катлаулана төшә. Әлеге персонажны олылау, бигрәк тә, сыер бозаулагач уздырылган «угыз боткасы» йоласын башкаруда чагыла. Барыннан да элек, угыз сөтенә йомырка белән бодай оны кушып ясалган сыек камырдан көлчә пешерәләр. Бу ризыкның исеме үк – угыз боткасы – аның угыз сөтеннән әзерләнгәнен белдерә. Угыз боткасы мәҗлесендә мулланың катнашуы мәҗбүри. Ул турыдан-туры Зәнги бабайга мөрәҗәгать итеп дога укый, әле генә дөньяга туган бозауга исәнлек тели. Аннан соң чәй эчү ритуалы уздырыла, муллага күчтәнәч итеп йомырка яки акча бирәләр [Завгарова, с. 54].

Себердә таралыш тапкан мөселман изгеләре культын тикшергән галимнәр Зәнги ата турындагы ышануларның Урта Азия һәм Идел буенда киң таралуын дәлилиләр. Әлеге персонажның асылында суфи шәехләренең чынбарлыктагы тарихи прототибы Зәнги ата булырга тиеш. Легендаларда ул Ташкент якларында көтү көткән, йөзгә-биткә тупас чалымлы кеше буларак сурәтләнә. Зәнги ата һәм аның фикердәшләре Алтын Урдада исламны таратуда хәлиткеч роль уйнаган дип исәпләнелә [Культ..., с. 85–86]. Казан арты территориясенә Зәнги атага бәйле ышанулар ислам дине белән кергән булырга тиеш, әмма аларның берничә район аралыгында гына таралыш табуы алга таба аңлатмалар таләп итә. Гомумән алганда, абзар иясе кешеләргә карата тискәре мөнәсәбәт белдерми, ул мәрхәмәтле, изге рух. Хуҗалыкта яши дип ышанылган гайре та-

бигый зат буларак, абзар иясе, өй иясе кебек үк, яклаучы һәм саклаучы вазифасын үти.

Шулай итеп, Казан арты татарларының традицион мәдәниятендә сакланып килгән йорт-хуҗалык ияләре хакындагы ышанулар системасын барлау аларның бүген дә актив булуын күрсәтте. Рух-ияләрнең исемнәрен һәм тышкы кыяфәтләрен анализлау түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкинлек бирде:

– Казан артының көньяк-көнчыгыш өлешендә йорт (хуҗалык) иясе өйне һәм мал-туарны саклау функцияләрен берләштерә, ә көнчыгыш районнар юнәлешендә әлеге персонажның тискәре сыйфатлары көчәя бара. Төньяк-көнбатыш районнарда исә өй иясе белән абзар иясе мөстәкыйль персонажлар буларак күзалланалар;

– көньяк-көнчыгыш районнарда йорт иясе бер үк вакытта антропоморф (кечкенә малай) яки зооморф (песи, елан) кыяфәттә күренергә мөмкин;

– Казан артының барлык территориясендә дә өй (йорт) иясе өлкән яшьтәге ир кеше яки хатын-кыз буларак гәүдәләнергә мөмкин. Еш кына ул ак киемгә киенгән тере яки үлгән йорт хуҗасы яисә хуҗабикә кыяфәтендә күренә;

– төньяк-көнбатыш өлешендә абзар иясе мөстәкыйль персонаж буларак күзаллана, һәм ул күпчелек очракта күзгә күренми торган зат буларак билгеле.

## Текстлар

*Җорт ияләре бар ийе. Менә әйтәләр бит инде җаңа җортка кергәнче, икмәк алырга кушалар бит әле* (Биектау районы, Казаклар авылы. Фатыйхова Вәсимә Галимҗан кызыннан (1933елгы) язып алды Л. Дәүләтшина).

*Җорт ияләренә, нигез хуҗаларына, дип дога кыласың инде* (Биектау районы, Казаклар авылы. Низаметдинова Шәмсеруйдан (1925 елгы) Л. Дәүләтшина язып алды).

*Күренеп йөрми бит ул. Ну тавыш булып ишетелә бераз. Җорт иясе хәбәр биргән, дип әйтәләр* (Биектау районы, Өлә авылы. Габдрахманова Гөлчирә Мифтах кызыннан (1935 елгы) Л. Дәүләтшина язып алды).

*Җорт иясенә, дип укыйбыз. Җылына бер мәртәбә күп кеше укыта җорт иясе дип. Белеп булмый бит. Күзгә күренми бит ул* (Биектау районы, Өлә авылы. Шәрипова Илһамия Рәшид кызыннан (1965 елгы). Л. Дәүләтшина язып алды).

*Беренче класста укыган чагым гынайы ул. Шулай тышка чыктым. Менә шулай сарай почмагы. Сарай почмагында җомычкалар куелган. Әби әйтә, кызым, ди, җомычка да ала кер, ди. Хәзер караңгы бит инде. Чын бу. Тотам, мин тоткан саен йоп-йомшак мамык шикелле әйбер. Тоткан саен һаман өскә үрмәли, һаман өскә үрмәли. Мин куркып киттем дә инде. Шулай кулга тоткан көе җыгылып калганым. Ул әйбер китте инде ул. Ап-ак ул, мәче шикелле. Ул җорт иясе булган, диде әбием* (Биектау районы, Күн авылы. Рахматуллина Нәсимә Каюм кызыннан (1936 елгы) Л. Дәүләтшина язып алды).

*Әни тора бит инде безнең иң беренче. Иң карт кеше булса да, ул тора. Менә ул берәр*

*кая китә икән, кыш көнеме ул, җәй көнеме, җорт иясе дәшә. Әни тавышы белән «Илһамия, тор әйдә», ди* (Биектау районы, Өлә авылы. Шәрипова Илһамия Рәшид кызыннан (1965 елгы) Л. Дәүләтшина язып алды).

*Хуҗаларым анда калмагыз. Әйдәгез безнең белән, дисең инде* (Питрәч районы, Күн авылы. Рәхмәтуллина Нәсимә Каюм кызыннан язып алынды (1936 елгы).

*Мenә чыптыр-чыптыр теге почмактан мәче менгән кебек ие, ди* (Питрәч районы, Керәшен Сәрдәсе авылы. Иванов Иван Васильевичтан (1929 елгы) Л. Дәүләтшина язып алды).

*Хайваннарның үзләренең хуҗасы бар. Аларныкы сарай хуҗасы дип атала* (Яшел Үзән районы, Бишнә авылы. Галиуллина Асия Галәветдин кызыннан (1942 елгы) Л. Дәүләтшина язып алды).

*Ул инде абыстай булып укып йөри. Менә шуларның койма буеннан менә ул, бер ягыннан. Шунда күренде ул миңа. Менә, бу Камал әбисенең йорт иясе күренеп йөргән. Әби аны зат иясе дип әйтә торган иде* (Биектау районы, Өлә авылы. Шәрипова Илһамия Рәшид кызыннан (1965 елгы) Л. Дәүләтшина язып алды).

*Менә өйнең олы фәрештәсе Зәнги бабай. Өйдә Коръән укыганда, аңа дога кылабыз, Зәнги бабай дип.* [Тагын нинди фәрештәләр бар? Хайваннарныкы, абзарларда, сарайларда бармы?] *Менә шул бер йорт фәрештәсе бөтен йортыңа хуҗа була инде. Зәнги бабай борынгы китапларда да бар ул. Менә шуңа дога кылабыз* (Саба районы, Байлар Сабасы авылы. Фатыйхова Флера Габдулла кызыннан (1931елгы) Г. Ханнанова язып алды).

*Минем иптәшем, конечно, зур да түгел, диде, ак күлмәк өстеннән казаки кигән, түбәтәй кигән кеше, диде. Менә монда уртада өстәл бар иде безнең. Без кергәндә өстәл артында китап укып утырадрые ул, – диде. Берничә мәртәбә әйтте ул аны, ничек әйтер иде микән. Менә без кереп ут кабызабыз, ул әйтте: «Йорт иясен күрдем мин бүген», – ди. Менә белмим мин, мәзәк итеп әйттеме ул аны. Шуны бик серьезно итеп сорап кала алмадым. «Киңрәк кенә түбәтәй кигән, ак күлмәк өстеннән казаки кигән. Гел шул бертөсле күрдем», – дип әйтәдерие* (Лаеш районы, Атабай авылы. Билалова Фәридә Фәхразый кызыннан (1947 елгы) Г. Ханнанова язып алды).

*Әле безнең кечкенә чак. Без әле иске авылда торабыз. Йорт иясе дигәннән, хәзер, безнең бабай бик дини, хәзер, икенде, ахшам вакыты булды микән инде, кич белән. ... шунда карасам – келәт белән абзар арасында бабайның алъяпкычын япкан, бабайның бүреге, бабай эт оясын көрәкләп йөри, кулында себерке. Хәзер, бабайга кердем дә мин, йөгереп кердем дә, бабай дип, дәштем әле аңарга, бабай дәшмәде. Хәзер, бабай намаз укып утыра, бабай син ич, дим, тегендә эт оясына саламнар җәясең анда, дидем дә, юк кызым, мин намаз укыйм, ди. Менә бабай күрдем, әйдә, чыгыйк әле, дим. Кызым, шаулама, беркемгә дә сөйләмә, ди. Ярар, ди, булган, ди. Ул йорт иясе этнең урыннарына йомшак ни сала, ди. Менә шушыны, балачагымдагыны, бүгенгедәй күз алдымда. Шундый хәл булганы бар.* [Нәкъ шушы бабай кыяфәтендә күрендеме?] *Нәкъ бабай. Киндер алъяпкычын ябып куя иде бабай, башта бүрек инде, караңгы бит, эңгер-мэңгер. Менә бабайны күрдем шулай итеп. Ә бабай намаз*

*укып утыра.* [Алар шул эңгердә күренергә мөмкиннәр инде?] *Белмим, белмим ансын. Менә шул йорт иясeдер ул, кызым, кешегә сөйләмә, йорт иясе бизмәсен, диде* (Лаеш районы, Тат. Сараланы авылы. Садыйкова Маһруй Мисләхетдин кызыннан (1938 елгы) Ф. Җәүһәрова язып алды).

*Менә мондый-мондый түгәрәк икмәкләр пешердем. Аны, ул сыя торган ни бар, урын. Менә шул сыерлар, тәреләр тора торган урынга, югарыга куйдык.* [Аны ел саен пешерәсез инде?] *Менә шуннан бирле пешергәнем юк әле, юк. Аннары өй әниләргә, өй әтиләргә пешерәләр иде. Ни ич, пич асты бар иде. Менә шул ни астына ташлыйлар иде. Менә шушындый икмәк пешереп. Аны, менә шундый итеп, менә сезгә ашамлык дип, пич астына салганнар иде. Ул шунда тик ятадрые. Ә инде минем икмәкләрне инде, кошлар ашагандыр инде. Кошлар оя ясый бит абзар эченә. Абзар эчендә кошлар. Бүре абзарында да, сыер өстендә дә, сарык өстендә дә.* (Лаеш районы, Ташкирмән авылы. Шишкова Мария Егоровнадан (1931 елгы) Г. Ханнанова язып алды).

[Йорт иясе бизмәсенгә нәрсәләр эшләнә? Маһрүй апа, хәтерләмисезме?] *Белмим ансын. Йорт иясе бизмәсен, дип, әйтәләр иде инде. И Ходаем, тeгe, сүгенгән кешеләр була инде, безнең күршедә Минһаҗ абый бар иде, Минһаҗ абыйлар бик сүгенә иде инде, Мәликә апаның ире бик сүгенә иде ул. И Ходаем, йорт ияләре бизмәсен инде, безнекеләр дә шушының тавышыннан, дип йөри иде бабай* (Лаеш районы, Тат. Сараланы авылы. Садыйкова Маһруй Мисләхетдин кызыннан (1938 елгы) Ф. Җәүһәрова язып алды).

*...Уята, торалмый калсаң. Например, исемеңне әйтеп уята. Часто йәшә ул. Исемеңне әйтеп йәшә. Җорт иясе ул. Моны бөтен кеше белә. Мин менә атна саен җорт хуҗама юып сөлге эләм.* [Кайда эләсез сез аны?] *Элəм менә, мич кырына элəм. Мин аны малайга да, киленгә дә әйтәм. Берегез дә моңа кулыгызны сөртмәгез, дим. Ул минем җорт хуҗамныкы. Мин аңа үзем дә сөртмим. Нурания беркөнне кайткан, битен дә сөрткән. Кулын да сөрткән. Нәсимә апа, ди, менә кечкенә кул, нәзек кенә, ди, тырнагы аппакка буяган, ди, төшемә керде, ди. Миңа кулын суза, ди. Олан, мәйтәм, кулыңны сөрттең мәллә? Керергә иренеп, ди, намаз укыганда, кулымы, битеме сөрткән идем, ди. Зинһар, сөртә күрмә, мәйтәм, җорт хуҗасыныкы ул. Менә сөрткән, шул көннүк кергән.* [Аны элгәндә берәр сүз әйтәсезме?] *Бисмилләһир-рахман-иррахим. «Җорт ияләрем, җорт хуҗам синең өчен бу», дип элеп куям* (Биектау районы, Күн авылы. Рәхмәтуллина Нәсимә Каюм кызыннан (1936 елгы) Л. Дәүләтшина язып алды).

*Җорт хуҗалары, җорт ияләре, әйдә минем белән барыгыз дип апчыгасың себерке белән. Күренеп йөрми бит ул. Ну тавыш булып ишетелә бераз. Җорт иясе хәбәр биргән дип әйтәләр* (Биектау районы, Өлә авылы. Габдрахманова Гөлчирә Мифтах кызыннан (1935 елгы) Л. Дәүләтшина язып алды).

*Әни, чыгып карыйм, һаман чыгып карыйм, ди, нитми, ди, ни, нитмәгән, бозауламаган әле сыер, ди. Берара йоклап китсәм, сыерның авыртканын сизенгән инде ул, авырта ахры дип инде. «Миннекал, сыерыңны чыгып ал, сыерың*

*бозауладЫ, ахры», – дип әйтеп, ди, тәрәзәдән әйттеләр, ди. Менә йорт иясе дип әйтәсе килә инде аны. Борыңгы кеше ышанган бит инде. Дога белән өшкергәннәр* (Балтач районы, Норма авылы. Рәхимова Мәсрүрә Миңнехан кызыннан (1953 елгы) Г. Ханнанова язып алды).

*Электән килә торган гадәтләрнең берсе – бөтен җирләргә дә догалар элү, бигрәк тә ишек өстендәгесе өй хуҗалары өчен әһәмиятле. Дога ул электән үк бәхет билгесе* (Балтач районы, Норма авылы. Кәлимуллина Флера Гарифҗан кызыннан (1936 елгы) Ф. Җәүһәрова язып алды).

[Апа, менә сездә йорт ияләренә, абзар ияләренә ышанулар бармы?] *Бар, ышаналар инде ансына, йорт хуҗасына ышаналар, абзар хуҗасына да. Абзар хуҗасының хәтерен калдырсаң, маллар авырта дибез инде.* [Аның хәтерен калдырмас өчен нишләргә?] *Хәтерен калдырмас өчен йорт хуҗасы, абзар хуҗасы, хайваннар хуҗасына, Мәхүбә әбигә сәдака бирәсең. Мәхүбә әби дип йөрткәннәр инде. Абзар хуҗасына сәдакә бирәсең, кәчеккә булса да, риза булсыннар, дип. Мин үзем дә менә дога кылганда, бер дә әйтмичә калмыйм. Мәхүбә түти дип йөрткәннәр инде ул карчыкны, электән килгән инде. Безнең элек бабайлар бик укымышлы булганнар, шул бабайлардан колакка кергән инде* (Балтач районы, Нөнәгәр авылы. Нәсыйхова Ләйлә Фасих кызыннан (1931 елгы) Д. Арсланова язып алды).

**Әдәбият**

*Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан, 1997. 248 б.

*Бурганова Н.Б.* О формировании татарских говоров Заказанья // К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. Казань, 1985.

*Завгарова Ф.Х.* Исламский мифологизированный персонаж Занки бабай в системе окказиональных обрядов современных татар // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре (фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы). Казан, 2011. 6 китап. 134 с.

*Корусенко М.А., Диянова А.М.* Традиционное мировоззрение барабинских татар во второй трети XX – начале XXI века: представления о духах-хозяевах освоенных пространств // Вестник археологии, антропологии и этнографии. 2011. № 2 (15).

*Селезнев А.Г. и др.* Культ святых в сибирском исламе: специфика универсального. М., 2009. 216 с.

Мифологический словарь / гл. ред. Е.М. Мелетинский. М., 1990. 672 с.

Татары Среднего Поволжья и Приуралья / отв. ред. Н.И. Воробьев, Г.М. Хисамутдинов. М., 1967. 539 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр., Т. I, 1977. 476 б.; Т.III, 1981. 832 с.

Этнотерриториальные группы татар Поволжья и Урала и вопросы их формирования. Историко-этнографический атлас татарского народа. Казань, 2002. 248 с.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 94(47)

*И.К. Заһидуллин*

# МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН КИҢӘЙТҮ ТУРЫНДА КАЗАН СӘҮДӘГӘРЛӘРЕНЕҢ 1879 ЕЛГЫ «ПРОГРАММАСЫ»

В статье рассматривается важная страница татарского национального движения – петиция татарской буржуазии г. Казани 1879 г. за расширение религиозно-культурной автономии и прав мусульман и за достижение равноправия в религиозной сфере.

**Ключевые слова.** Казанские купцы, «мусульманский вопрос» в империи, Оренбургское магометанское духовное собрание, религиозно-культурная автономия мусульман.

Россиядә XIX гасырның икенче яртысында башланган модернизация йогынтысында татар җәмгатьчелегенә яңалыклар, нигездә, өч социаль төркем вәкилләре тарафыннан кабул ителә һәм таратыла. Сүз сәүдәгәрләр катлавы, мөселман руханилары һәм дворяннар хакында бара. Бу корпоротив төркемнәр үзләренең, сословие буларак, Россия җәмгыятендә торткан югары дәрәҗәләре буенча (дворяннар, гильдия сәүдәгәрләре) һәм гади халык арасында булган югары дәрәҗәләре (сәүдәгәрләр һәм руханилар) нигезендә төбәк һәм гомумтатар милли элиталары ролен үти башлый.

Шундый көчле һәм Урта Идел төбәгендә зур йогынтыга ия булган төркемнәрнең берсен Казан шәһәре гильдия сәүдәгәрләре тәшкил итә. Аларның күбесе авыллардан шәһәргә килеп урнашкан беренче яки икенче буын эшмәкәрләр була. Сәүдәгәрләр, милли элита буларак, мөселманнарны берләштерү өчен Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыяны файдаланырга кирәклеген аңлыйлар. Хакимиятнең 1870 еллардагы татарларга карата уздырылган милли сәясәте һәм ясаган адымнары мөселманнар арасында ризасызлыкны көчәйтә һәм сәүдәгәрләрнең социаль активлыгында чагыла.

Казан сәүдәгәрләренең активлашуына олыгайган мөфти С. Тәфкилевның авырып китүе һәм 1878 елның сентябереннән Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя утырышларында килмәве һәм рәислек итә алмавы хакында Уфадан килгән хәбәрләр сәбәп була [Материалы, с. 428]. Казыйлардан мөфтинең отставкага китәргә җыенуы хакында яшерен мәгълүмат алганнан соң, Казан сәүдәгәрләре аның урынына кандидатны башлап үзләре эзләргә булалар.

Хакимиятнең дине белеме булмаган отставкадагы офицер С. Тәфкилевне – аксөякләр, дворян вәкилен – мөфти вазифасына билгеләве мөселманнар арасында Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыяның абруе төшүгә китерә. Мөфти С. Тәфкилевкә карата татар җәмәгатьчелегендә төрле карашлар хакында Казан шәһәре ахуны Ш. Мәрҗани болай ди: «Кешеләргә дус һәм яхшы күренергә

тырышса да, үзе гыйлемсез, җөрьәтсез бер бәндә булды, һәр коткы салучының сүзенә авышканлыктан һәм карашларында тотрыклылык булмаганлыктан, мөстәкыйль бер эш тә башкара алмады» [Мәрҗани, б. 217].

Бу хакта фикерне беренче булып губернатор Н.Я. Скарятин 1878 елның ноябрь азагында Казан өязендә уздырылган хакимияткә буйсынмаган татар игенчеләрен солдатлар катнашында сuктыру вакытында ишетә. Татар крестьяннары мөфти сайлауны Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыяга караган барлык мөселман катнашына үткәрү зарурлыгын җиткерәләр [Фирсов, 1926, с. 41].

Чыннан да С.Тәфкилевнең мөфтилектән китәргә җыенуын ишеткәч үк, Казанда, губернада гына түгел, мөселманнар яшәгән башка төбәкләрдә дә сүзе үтә торган, дәрәҗәле сәүдәгәрләр – Исхак Гобәйдулла улы Юнысов, Вәли Кәрим улы Апанаев, Мортаза Мостафа улы Әҗемов һәм Мөхәммәтҗан Галиев – мөселманнар исеменнән губернатор Н.Я. Скарятинга үтенеч белән мөрәҗәгать итәләр. Алар мөфти вазифасына инде тәгаенләнгән дип үзләре фаразлаган Нигъмәтуллин (Оренбург төбәгеннән, Казан университетын тәмамлаган) яки Сираҗетдинов урынына, үз кандидатын – Тамбов губернасының Елантау өязенә кергән Әҗе авылы ахуны Сәйфулла Урмановны тәкъдим итәләр [Материалы, 1936, с. 428]. Эшкуарлар, мөфтилеккә дәгъва итүче башка кандидатлар ислам дине кануннарын яхшы белмиләр, диләр. Алар очрашу вакытында губернаторга эчке эшләр министрына үзләренең ни өчен Урмановны тәкъдим итүләрен аңлату өчен, Петербургка 4-5 кешелек депутация җибәрергә ниятләүләрен дә белдерәләр. Моңардан тыш, алар министрга мөселманнар язмышына кагылышлы башка мәсьәләләрне күтәрергә җыенуларын җиткерәләр. Чыганаклардан күренгәнчә, алар күрше регионнардагы күренекле мөселманнар белән оештыру эшләре дә алып барганнар. Аерым алганда, Елантау өязе исправнигы: «...Казан, Уфа һәм башка төбәк татарлары Урмановка хат юллаганнар һәм мөфти булырга тәкъдим иткәннәр» [Материалы, с. 428], дип хәбәр итә.

Илдә барган үзгәртеп корулар шартларында, сәүдәгәрләр, хөкүмәт алдында, Россия канунында язылган мөфти сайлау кагыйдәләрен үтәлү тиешлеге мәсьәләсен күтәрәләр.

Казан губернасының Спасс өязе исправнигы мәгълүматларына карагаранда, мөфти урынына кандидат мәсъәләсе Казан сәүдәгәрләре тарафыннан 1879 елның февралендә актив тикшерелгән. Мөфтинең отставкага чыгу турында сөйләшергә дип Санкт-Петербургка китүен ишетүгә, алар, фикерләрен үзгәртеп (бәлки Урмановның ризалык бирмәве сәбәпле) Казанның 1 нче мәчете имамы ахун Ш. Баһаутдинов (Ш. Мәрҗани) кандидатурасын мөфтилеккә тәкъдим итәргә килешәләр, моның өчен барлык чыгымнарын сәүдәгәрләр Юнысов, Апанаев һәм Апаков үз өсләренә алырга булалар [ТРМА, 1 фонд, 3 тас., 4468 сак. бер.]. Ш. Мәрҗани кандидатурасын Спасс өязе авылларының күп кенә муллалары да хуплыйлар [шунда ук].

Шунысы мөһим, сәүдәгәрләрнең 1879 елның гыйнварындагы губернаторга визиты зур әзерлек белән оештырыла. Дәрәҗәле

татарлар һәм муллаларның гыйнвар ае дәвамында һәм февраль башында Юнысов, Әҗемов, Казаков һәм башка сәүдәгәрләрнең өйләрендә җыелулары турында шәһәр полицмейстеры хәбәр итә [ТРМА, 1 фонд, 3 тас., 4468 сак. бер.].

Берничә көннән, гыйнвар азагында, губернатор белән элекке килешү нигезендә, сәүдәгәрләр Н.Я. Скарятинга Санкт-Петербургка барачак депутациянең (коммерция советнигы И.Г. Юнысов, «мактаулы гражданнар» И.И. Апаков, В.К. Апанаев, 2 нче гильдия сәүдәгәрләре М.И. Галиев һәм М.-Ш.А. Үтәмешев) исемлеген һәм Эчке эшләр министрлыгында күтәрергә уйлаган мәсьәләләрне язып тапшыралар. Н.Я. Скарятин 1879 елның 29 гыйнварында Эчке эшләр министрлыгы идарәчесе Л.С. Маковка язган хатында, яңа мөфти кандидатурасын сәүдәгәрләрнең үзләре аша хәл итәргә ниятләүләре хакында 26 гыйнвардагы язган хәбәрен исенә төшереп, сәүдәгәрләр үтенеченең калган пунктларын бәян итә.

Эчке эшләр министрлыгы идарәчесе Л.С. Малов 2 нче февраль көнне кул куйган хатында татарларның мондый башлангычын дәүләт эшләренә кирәк булмаган тыкшыну, ә мөфтилеккә кеше тәкъдим итүне вакытсыз дип бәяли һәм депутациягә башкалага килүен тыя [шунда ук, б. 9].

Татарстан Республикасы Милли архивында Казан сәүдәгәрләренең яшерен киңәшмәләрендә эшләгән һәм губернаторга тапшырган таләп-«программа»ның оригиналы саклана. Аның беренче пунктында Россия мөселманнарына отставкага китәргә ниятләгән мөфти С. Тәфкилев урынына «үзебезнең руханилар арасыннан лаеклы һәм дини белемле затны» сайларга «тулы хокук» бирелүен таләп итү турында язылган [шунда ук, б. 13]. Бу үтенечнең беренче пункт итеп урнаштырылуы сәүдәгәрләр өчен яңа мөфти сайлауның беренчел әһәмияткә ия булуын раслап тора. Әйтергә кирәк, бу вакытта Россия кануннында Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя округы мөселманнарның мөфти сайлауга хокуклары булу турында язылган була. Икенче төрле әйткәндә, сәүдәгәрләрнең бу үтенече «канун кысаларында» язылган. Чынлыкта хакимият «ышанычлы» мөфтине үзе билгеләп куя, бу канунны үтәмәскә ияләнә, шул ук вакытта юкка да чыгармый.

Мөфтине Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнарының рухи башлыгына (әмир әл-мумин) әверелдерү концепциясе Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыяның казыйларын да приходлар вәкилләре тарафыннан сайлап кую турындагы фикере белән үрелеп барыла. Бу хакта канунда: «Члены духовного собрания избираются магометанским обществом, каждый на три года, и утверждается местным начальством», дип язылган була [Уставы, 1896, ст. 1237]. Шулай итеп, үтенечнең икенче пункты да рус самодержавиясенең исламга кагылышлы канунннарын хакимиятнең тайпылышсыз үтәргә тиешлегенә кайтып кала. Сайлаулар уздырылган очракта, Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя тарафыннан кабул ителгән карарлар мөселманнар өчен канун көченә ия була. Әлеге үзгәрешләр Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя округында дини-мәдәни автономияне тулы хокуклы мөселман җәмгыяте дип аталган яңа

дәрәҗәгә күтәрергә тиеш була. Бу ике пункт үтәлгән очракта, Дини идарә Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнарның чын мәгънәсендә сайланган вәкиллекле органына әверелә.

Сәүдәгәрләрнең башка үтенечләре мөселманнарның дини эшләре белән җитәкчелек итүне һәм аларның христианнар өстенлек иткән дәүләттә яшәү шартларын үзгәртүгә, мөселманнарга да рус халкы белән тигез хокуклар таләп итүгә юнәлдерелгән. «Программа»ның баштагы ике пунктының дәвамы булып Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыяның мөфтиенә һәм казыйларына хезмәт хакларын күтәрү турындагы үтенеч тора. Православие дәүләт дине булып саналган илдә дини эшләрне алып бару өчен чыгымнар бүленүен истә тотып, Казан сәүдәгәрләре күтәргән Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыягә чыгымнарны арттыру фикере күптәп өлгергән мәсьәлә иде, ә сәяси яктан ул дини оешманың һәм мөселманнарның илдәге статусын чагылдыручы маркер була. Казыйлар 1836 елгы канун нигезендә бары тик 284 сум 28 тиен күләмендә еллык хезмәт хакы алалар. Бәяләр артуга, Уфа шәһәрендә тормыш кыйммәтләнүгә күз йомып, 40 ел дәвамында хезмәт хакының үзгәрешсез калуын хакимиятнең исламга карата гадел булмаган мөнәсәбәте белән аңлатырга мөмкин. Мәгълүм ки, бу вакыт аралыгында Россиядә губерна һәм өяз учреждениеләрендә эшләүче чиновникларның да, чиркәү руханиларының да хезмәт хакы арттырыла. Мөфти С. Тәфкилев тырышлыгы белән 1877 елдан эчке эшләр министры мөселманнарның никах җыемнарының бер өлешен Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя канцеляриясенең хезмәткәрләренә өстәмә түләү рәвешендә кулланырга рөхсәт бирә.

Казыйларының хезмәт хакы кечкенә булу сәбәпле, Казан губернасының белемле имамнары казыйлыкка сайланудан баш тарталар. Нәтиҗәдә, казыйлар итеп белем ягыннан бик үк лаек булмаган затларны расларга туры килә. Утырышчыларның хезмәт хакы түбән булганга, аларның кайберләре төп вазыйфаларын үтәү урынына, читтән өстәмә табыш чыганагы эзләргә мәҗбүр булалар.

1836 елдан бирле мөфтинең дә хезмәт хакы элеккечә саклана – елга 1572 сум тәшкил итә. С. Тәфкилев кебек бай һәм эре алпавыт өчен хезмәт хакының күләме әллә ни зур роль уйнамый. Әмма аның урынына килгән күп балалы М. Солтанов мөфти вазифасын кабул итәргә хезмәт хакын хакимият 5 мең сумга, өч тапкырдан артыкка, күтәрергә вәгъдә ителгәч кенә риза була [РДТА, 821 фонд, 8 тас., 1068 сак. бер.].

Сәүдәгәрләр үтенеченең тагын берсе – шәригать кануны буенча мөлкәт һәм мирас бүлү системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән була. Яшәп килүче канун буенча, имам, мөрәҗәгать иткән очракта, үз мәхәлләсе мөселманының мөлкәтен бүлергә хокуклы була. «Гражданлык законнары»ның 1338 нче маддәсендә дини кануннар буенча мөселманнарның мөлкәтләрен бүлү хакында болай диелгән: «Раздел имуществ, оставшихся после магометан, производится по их закону. Но магометанское духовенство, подведомственное Оренбургскому магометанскому духовному собранию, имеет право рассматривать и решать по своему закону дела о частной

собственности, возникающие по завещаниям или при разделе имений между наследниками только тогда, когда участвующие в сих делах магометане будут просить об этом и примут беспрекословно объявленные им решения: разделы, в сем случае совершаемые, утверждаются в надлежащем присутственном месте. Но если участвующие в делах объявят на решение духовенства, касающегося до их собственности, неудовольствие и обратятся с просьбою к гражданскому начальству, то рассмотрению сих дел предоставляется обыкновенным судебным местам по установленному общими узаконениями порядку» [Законы гражданские, ст. 1338].

Әмма кайвакыт руханиларның шәхси мәнфәгатьләре белән бәйле рәвештә шаригать кануннарын бозу очраклары да күзәтелә. Яисә кеше, мулла чыгарган карардан риза булмыйча, дәүләт мәхкәмәсенә мөрәҗәгать итә алган. Мондый күренешләр мөселманнар арасында шаригать кануннарының, муллаларның дәрәҗәсен төшергән, «икенче» планга куйган.

Шуңа күрә сәүдәгәрләр милек яки мирас бүлү кебек һәр кеше өчен мөһим эшне фәкать «чын лаеклы һәм диндар», абруйлы имамнарга рөхсәт итү ягында булалар. Алар фикеренчә, милек һәм мирас бүләргә хокуклы имамнарны һәр төбәк өчен Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя билгеләп куярга тиеш, бу башка имамнар әлеге хокуктан мәхрүм ителәчәк, дигән сүз. Шушы юл белән сәүдәгәрләр шәригать мәхкәмәсен гадел мәхкәмәгә әйләндерергә уйлыйлар.

Бу проблеманың икенче ягын – мөселманнарның мөлкәтләрен бүлү буенча дәүләт мәхкәмәсенә мөрәҗәгатьне тыю турындагы мәсьәләне – алар губернатор белән сөйләшкәндә күтәрәләр. Бу хакта «программа»да язылмаган. Биредә ике төрле фараз булырга мөмкин. Беренчедән, шәригать мәхкәмәсен сайлаган кеше, аның карарыннан риза булмаса, дәүләт округ судына мөрәҗәгать итү хокукын югалта, яки ул баштан ук дәүләт мәхкәмәсенә мөрәҗәгать итәргә тиеш. Икенче фараз итеп мөселманнарның милек, мирас бүлү мәсьәләләрен фәкать шәригать кануннары нигезендә генә хәл итүен күрсәтергә мөмкин.

Санкт-Петербург университеты профессоры И.Г. Нофаль, Казан сәүдәгәрләренең Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя округына кергән мөселманнар мөлкәтен бүлү эшенә Россия судларын катнаштырырга теләмәве хакындагы үтенечләренә җавап итеп, ул чагында Франция колониясе булган Алжир тормышыннан мисал китерә: анда да мөлкәт бүлү шәригатькә таянып тормышка ашырылган, әмма казыйның карары ике якның да ризалыгы булганда гына үз көченә кергән. Кайсы да булса бер як апелляция биргән очракта, мәсьәлә француз суды тарафыннан хәл ителгән. Россиядә мөселманнарга карата административ һәм сәяси күзәтчелек системасы урнаштырылу Алжирдагы һәм Бөекбританиянең Һиндстан биләмәләрендәге кебек тәртипләргә тәңгәл килә. Көнчыгыш белгече, шуны истә тотып, Казан сәүдәгәрләренең бу үтенечен «дини» мәсьәлә буларак түгел, ә матди һәм социаль мөнәсәбәтләр яссылыгында бик кискен бәяли: ул бу теләкне хакимияткә каршы көрәшүгә, хокукка ия булырга омтылуга, хәттә аның барлыгын

танымауга омтылуга тиңли [Материалы, 1936, с. 426–427].

Сәүдәгәрләрнең хөкүмәт һәм иҗтимагый оешмаларда эшләүче мөселманнарга җомга көнне һәм башка ислам дини бәйрәмнәрендә ял бирелүен сорап язган үтенече мөфти С. Тәфкилевнең 1878 елда Эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгате белән тәңгәл килә. Биредә сүз тигез хокуклылык турында бара, чөнки якшәмбе көн христианнарның ял көне санала. XIX гасыр азагында Россиядә ел дәвамында 77–79 көн ял итәләр (шуларның 52 се – якшәмбе, калганнары – «патшаның табель көннәре» һәм провославие дине бәйрәмнәре), бу көннәрдә мөселман эшмәкәрләренең сәүдә-сәнәгать предприятиеләре дә эшләми. Шуны да истә тоту мөһим, бу чорда Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя һәм Татар укытучылар мәктәбендә, рус-татар (башкорт) башлангыч мәктәпләрендә, мәдрәсәләр каршындагы рус сыйныфларында эшләүчеләр һәм укучылар җомга көнне, хәрби ведомстволардагы мөселман хәрби хезмәткәрләре Рамазан һәм Корбан бәйрәмнәрдә өч көн ял итәләр, әмма бу башка казна оешмаларында кулланылмый [Загидуллин, 2006, с. 345].

Профессор И.Г. Нофаль, бу мәсъәләне шәригать күзлегеннән бәяләп, ислам динендә җомганы бәйрәм итү көндезге җомга намазы вакыты белән генә билгеләнә, дип яза, аның фикеренчә, мөселманнар Рамазан һәм Корбан бәйрәмнәрендә генә ял итүгә хокуклы [Материалы, с. 423–424].

Сәүдәгәрләрләрнең соңгы ике үтенече 1870 елларда мөселманнарга карата уздырылган хөкүмәт сәясәтенә җавап рәвешендә язылган. 1870 ел, 26 март «Россия яшәүче инородецларга белем бирү буенча кагыйдәләр»дә киләчәктә мөселман руханилары өчен рус телен белү мәҗбүри булачак дип белдерелә, ә 1874 елны Идел–Урал төбәге мөселман мәктәп-мәдрәсәләре Халык мәгарифе министрлыгы карамагына тапшырыла. Сәүдәгәрләр мәдрәсәләрне, имамнарны һәм мөдәррисләрне Халык мәгарифе министрлыгына буйсынуыннан азат итү һәм имам, мөдәррисләргә рус телен белүне мәҗбүри итмәүне хакимият тарафыннан гарантияләүне, икенче төрле әйткәндә, инде кабул ителгән кануннарны үзгәртүне сорыйлар.

Аларның борчылулары урынлы була. Халык мәгарифе министры Д.А. Толстой тарафыннан 1877 елда Дәүләт Советына тәкъдим ителгән проектта түбәндәгеләр билгеләнә: 1878 елның 1 гыйнварыннан мөселман мәктәпләрендә укытучылар һәм рухани дәрәҗәгә омтылучылар өчен русча уку һәм яза белү бурычын куюю карала, ә 1880 елның 1 гыйнварыннан – башлангыч белем бирүче мәдрәсәләр каршындагы рус сыйныфларында программа күләмендә белемле булу бурычы билгеләнә, шулай ук киләчәктә яңа мәктәпләрне фәкать халык хисабына тотыла торган рус сыйныфы булганда гына рөхсәт бирү карала. Бу тәкъдимнәр 1878 елда Дәүләт Советында тикшерелә, әмма яклау тапмый [Фәхретдин, 2011, б. 165–166]. Күрәсең, Казан сәүдәгәрләре хөкүмәтнең ниятләрен якташлары – Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя казыйлары аша белгән булса кирәк. Проект 1877–1878 еллардагы рус-төрек сугышы сәбәпле кичектерелгән була. Сугыш Россия җиңүе белән тәмамлагач, аны тормышка ашыру өчен нииндидер сәяси киртә-

ләр калмады, дип уйланылган, күрәсең.

Сәүдәгәрләр үтенечендә соңгы мәсьәлә – 1874 елгы гомуми хәрби хезмәт үтәү бурычы турындагы уставта рус урта мәктәпләрендә укучыларны уку дәверендә вакытлыча хәрби хезмәттән азат итү ташламасын мәдрәсәләрдә укучы шәкертләргә дә куллану турында гозер [Материалы, с. 421–422; ТРМА, 1 фонд, 3 тас., 4468 сак. бер.].

Сорау туа: ни өчен сәүдәгәрләр үз фикерләрен язма рәвештә генә теркәп җибәрмәгәннәр? Эчке эшләр министрлыгының мөселманнар депутациясе белән очрашудан баш тартуы үзәк хакимиятнең алар фикере белән исәпләшергә теләмәвен аңлаткан. 14 февральдә Исхак Гобәйдулла улы Юнысов, Вәли Кәрим улы Апанаев, Мортаза Мостафа улы Әҗемов һәм Мөхәммәтҗан Галиев Эчке эшләр министрлыгы управляющиеның карары белән белән танышуларын имзалары белән раслыйлар [ТРМА, 1 фонд, 3 тас., 4468 сак. бер.]. Кул куйганнан соң башкалага бару хакимияткә ачыктан-ачык каршы чыгу буларак бәяләнер иде.

Бер үк вакытка хөкүмәт авыру С. Тәфкилевне мөфти булып калырга күндереп, сәүдәгәрләр «программа»сының беренче маддәсен «хәл итә» [Материалы, с. 432–433]. Шулай итеп яңа мөфти сайлау көн тәртибеннән төшеп кала.

Казан сәүдәгәрләренең «программа»сы, андагы фикерләр хөкүмәткә Казан губернаторы рапорты аша җиткерелә. Аңа Санкт-Петербург университеты профессоры И.Г. Нофаль, ислам буенча белгеч буларак, эксперт бәяләмәсе яза.

Гомумән алганда, Казан сәүдәгәрләренең 1879 елгы программасы 1905 елга кадәр татар милли хәрәкәтенең иң югары дәрәҗәдә һәм комплекслы төзелгән документы булып тора. Анда мөфтине Россиянең Европа өлеше һәм Себер мөселманнары җәмгыятьләренең рухи башлыгы итү, Мәхкмәи шәргыя Ырынбургыяны татар һәм башкортларның баш, югары вәкаләтле, сайланып куелган дини оешмасына әйләндерү фикере салынган була. Татар сәүдәгәрләр катлавының төп сәяси таләбе – мәктәп-мәдрәсәләрне хакимият карамагыннан алу һәм аларны элеккечә хөкүмәтнең, аларга ышаныч белдереп, башкалар өчен ябык саналган бу өлкәгә катнашмавына ирешү була.

Милли мәгариф системасын хөкүмәт опекасыннан һәм буйсынуыннан азат итү мәсьәләсе аннан соңгы елларда күзәтелгән петиция кампанияләренең төп таләпләренең берсе булып кала.

Мөселманнарга руслар белән тигез хокуклар бирү кирәклеге турындагы фикерләр татар сәүдәгәрләренең сәяси аңы һәм хокукый белеме үсә баруын ассызыклый. 1879 елгы «программа» әле татарлар арасында җәдитчелек хәрәкәте көч алганчы ук татар буржуазиясенең, үзен милләттең юлбашчысы итеп тоеп, иҗтимагый көч сыйфатында сәяси мәйданга чыгуын раслый.

**Әдәбият**

*Загидуллин И.К.* Мусульманское богослужение в учреждениях Российской империи (Европейская часть России и Сибирь). Казань : Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2006. 361 с.

Законы гражданские. Изд. 1890 г. // Свод законов Российской империи. Т. 10. Ч. 1.

Материалы по истории Татарии второй половины XIX в. М.; Л.: Издательство Академии наук СССР, 1936. Ч. 1. 512 с.

*Мәрҗани Ш.* Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 416 б.

ТРМА (Татарстан Республикасы Милли архивы), 1 нче фонд, 3 нче тасвирлама, 4468нче саклау берәмлеге.

РДТА (Россия дәүләт тарих архивы), 821 нче фонд, 8 нче тасвирлама, 1068 нче саклау берәмлеге.

Уставы духовных дел иностранных исповеданий. Изд. 1896 г. // Свод законов Российской империи. Т. 11. Ч. 1.

*Фәхреддин Ризаэддин.* Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр: сайланма хезмәтләр. Казан: Рухият, 2011. 344 б.

*Фирсов Н.Н.* Прошлое Татарии (краткий научно-популярный исторический очерк). Казань, 1926. 47 с.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,*** *тарих фәннәре докторы,*
*Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының*
*Урта гасырлар тарихы бүлеге җитәкчесе,*
*e-mail: zagik63@mail.ru*

УДК 94 (47)

*Э.К. Сәлахова*

# КАЗАННЫҢ БОЛГАРГА МӨНӘСӘБӘТЕ

История Казанского государства — сложная историческая тема, в ней существуют ряд нерешенных проблем. Одним из таких являлся вопрос о происхождении Казанского ханства и его взаимосвязь с Булгарским государством, отношение к Золотой Орде. Автор статьи рассматривает и изучает постановку и решение данной проблемы в научном наследии татарского историка начала XX века Г.Н. Ахмарова.

**Ключевые слова:** Булгарское государство, Казанское ханство, Г.Н. Ахмаров, история татарского народа, национальная история, Золотая Орда, ханы Казанского ханства.

Татар тарихы, татар дәүләтләре тарихы шактый катлаулы темаларның берсе, шуңа күрә дә күп кенә мәсьәләләрнең чишелешенә әлегә кадәр нокта кую мөмкинлеге юк. XIX йөз ахыры – XX йөз башында, татар тарих фәне туып кына килгән чорда, бу проблемаларның никадәр күп булын күзаллавы кыен түгел. Г. Әхмәрев үз хезмәтләрендә татар тарихының Болгар, Казан чорына караган күпсанлы мәсьәләләренә кагылырга, мөмкинлеге булган кадәр өйрәнергә тырыша. Аның хезмәтләренең барысында да диярлек бәйләп тора торган мәсьәлә ул – Болгар белән Казан мөнәсәбәте: дәүләтләр мөнәсәбәте, аларның халкының мөнәсәбәте. Хәтта «Казан тарихы» хезмәтенең беренче бүлеген «Казанның Болгарга мөнәсәбәте» дип исемләп, беренче итеп шушы проблеманы куюны кирәк таба.

Казан ханлыгының нигезләнүе, аны нигезләү вакыты хакында хәзерге көндә фәндә бертөрле генә караш юк. Бер төркем галимнәр, Казан ханлыгы Алтын Урда – Җүчи олысыннан башлангыч ала, дисәләр, икенче фикер-карашлылар аның тарихын турыдан-туры Болгар дәүләте белән бәйлиләр [Сафаргалиев, с. 280–524; Алишев, с. 186–200]. Г. Әхмәревнең тикшеренүләре дә соңгы карашны дәлилләүгә хезмәт итә [Гайнетдин..., б. 381]. Гомумән, XX йөз башы татар тарихчылары үз хезмәтләрендә Болгар белән Казанның турыдан-туры мөнәсәбәтләре булуны раслыйлар [Мәрҗани; Атласи; Баттал].

Г. Әхмәрев: «Болгар вә Казан, гадәттә, бер-берсеннән аерым, ягъни икесе ике мәмләкәт кеби, саналып йөртелсәләр дә, боларның тарихи хәлләрен дикъкать илә тикшергәндә, бер-берсенә мөнәсәбәтләре, хәтта икесе бер мәмләкәт булганлыгы ачыклана» [Әхмәрев], дип яза. Бу сүзләр, аның күпсанлы тикшеренү хезмәтләрендә төрле фактлар белән раслана. Беренче дәлил итеп, Казан ханлыгында шул ук төрки-болгар халкы яшәгәнлеген, аларның бөтен гореф-гадәтләре, көнкүреше, кәсепләре, һөнәрләре болгар халкы белән берүк булуын күрсәтә.

Моның шулай икәнен ул казу эшләрендә катнашкан археолог буларак та белдерә. Г.Н. Әхмәрев XX йөз башы башка татар тарихчыларыннан рус телен камил белүе белән аерылып тора, шуңа да ул үзенең хезмәтләрендә киңрәк даирә язма тарихи чыганакларны куллана алган, ягъни аның хезмәтләрендә рус елъязмалары актив кулланыла, һәм бу мәсьәләнең чишелешендә дә рус елъязмаларыннан да дәлилләр китерә. Рус елъязмаларына (вакаигънамәләрендә) Казан халкы «Казан болгарлары» (Болгары, глаголемы казанцы) дип язылган. Моннан тыш, шул ук чыганакларда рус патшаларының титулларының берсе «князь Булгарский», дигәне дә була, 1487 елда рус патшасы Иван III, Казанга яу белән килгәннән соң, үз титуллары арасына «Государь Булгарский» дигәнен дә өсти, гәрчә, бу вакытта инде Болгар дәүләте булмаса да. Бу момент та Казанның Болгар дәүләте дәвамчысы булуына, күршеләр тарафыннан икесе бер мәмләкәт буларак кабул ителүенә сылтама. Моннан тыш, 1675–1686 елларда Казан митрополиты Иосаф документларда «Казан һәм Болгар митрополиты» итеп бирелә. Г. Әхмәрев тарихи тикшеренүләренең тагын бер мөһим чыганагы – ул татар халык авыз иҗаты, халык хәтерендә булган тарихи моментлар тарихның кайбер четерекле мәсьәләләрен ачыклаганда юнәлеш бирүче бер башлангыч була ала. Бу очрак та да, тарихчы арларның (удмуртларның) хәтта XX йөз башына кадәр татарларны «болгарлар», яисә «бигерләр» дип атавын яза. (Г. Әхмәрев Вятка губернасы Алабуга өязе Биектау авылында укытучы булып эшли һәм ул арлар белән якыннан аралашкан).

Г. Әхмәрев үзенең хезмәтләрендә дәүләтне Казан ханлыгы дип атамый, аңарда ул Казан мәмләкәте, дип бирелә. Аның фикеренчә, Казан ханнарының күбесе чыгышы белән Алтын Урда (Җүчи олысыннан) булсалар да, дәүләтнең идарә системасы Алтын Урда системасын түгел, ә, башлыча, Болгар дәүләтенең үзәк власте структурасын хәтерләтә. Дәүләт идарәсен Г. Әхмәрев «Хан хозурында һәрвакыт әгъяне дәүләт булып, аларның үзләренә махсус хокуклары булган. Мәмләкәт идарәсенә катнашып, хан алардан башка үзе генә идарә кыла алмаган. Алтын Урданың идарәсе бу рәвешле булмаган, анда хан ялгыз үзе генә, ягъни һәр эшен үзе теләгәнчә кылган» [Әхмәрев, 116 б], дип характерлый. Тагын бер дәлил – ул нәселдән-нәселгә тапшырылып килә торган титуллар. Г. Әхмәрев алар турында болай яза: «Казанда нәселдән килә торган (ягъни атадан угылга кала торган) бикләр вә морзалар сыйныфы да булган» [Әхмәрев].

Икенче зур мәсьәлә – Казан дәүләтенең идарәчеләре, ханнары. «Казан тарихы»нда галим «Казан ханнарының исемнәре вә ханлык кылган мөддәтләре» дигән бер исемлек бирә һәм, үзе язганча, Казанның сәяси тарихы шактый катлаулы булганлыктан, эшнең профессионале булмаган кешегә бу буталчык вакыйгаларны аңлау бик кыен икәнлеген аңлап, хезмәтен ханнарның исемнәре һәм алар идарәлек иткән вакытта булган вакыйгаларны сөйләү рәвешендә бәян итә. (Аның «Болгар тарихы», «Казан тарихы» кемнәрдер алдында сөйләү өчен әзерләнгән лекция

формасында язылган) [Казан…; Хотбә...; «Шәрык клубы»нда...]. Г. Әхмәров хезмәтендәге исемлек без гадәтләнгән Олуг Мөхәммәд, яисә, Мәхмүд (Мәхмүтәк)тән башланмый. Исемлек Алтынбәк, аннан Галимбәк дип китә. Алар – татар риваятьләрендә сөйләнгән Габдулланың уллары. Риваять буенча, Әмир Тимер Болгарны туздырганнан соң, һәлак ителгән Габдулла ханның улларын – Алтынбәк белән Галимбәкне – коткарып калалар һәм алар Иске Казан урынына килеп, кальга (крепость) корып, Казан ханлыгына нигез салалар. Соңрак Алтынбәк хаҗ сәфәренә китеп, шунда һәлак була, ә идарә Галимбәккә күчә. Халык күңелендәге тарихи вакыйгаларда шулай диелә. Галим, билгеләп үтелгәнчә, мондый риваятьләрне беркайчан да инкяр итми, ә, киресенчә, аның дөреслеген яисә ялгышлыгын тарихи чыганаклар, үзенең тикшеренүләре белән раслый. Бу очракта да, Алтынбәк белән Галимбәк идарәсе елларында ике дәүләт – Болгар белән Казан мөнәсәбәтен, аларның бер-берсенә бәйләнешен эзли. Рус елъязмаларында Либей дигән тарихи шәхес турында мәгълүматлар бар, Г. Әхмәрев фикеренчә, нәкъ менә шул Либей дигән кеше Галимбәк булырга тиеш тә инде, чөнки Галимбәк исеме рус орфографиясе тәртипләре буенча, Алимбек рәвешендә әйтелгән, тора-бара олы (карт) кеше буларак аны Али баба дип атаганнар, рус елъязмаларында Али баба Либей буларак язылган, Вельяминов-Зернов та Либей – Алибәкнең үзгәртелгән (бозылган) формасы дигән караштa торган [Вельяминов-Зернов]. Галимбәк (Алибек, Али баба), рус елъязмалары буенча, Либей Мәхмүд хакимияткә килгәнчегә кадәр әле исән була. Г. Әхмәрев фикере буенча, хакимият өчен көрәштә Олуг Мөхәммәд, аның улы Йосыф белән бергә Галимбәк тә Мәхмүд тарафыннан үтерелә.

Тарих фәнендә Казан ханлыгының нигезләнү вакыты, нигезләүчесе хакында ике караш бар: аның берсе Казанны нигезләүче итеп Олуг Мөхәммәдне саный, һәм 1436–1437 елларны күрсәтә, ә икенчесе исә, Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүд белән бәйләп, 1445 елны атый. Г. Әхмәрев бу хакта үз фикерен белдереп, болай дип яза: «Казан хөкемдарларының ышанычлырак тарихы татар ханнарыннан гына, ягъни, Сарайдан күчеп килгән Олуг Мөхәммәд ханнан гына башланадыр.» Аның бу сүзләре Казан ханлыгын нигезләүче, һичшиксез, Олуг Мөхәммәд дигән карашны раслауга юнәлдерелмәгән. Киресенчә, ханнар исемлегендә Олуг Мөхәммәд өченче буларак кына бирелә. Аның белән бәйле тарихи вакыйгаларны сурәтләгәндә, сүз сөрешеннән дә Олуг Мөхәммәд шәхесе болгар-татар дәүләтенең чираттагы идарәчәсе буларак аңлашыла. Г. Әхмәров Олуг Мөхәммәд идарәсе елларында дәүләтнең элеккеге мәшһүрлеге торгызылуны, бу гамәлдә Олуг Мөхәммәднең бәһасез ролен билгели. Яңадан торгызылган Болгар дәүләте, яңа башкаласының исеменә нисбәтле рәвештә, Казан ханлыгы дип атала башлый, дигән фикер яңа дәүләт төзелүе турында түгел, ә Идел буенда торгызылган, яңартылган, куәтләнгән дәүләтне күрергә теләүне аңлата.

Өченчедән, Болгар белән Казан дәүләтләренең мөнәсәбәте авторның Казан шәһәре тарихын

сурәтләвендә дә чагыла, бу очракта да ул шул фикеренраслый.

Казан ханлыгының башкаласы булган Казан шәһәре, Г. Әхмәрев фикеренчә, һичшиксез, болгарлар шәһәре. Моңа дәлил итеп, ул берничә моментны атый: елганы һәм шәһәрне аңлата торган «Казан» сүзе – төрки сүз, Казанның саклану корылмалары Болгар шәһәрләренең корылмалары белән берүк төрле, Казан шәһәре янында сакланып калган зиратларда куфи язмалы болгар чоры каберташлары бар, Воскресенская, Новгородская, Софийская, Львовская, Костромская рус елъязмаларында рус князе Юрий Дмитриевич (Василий I бертуганы) яулап алган болгар шәһәрләре арасында, Великие Булгары, Жукотин (Җүкәтау), Кирменчук (Кирмәнчек) белән бергә, Казан шәһәре дә атала.

Г. Әхмәрев фикере буенча, Югары Идел буенда төзелгән төрки-болгар дәүләте үз тарихында 2 этапны үтә: аның берсе – башкаласы Болгар шәһәре булган Болгар дәүләте дәвере, ә икенчесе – башкаласы Казан шәһәре булган Казан ханлыгы чоры. Дәүләтнең исеме бары тик башкала исеменә бәйле рәвештә генә үзгәргән, ә аның эчтәлеге шул ук. Идел буенда оешкан Болгар дәүләте үзенең яшәешен Казан ханлыгы исеме белән 1552 елгы фаҗигале вакыйгага кадәр дәвам итә. Дәүләтне ханлык дип атау Сарайдан килгән идарәчеләр тарафыннан гына башлана. Иске Казан чоры исә, Болгар дәүләте белән Казан ханлыгын бәйләүче, тоташтыручы дәүләт тарихында бер вакыт аралыгы. Г. Әхмәрев хезмәтләрендә Алтын Урда дәүләте Казан чорына кадәр яшәгән күрше бер дәүләт рәвешендә бирелә, бу дәүләт таркалгач, аның югары катлам вәкилләренең бер өлеше Идел буена килеп сыеналар. Сарайдан чыккан ханнарның, идарәчеләрнең дәүләтне торгызу өчен куйган көчләрен, аның дан-шөһрәтен кайтарудагы рольләрен билгеләү белән бергә, ул – Казан ханлыгын көчсезләндерүгә, ахырда яуланып алынуына китергән сәбәпләрне дә шуларда күрә. «Яңа Казанда хөкүмәт тоткан ханнарның күбесе Алтын Урдадан чыккан адәмнәр булганнар. Шулар белән күп татар кенәзләре килеп, Казанда үзара низаглашып, һәрдаим фетнә чыгарып торганнар. Шул ихтилаф вә низаглар сәбәпле, Казан ханлыгы да зәгыйфьләнеп, ахырында Мәскәү милкенә кереп калган», дип яза [Әхмәрев].

**Әдәбият**


Алишев С.Х. Казанское ханство. Возникновение и развитие // Материалы по истории татарского народа. Казань, 1995.

Атласи Һ. Себер тарихы. Сөембикә. Казан ханлыгы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 446 б.

Әхмәрев Г. Казан тарихы. Казан: Бәянелхак, 1910. 116 б.

Баттал Г. Татар тарихы. Казан: Өмет, 1916. 127 б.

Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. Ч.1 СПб., 1863. 558 с.

Гайнетдин Әхмәрев: тарихи-докукументаль җыентык / төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, Э.Сәлахова. Казан: Хәтер, 2000. 384 б.

Казан тарихы хакында лекция // Бәянелхак. 1909. 15 февраль.

Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 414 б.

Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций. М.: Инсан, 1996.

Хотбә вә лекция // Йолдыз. 1908. 4 май.

«Шәрык клубы»нда тарих дәресе // Йолдыз. 1908. 16 ноябрь.

***Сәлахова Эльмира Кадим кызы,*** *тарих фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 94(47):82–94

*Х.З. Баһаветдинова, Р.Р. Исхаков*

# XIX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА КАЗАН АРТЫ КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫ ТОРМЫШЫНЫҢ УКЫТУЧЫ Т.И. ТИМӘЙ КӨНДӘЛЕГЕНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ

В публикации представлен отрывок из дневника известного кряшенского просветителя, педагога и миссионера Тимофея Ивановича Тимея, который показывает картину быта и нравов кряшен Заказанья, а также раскрывает причины и особенности исламизации местного населения. Этот документ является одним из первых произведений письменного художественного творчества кряшен, раскрывает особенности народных говоров татар Заказанья второй трети XIX в.

**Ключевые слова:** история и этнография татар-кряшен, межконфессиональные отношения в Среднем Поволжье, история татарских селений Заказанья.

Казан арты административ яктан Казан губернасының Казан өязенә кергән төньяк-көнчыгыш районнары керәшен татарлары тупланып яшәгән төбәкләрнең берсе булып санала. Явыз Иван IV заманнарында, Казан ханлыгы буйсындырылганнан соң, бу төбәк татарларны православие диненә чыгару үзәкләренең берсенә әверелә. Монда иң борынгы керәшен авылларыннан Апаз, Түбән Әзәк (хәзерге Арча районда), Карадуган (Балтач районына керә) һ.б. урнашкан. Мишә, Түбән Кама аръягы, Урал буе керәшен авылларының күбесенә нигез салучылар шушыннан чыкканнар. XIX гасыр уртасына Казан өязендә 2500 керәшен татары исәпләнә. Алар керәшен татарларының үзенчәлекле традицион мәдәниятенә һәм дини-мифологик күзаллауларга ия булган аерым бер этнотерриториаль төркем хасил итәләр.

XIX гасырның икенче яртысында керәшен татарлары җәмгыятендә патриархаль тәртипләрне үзгәртү процессы башлана, традицион кыйммәтләр системасында торгынлык, мөселманнар белән мәдәни бәйләнешләрнең ныгуы күзәтелә. Бу хәлләр алар каршына алга таба үсеш юнәлешен сайлау мәсьәләсен куя, гомумтатар мәдәни киңлегенә кушылу теләген ныгыта. Моның табигый нәтиҗәсе җирле керәшеннәрнең исламга чыгуында күренә. XX гасыр башына Казан өязендә яшәгән кайбер авыллардан тыш (православие дине юнәлешен саклаган керәшен татарларының иң зур төркеме Яңасала авылында кала), барлык керәшен татарлары диярлек исламга күчә. Әлеге процесс үз үзенчәлекләрен саклап калу белән «чын» татарга әйләнү арасында барган катлаулы, каршылыклы, еш кына драматик вакыйгалар дулкынында бара.

Бу тема буенча иң әһәмиятле чыганакларның берсе – Түбән Әзәк авылындагы Изге Гурий борадәрлеге миссионерлык мәктәбе укытучысы, күренекле керәшен мәгърифәтчесе Тимофей Иванович Тимәйнең көндәлек дәфтәрләре. Язылу вакыты

1873 ел белән билгеләнгән әлеге документ 1871 елны исламга чыгарга рәсми үтенеч биргән Түбән Әзәк авылы кешеләренең көнкүрешен, әлеге адымны ясарга этәргән сәбәпләрне ача. Язмаларның кыйммәте – бу процессның эчтән торып, вакыйгаларда катнашучы күзлегеннән сөйләнүендә. Бу документ, керәшен татарларының исламлашу күренешен генә аңлатып калмыйча, әлеге төбәктә яшәгән керәшен татарларының үзләрен кем итеп тоюларын, татарлардан булулары хакындагы тарихи хәтерне саклап яшәүләрен, мөселман кардәшләре белән мәдәни бәйләнешләрне саклауларын ачык күрсәтә. Кызыклы мәгълүматларны үзенә сыйдырган тарихи документ булу белән бергә, ул бу чорда Казан арты төбәгендә яшәгән халыкның тел үзенчәлекләрен дә чагылдыра. Шунысын да ассызыкларга кирәк: көндәлек, сакланып калган тарихи чыганаклар арасында, керәшен татарлары зыялыларының бер вәкиле тарафыннан татар сөйләмә телендә Н.И. Ильминский тәкъдим иткән кирилл алфавиты белән язылган иң борынгы эпистоляр жанр үрнәге булып тора.

## Казан губернасы һәм өязе Түбән Әзәк авылының Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе укытучысы Тимофей Иванович Тимәй көндәлегеннән (1873 ел)

(Текстның орфографиясе хәзерге заман татар теленә якынайтылды)

1873 го года, 3-го дня июня, кич 6 сәгатьтә.

Түбән Әзәккә килеп, школга кердем; керсәм, школ өенең хуҗасы Емельян бабай каралтылар сүттереп сипләттерә икән, эшчеләре күп икән, өе бик тыгыз икән; шунлыктан мине өендә кундырасы килмәде. Емельян бабай кертмәгәч, бүтән квартир эзләдем, бер өйгә кердем, аның хатыны гына өйдә булды; ул хатын иреннән башка кертәсе булса да, мин кермәдем. Шуның өчен, мин үзем бер генә кич кунарга дип сорыем, әмма үземнең уемда бер атналап торасы кук. Ул йорттан чыккач, урамда җыелышып тора торган кешеләр катына (янына) барып әйттем, мине кертеп кундырсагыз ла дип. Ул кешеләр миңа әйттеләр, әнә теге йортның хуҗасы кертер сине, дип. Палеть агай йортын күрсәтеп әйттеләр. Палеть Емельянов йортын бер кеше дә күрсәтмәгән көе, үзем үк танып, урамнан узган уңайда ямщигыма күрсәткән идем. Тик, туры Палеть агайга килеп керсәм, бу нинди кеше икән, килде дә туры Палеть агайга керде, бу кешене Палеть үзе чакырган микән? Ник килде икән бу кеше? Нинди кеше икән, ни эш белән йөри торган кеше икән? дип халык болганмасын минем аркылы, Палеть агайга да кыенлык килмәсен дип, керми узып киткән идем. Палеть агай өен күрсәтүчеләргә каршы мин әйттем, соң ул күрсәтә торган өегезнең хуҗасы ничек: ару (яхшы) кешеме, җәмәгатьләре күпме? дип. Алар әйттеләр: ул сезнең ише кешеләр белән бик таныша торган кеше, керәшен көе тора, үзе язу да таный, йорты да ике, җәмәгатьләре дә күп түгел, икмәге тозы да иркен, самавары да бар, аңар бардың исә, ул кертми калмас сине, диделәр. Мин әйттем: ул ни исемле кеше соң? дидем.

Алар әйттеләр: Палеть атлы кеше, училище хуҗасының улы ул, диделәр. Тагы әйттеләр: син Казаннан килгәнсең ахры, без таныйбыз сине, диделәр. Мин җавап бирдем: дөрес Казан аркылы киләмен, тик үзем Казан артында торам бу елларда, дидем. Тагы әйттем: ике атнадан бирле юлда йөримен, бөтен тәннәрем какшады, җилдән колакларым шаулады, күзләремә тузан кереп капланды, бер ауык кына (бераз гына) ял итеп, төзәнергә бер квартир кирәк булды миңа, дидем. Алар, яхшы алайса, ару юл булсын, диделәр. Шуннан соң мин Палеть агай йортына барып баскычына менгәч, Палеть агай чыгып күреште дә, кулдан тотып өенә алып керде, әйберләремне дә кертте. Казандагылар ни хәлдә торалар, Николай Ивановичлар (сүз шәркыятьче, педагог-миссионер Н.И. Ильминский (1822–1891) турында бара) саумы? Василий пуп (керәшен татарларыннан беренче христиан рухание В.Т. Тимофеев) саумы, дип сораштырды. Аннары авыл, күршеләр тормышыннан да, үз тормышыннан да бер ауык сүзләр сөйләште. Тагы әйтте, Николай Иванович миңа хат белән бер кенәгә җибәргән, диде. Тик ул хатны укый алалмыем, таный алмыем, диде. Күп грамотный кешеләргә күрсәттем, берәү дә таный алмый, диде. Мин әйттем, миңа биреп карачы әле ул язуны, дидем. Палеть агай язуны миңа күрсәтте, мин укып бар сүзләрен дә аермачыклап әйтеп белдердем.

Ул көнне шуннан бүтән эш булмады.

Моны яздым, июньнең 3 нче көнендә д. Әзәктә мин Темей.

4-го дня июня. Понедельник.

Иртән торып Палеть агай Арча базарына китте, он сатарга.

9 сәгатьтә Емельян бабай килде, ул сәлам биреп керде дә байтак утырды. Емельян бабай болай сөйләште: бу ни хәл булыр икән безнең татарга чыгучыларга, решение кайчан чыгар икән аларга, диде. Мин җавап бирдем, аларга һичкайчан да решение булмас; минем сүземнең дөреслеген моннан бел, мондагылардан элекке прошение биргән булып, татарга чыгабыз, дип йөрүчеләр бар, аларга да һич берсенә решение чыкмый лабаса моңарчы, моннан соң да шулай булыр, дидем. Емельян бабай әйтте, алайса решение дә чыкмаса, алай да болай да булмаса, котырган эт күк булып, котырып йөрербез мени без, диде. Мин әйттем, сезнең дә, сезнең туганнарыгызның да, карендәшләрегезнең дә, авыл күршегезнең дә, якташларыгызның да, бар затларыгызның да котырып йөрүегезне теләми Ходай, әмма, яхшы кешеләр дә, патша да риза түгел шундый кешеләргә, дидем. Ул әйтте, алай була торган булса бер-бер төрле кысанлык күрсәтү кирәк ийе, диде. Мин әйттем, соң кысанлык күрсәтүдән ни файда булыр? Син уйлап карачы әле: тар-тар гына имән такталарны җыештырып бер төшкә егермене куйгач, алар өстенә су салсаң анда су тормас, тик аларны бер оста кеше юынгалап, ышкылаштыргалап 14 ен кысага куеп, 6 сын ике башка төп итеп куеп, аның тышыннан кыршау белән кыршаулап ныгытса, аны мичкә, дип атыйлар, аңар ни салсаң да акмый. Алай булса да 2-ме тактаның эчендәге нәстәсе акмаганлыгы, тактадан түгел, кыршаудан. Кыршаудан икәнен болай бел: кыршауларын салгызып алдың исә, такталар эчендә су тору түгел, такталар үзләре дә таралып бетәрләр. Такталар-

ны җыеп, кыршауларны кигезеп куйсаң, тагы ныгаеп торырлар: эченә әйбер салсаң да акмас. Менә, имән тактасыннан ясаган мичкәнең акмаганлыгы, гел кыршаудан. Кыршаулар такталарны оештырып тотып агызмый торулары – ясый торган остасыннан. Урмандагы агачлар арасында, имәннән биек агач юк. Алай булса, урмандагы агачларның иң биегеннән мичкә тактасы була. Гел шуның күк, халык арасында, иң олы күңеллесе Мөхәммәт динен тотучылар. Имәнгә караганда шомырт агачы никадәр кечкенә, аннан кыршау була. Гел шулай, кеше кысучы түрәләр кече күңелле. Тагы шомырт агачына караганда, мичкә ясаучы оста ни хәтле кечкенә, кешеләр өстенә хөкем кылучы патша да шулай кече күңелле. Менә инде уйлап карасаң, үзең дә белерсең. Олы нәстәләр берсе дә үзен-үзе тота алмый, иң кече нәстә, үзеннән олы нәстәләрне барысын да тотып тора. Һәрбер олысымак уйлы кәферләнүчән халыкларга башлык булып, патша теләсә ни кыларга куәте бар-барын. Анысы алай булса, монысы болай. Мичкә ясый торган оста да, такталарны кысып тора торган кыршау да, такталары да җирдән үсеп булалар. Но, бу нәстәләрне үстерүче җир бик олы: диңгезләрне булдырган Ходай ни хәтле олыдыр. Кисмәккә салып тотмаса да, Ходайның су тота торган урынналары бар. Шул кадәр иркен, эчендә тора торган суының исәбе дә юк. Үзе бер дә кимеми, читтән килеп ни хәтле су кушылса да, артканы да һич тә беленми. Тик, үзе шул суның исәбен дә белеп, бүтән төштәге сулар килеп әлеге иркен урындагы суга кушылсын иде, дип, һәрвакытта көтеп тора, дидем. Боларның мәгънәләрен барын да әйттем әйтүен, тик монда язмыем. Әгәр дә бер кеше беләсе килсә, миннән сорап белсен.

Бу сүзләрне сөйләшкән вакытта Гәүей (Гаврил) агай да бар иде. Гәүей агай озак утырмады, тяжель (авыр, җитди) эше бар күк булып, чыгып китте. Аннан соң мин самавыр куйдырдым, Емельян бабайны чәй белән сыйладым. Чәй эчкәндә дә Емельян бабай гел шуны сөйләште: монда халык эрәтләп әйткән сүзне күтенә дә кысмый, азрак кысмыйча эрәт булмас: бергә азрак кыссак, элекке ирексез тоткан күк булса да, соңыннан чын күңелдән татарлар иде әле динеңне дә, диде.

4 че сәгатьтә авылда сөйләшеп утырырга бер кеше дә юкка күрә, су буена төшеп киттем. Анда малайлар уйнап йөриләр иде, аларның бер-берсенә ничек дип дәшкәннәрен дә, сүз рәвешләрен дә белим дип. Алар, мин якын бара башлагач, читкәрәк китәләр. Алар курыкмасын дип мин читкәрәк китсәм, минем артымнан киләләр. Үзләре бер-берсенә болай дәштеләр. Кайсысы Шәрәфи дип, кайсы Николай дип, кайсы Сәйфулла дип, кайсы Алексей, кайсы Мөхтәр. Тагы 2 кыз бар иде, берсе Сәрбиҗамал, берсе Анный.

Я писал Темей.

5-го дня июня.

Кич 5 нче сәгатьтә Югарыгы Әзәк (хәзер Арча районына керә) иленә барыйм дип чыктым. Но, барасы юлымны Палеть агай күрсәтеп, өйрәтеп җибәрде җибәрүен, тик үзе болай диде: анда баруын барасың син, аларның намаз укыган вакытына-ниенә туры килеп-нитеп, бездә ни эшең бар синең, монда ник кердең дип, кыйнап чыгармаслар микән сине, диде. Мин

әйттем: мин бер дә эш тикшереп йөрмимен, аның да, бүтән бер кешенең дә эшен тикшермим, кыламышын сынамыем. Тик, ул ризонны кеше, гыйлем кеше; шуңар күрә барам мин аның катына, дидем. Палеть агай әйтте: алай булса да сак йөр, диде. Мин шуның катыннан китеп, урамдагы елгадан аркылы чыгып, тау менеп барган чакта, Гәүей агай дәшеп туктатты мине. Ул сорады: Николай Иванич (Ильминский) язу җибәрмәдеме миңа, дип. Тагы бер ауык сөйләшеп тордык, авыл кешесенең кыйлануы турысыннан. Ул тагы әйтте: мулла катына баруың куркыныч синең, диде. Мин әйттем: яктыда йөргән кеше чокырга батмый, ташка сөртенми, Алла яктысында йөрермен, явыз кешеләр караңгысы каплап бетерә алмаслар Алла яктысын, миңа да бер эш тә кылмаслар, мин аларга зыянымны тешермәгәч, дидем дә, Гәүей агай катыннан китә башладым. Гәүей агай әйтте: иртә минем катыма кил, дип. Мин, ярар, дидем дә киттем. Бер ауык киткәч, урамда бер кеше күрдем; ул кеше мине күргәч, караул өенә кереп утырды. Мин дә барып кердем. Ул кешедән белмәгән күк булып сорадым: мулла кайда тора, дип. Ул бик уйлап кына озаклап әйтте: мин белмием монда мулла барын, диде. Алай булса да аның янында бер ауык сөйләшкәләп тордым. Шул чорда безнең каттан бер тирес түгүче үтеп китте, аның чәче барын күреп әйттем: сезнең авылыгызда чәчле кешеләр дә бар икән, дидем. Ул кеше әйтте: безнең мондагы халык, алтынланган тимер күк, диде. Урыс килсә, йә пуп килсә, бер-бер эш тикшерүче килсә, түбәтәй кия дә, татар, дип кычкыра; мулла килсә, указың кая дип, без керәшен, дип кычкыра, диде. Шуннан соң мин ул күрсәткән юлдан киттем, мулла катына.

Мулла тора торган өйнең капкасы төбендә бер кеше очрады; ул әйтте: кая барасың? диде. Бу кеше чәчле Гыйззәт, мин әйттем: мулла катына сөйләшеп утырыйм дип киләдер идем эле, дидем. Шунда мине күреп, аннан да моннан да җыела-җыела кешеләр күп булдылар. Төрле сүзләр сөйләшеп утырдылар, минем нинди эш белән йөри торган кеше икәнемне дә белергә тырышкан күк сүзләр ишеттем (татарга чыгуларының сәбәбе турысында кызганган күк булып сөйләштем). Без капканың тыш ягында сөйләшкәндә, капканын эч ягында мулла хатыны гел тыңлап торды. Аны кешеләр таныттылар миңа: тагы, мулла өйдә юк дип әйтәдер, диделәр. Шул капка төбендә бер сәгать ярым утырдым, аннан соң бер кеше алып керде мине. Бу кеше Җәпи атлы, пуп кушкан аты Ефемьдыр ахры. Җәпи агай миңа ипи кисте, шунда әлеге Гыйззәт тә өйгә керде. Гыйззәтнең хатыны, тагы бер хатын керде; тагы бер ир, бер кыз кереп тордылар. Монда сүз башланды, Алла ике дигән сүздән. Кешеләр бер ауык сөйләшкәннән соң, мин дә кушылып сөйләшә башладым (Адәм белән Еваның оҗмахтан куып чыгарылуы турысында, изге Марся тотуы турысында, аннары изге кабер әйтелүе турысында, тагы кояш турысында). Шунда, әлеге мулла хатыны да кереп сөйләште, мулла кайтмый инде, чәебез суынып бетте, дип, әйдәгез безгә чәй эчәргә, дип. Мин әйттем: кыз-хатын янына кергәч ничек булыр, мулла кайткач яратмас, дидем. Аннары остабикә абыстай чыгып китте. Ярты сәгатьтән соң бер кеше

алып керде мине мулла өенә, әле дә кайтмаган иде мулла. Мулланың остабикәсе тиз үк өстәл җәеп, чәй эчертәсе булды миңа: но, мин утырмадым, мулла өйдә булмаганга күрә. 10 минут утырдым да чыгып, кайтып киттем.

Емельян бабайлар катына җиткәч, тагы кешеләр очрады; анда, гел кеше сүзен генә тыңлап тордым. Үзем аз сөйләштем. Аннары Палеть агайга кайтып яттым. Шул, 11 нче сәгатьнең яртысы иде.

6-го дня июня.

Иртәдән башлап кичке 6 сәгатькә чаклы чыга-чыга йөрдем урамда, юаныргга бер кеше тапмадым. Кайсылары тирес түгәләр, кайсылары урманга киткән, кайсылары тегермәндә. Палеть агайдан сорадым: сезнең авыл кешеләре кайчан бушарлар эштән, дип. Петраудан биш-алты көн элек, бар халык бар да буш булыр, ди. Бүтән кешеләр дә шулай диләр. Бу арада Курбашта (сүз Т. Тимей укытучы булып эшләгән Казан губернасы Цивил өязе Иске Корбаш авылы турында бара) торган булсам, болар бушаган вакытта монда килгән булсам; ике якка да, үземә дә ару булыр иде әллә.

7 нче сәгатьтә тагы чыктым, шул чакта урамда бер ауык кеше бар иде, алай булса да бала-чага гына иде. Һичбер төштә сөйләшеп утырырга иптәш таба алмагач, Гәүей агайга кердем. Анда бер карт Стифан атлы кеше керде, ул да татарга чыкмый калган икән. Гәүейнең кайнатасы Андрей бабай да бергәләшеп сөйләшеп утырдылар, әлеге бер җилкенү турысында. Миннән дә шуны сораштырып утырдылар, бу эшнең решениесе тиз чыгар микән, дип. Мин әйттем: аларга юньле решение чыкмас: чыкмас дигән сүземнең чынлыгын моннан белегез, болардан элгәре чыкканнарга да, һичбер төрле нәрсә юк лабаса, мулла да бирелми лабаса, дидем. Андрей бабай әйтте: безнең Югарыгы Әзәк илендә бар лабаса мулла, диде. Мин җавап бирдем: болай әгәр дә бу мулла монда торасы булса, болардан элекке чыкканнарга указный мулла куелыр иде моңарчы. Тагы моннан билгеле, аның торасы түгеле, кенәген (кичә) мин баргач та качып калганын әйтәсез, чын нәстә шулай куркып торырмы, качып калырмы? Чын нәстә булса, нигездә кузгалмый ята торган дәү таш күк, каты давыллар белән дә кымшанмый торган тау күк нык торыр иде ул, бер кешедән дә курыкмас иде, курку түгел, каушамас иде, дидем. Андрей бабайның тәресе, тәре урыныннан бер яктарак шүрлектә икән. Аннан чыгып, югары очка таба бардым. Анда, урам чатында кешеләр утыралар иде, алар катына мин дә утырдым. Анда үзем күп сөйләшмәдем шуның өчен, үзем күп сөйләшсәм, кеше хәлен бер дә белеп булмый. Анда кешеләрнең сөйләшкән сүзләре шушы: бер-берсен иҗекләү, бер-берсеннән көлү, әкият сөйләү, бигрәк тә Казандагы трактирларда ни күргәннәрен, анда кеше үтерү, аны яшерү турысында. Аннары тагы, юлда очрашкан кешене алдалап, аның әйберен алу турысында. Шунда күп утырып, шундый сүзләрне ишетеп туйдым да аларга каршы бер җавап әйттем: яхшы, күп сүзләр сөйләштегез инде, ишеткәнегезне дә, күргәнегезне дә, кылганыгызны да, кыласыгызны да, кыларга көчегез җитмәслекне уйлаганыгыз да беленде сөйләшкән сүзегездән. Бу ни җитте начар сүзләрне

ишетеп туйдым, инде ару сүзләр дә ишетәсем килә, дидем.

Шундагы кешеләрнең яшьләрдән картырагы, картлардан яшерәге, уртанчылар арасыннан берсе әйтте болай: әле бу бик зарарлы түгел, безнең арада моннан аруны таба алмассың, моннан начарының күплеге исәпсез булыр, диде. Тагы әйтте: без татар, урыслык турысына китәр ләбаса безнең сүзебез, әгәр дә яхшылап сөйләшсәк. Без инде теләсәк ни кыйланырга келибез, шуның өчен татарга чыктык. Яхшы сүзләр сөйләшергә ярый, ялганчы түгел кешегә генә, диде. Бу сүзләрне әйткән кешенең чәче озын түгел-түгелен, алай булса да бик такыр итеп кырыкмаган, түбәтәй кимәгән. Шул чакта Палеть агай әйтте болай: Кешеләр әйтәләр миңа ник татарга чыкмыйсын, син бер ялгызың гына чыкмый калып җиңәрсең мени? диләр Үзләре татарга чыккач элеккегедән дә усал торалар (авыр яшиләр). Әгәр дә, татарга чыккан кешеләр яхшы торсалар, бу татарга чыккач, кеше төзәлә икән ләбаса дип, мин дә чыгар идем татарга, диде. Моннан соң кайсылары көлделәр, кайсылары читкә таба киттеләр. Мин әйттем: сез болай итсәгез ару булыр иде, дидем. Сез шушылай җыелган, җыелуыгыз ни өчен булса, иң элек шул эшегезне эшләгез. Кыласы эшегез булса, кылыгыз. Итәсе киңәшегез булса, итегез.

Чыганак: ТР МА, ф.968, тасв. 1, эш 15, б.127–134об. (нөсхә).

***Баһаветдинова Халидә Зиннәт кызы;***
***Исхаков Радик Равил улы,*** *тарих фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының керәшен татарларын һәм нугайбәкләрне өйрәнү үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 553.98

*М.Н. Минһаҗев, Б.М. Минһаҗев, А.Г. Кыямова*

# ТАТАРСТАН ГЕОЛОГИК СТРУКТУРАЛАРЫНЫҢ НЕФТЬ БИРҮЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ ҖИР КАБЫГЫНЫҢ ЯҢА ГЕОДИНАМИКАСЫ АРАСЫНДАГЫ БӘЙЛӘНЕШ

Приведены результаты исследований по изучению неотектонических критериев нефтеносности Южно-Татарского свода. Установлено, что для геолого-тектонических условий Южно-Татарского свода масштаб нефтеносности прямо пропорционален интенсивности неотектонических движений, интенсивность и амплитуды положительных движений новейшего неотектонического этапа развития земной коры способствуют аккумуляции нефти в антиклинальных ловушках. Восходящий режим новейших движений вызывает направленный поток нефтефлюидов из областей генерации к антиклинальным структурам. При наличии надежных покрышек и других благоприятных факторов из поступающих углеводородов образуются залежи нефти и газа. При нисходящих движениях, наоборот, углеводороды выдавливаются из структуры. Образно говоря, восходящие и нисходящие новейшие деформации создают в отложениях осадочного чехла эффект компрессии-декомпрессии. Следовательно, при прочих равных благоприятных условиях следует отдавать предпочтение тем районам и структурам, которые испытывали и испытывают новейшие и современные поднятия.

**Ключевые слова:** Южно-Татарский свод, нефтеносность, нетектонические движения, аккумуляция нефти.

Татарстан җир тышчасы доманик токымнарының нефть бирүчәнлек потенциалы һәм чыгарылган нефтьнең тулаем куләме (3 млрд тоннадан артык) арасындагы каршылыкны геология күзлегеннән аңлату гаять әһәмиятле мәсьәлә, чөнки моны ачыклау республиканың алдагы нефть табу стратегиясен билгели [Муслимов, с. 24–29]. Әлеге каршылык, яңа тектоника (неотектоника) йогынтысы нәтиҗәсендә кристаллик нигезнең деструкция каналлары буенча нефть утырма тышчага күтәрелә, дигән фаразлау нигезендә, шактый яхшы аңлатыла. Шуны да искәртик, хәзер геология фәне нефть ятмаларының оешуында яңа тектониканың әйдәүче рольне үтәгәнен исбат итте инде.

Шул сәбәпле, тәкъдим ителүче хезмәттә төрле масштаблы (төгәллектәге) яңа тектоник тикшеренүләрнең нәтиҗәләре китерелә. Тикшеренүләр түбәндәге мәсъәләләрне ачыклауны максат итеп куя:

– яңа тектониканың халәте һәм төбәкләрнең нефть бирү потенциалы арасындагы бәйләнеш;

– яңа тектониканың җир кабыгының нафтид газсызлануына тәэсир итү мөмкинлеге.

Яңа тектониканың халәтен өйрәнү буенча тикшеренүләр региональ масштабта тулаем Республика буенча структур-геоморфология ысуллары нигезендә (денудацион тигезләнү өслекләренең һәм елга үзәннәренең бүселү, рельефның эрозион парчалану күрсәткечләрен ачыклау) һәм аэросурәтләрне геоиндикацион ысулда аныклау рәвешендә башкарылды.

Җир кабыгының нафтид газсызлану дәрәҗәсен җентекләп тикшеренүләр Көньяк-Татар Түбәсенең Куакбаш уры мәйданында

(Ромашкино нефть чыганагының 301–303 нчы ятмалары) кристаллик нигезне палеоструктур һәм палеогеодинамик ысуллар; кристаллик нигезне, терриген девон, башкорт, верей катламнарының яңа тектоник хәрәкәтләренең чагыштырмача амплитудаларын өйрәнү геология ысуллары һәм космосурәтләрне структур анnetwork ыклау нигезендә башкарылды.

### *Региональ тикшеренүләрнең нәтиҗәләре*

Әйткәнебезчә, Татарстанның яңатектоникхаләтеденудационтигезләнү өслекләренең бүселү һәм рельефның эрозион парчалану күрсәткечләрен ачыклау ысуллары белән өйрәнелде. Шул сәбәпле, неотектоник хәрәкәтләрнең абсолют амплитудалары түбәндәге тигезләнү өслекләре мисалында саналды [Дедков, с. 3–20]:

–соң(гы)лигоцен-миоцен(P3-N1), 300–350 м абсолют югарылыкта формалашкан;

– плиоцен (N2), 200–250 м югарылыкта;

–соң(гы)плиоцен-плейстоцен (N2-Q1), 120–180 м югарылыкта.

Бу максаттан шулай ук рельефның горизонталь парчалану дәрәҗәсе дә саналды, чөнки бу күрсәткеч – яңа тектоника функциясе. Анализ, рельефның горизонталь парчалану дәрәҗәсе һәм тигезләнү өслекләрен ачыклау нәтиҗәсендә ачыкланган уңай тектоник хәрәкәтләр арасындагы бәйләнешнең туры пропорциональ булуын күрсәтте. Димәк, яңа тектониканың уңай градиентлары күрсәткече кайда югары, шунда рельефның эрозион һәм флювиаль формаларының тыгызлыгы да зур (1 нче рәсем).




1 нче рәсем. Татарстан Республикасы рельефының эрозион парчалану картасы

Шушы тикшеренүләр нәтиҗәсендә Татарстан Республикасының яңа тектоника картасы төзелде. Картада Республиканың мәйданы яңа тектониканың халәте буенча түбәндәге 4 районга бүленә.

1. Үтә актив халәтле: Көньяк-Татар Түбәсе, Казан-Киров авлакогены.

2. Актив халәтле: Төньяк-Татар Түбәсе, Көньяк-Татар Түбәсенең көнбатыш итәге, Мәләкәс иңкүлегенең көнчыгыш сырты, Токмов Түбәсенең көнчыгыш итәге.

3. Түбән актив халәтле: Төньяк-Татар Түбәсенең көнбатыш итәге, Мәләкәс иңкүлеге үзәк зонасының көнчыгыш өлеше.

4. Актив булмаган халәтле: Мәләкәс иңкүлегенең үзәк һәм көнбатыш өлешләре, Төньяк-Татар Түбәсе белән Казан-Киров авлакогены тоташкан район (2 нче рәсем).

Татарстан геологик структураларның нефть бирүчәнлеген һәм яңа тектоник халәтен анализлау бу күрсәткечләр арасындагы бәйләнешнең туры булуын күрсәтте. Моны супергигант Ромашкино нефть ятмасының неотектоник халәте үтә актив булган һәм хәзерге структур рәвешен кристаллик нигезнең уңай неотектоник хәрәкәтләре нәтиҗәсендә алган (плиоцен чорыннан да иртәрәк түгел) Көньяк-Татар Түбәсенә туры килүе дәлилли [Геологические...].




2 нче рәсем. Татарстан Республикасының яңа тектоника картасы

Яңа тектониканың халәтенә тәңгәл буларак, бу караштан актив булган Көньяк-Татар Түбәсенең көнбатыш итәгендә Республикада нефть бирүчәнлеге буенча икенче урында торган Яңа-Елхово һәм башка күп кенә чыганаклар урнашканнар.

Төньяк-Татар Түбәсенең көньяк-көнчыгыш итәгендә (шулай ук, актив неотектоник халәтле) Бондюг, Беренче Май, Алабуга һ.б. нефть чыганаклары урнашканнар. Бу төбәктә нефть бирүчәнлекнең үзенчәлегенә, неотектоник сәбәптән тыш, девон терриген катламнары калынлыгының аз булуы да тәэсир итә. Әлеге катламнар биредә Төньяк-Татар Түбәсенең үзәк өлешенә таба югалалар (кысылып чыгалар).

Мәләкәс иңкүлегенең яңа тектоник халәттән актив булган көнчыгыш сыртына уртакул һәм вак Аксубай-Мокша, Кадыйр, Норлат, Максат нефть чыганаклары туры киләләр.

Шулай итеп, региональ тикшеренүләрнең төп нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– рельефның бүселү абсолют күрсәткечләре китерелгән һәм Республиканың төрле неотектоник халәтле районнарга бүленгән яңа тектоника картасы төзелде;

– Көньяк-Татар Түбәсендә неотектоник халәт һәм нефть бирүчәнлек күрсәткечләре арасында туры бәйләнеш булуы дәлилләнде.

### *Җентекле тикшеренүләрнең нәтиҗәләре*

Куакбаш урының палеоструктур һәм палеодинамик үсеш үзенчәлекләрен өйрәнү ур кристаллик нигезенең тиман, семилук, данково-лебедян, фамен, тула, серпухов, башкорт, верей һәм ассель чорларындагы халәтен өйрәнүдән торды. Мәкаләдә Куакбаш урының палеозой эрасына караган әлеге вакыт дәверендәге үсешен җентекләп язарга мөмкинлек, әлбәттә, юк. Шул сәбәпле, тикшеренүләрнең төп нәтиҗәләрен генә китерәбез.

Палеогеодинамик, неотектоник тикшеренүләр автор тарафыннан эшләнгән һәм җир кабыгының палео- һәм яңа тектоникасын кристаллик нигез яисә утырма тышчаның башка өслекләре буенча өйрәнергә мөмкинлек бирүче ысул кысаларында башкарылды [Мингазов].

Палеотектоник тикшеренүләр ярдәмендә Куакбаш урының генезисы билгеләнде. Нәтиҗәсе: Куакбаш уры – неотектоник хәрәкәтләр тәэсирендә кристаллик нигезнең һәм өстәге терриген катламнарның уңай бүселүе сәбәпле хасил булган седиментацион-тектоник структура ул [Геологические...].

Куакбаш уры кристаллик нигезенең яңа тектоника үзенчәлекләре түбәндәгедән гыйбарәт (3 нче рәсем):

неотектоник ысул белән Куакбаш урына көнбатыштан күрше булган субмеридиональ юнәлешле Алтунино-Шунак, төньяк-көнчыгыш юнәлешле Көньяк һәм Чиктәш ярылышлары ышанычлы билгеләнәләр. Шуны да искәртик, ярылышларның төгәл урыннарын, аларның буй кисемнәренең гипсометрик тирбәлешен төгәл тасвирлаудан тыш, тектоник ярылышларның тискәре күрсәткечле тәэссорат зоналары һәм аларның чикләре дә дөрес ачыклана. Ярылыш зоналары арасында яңа тектониканың төньяк-көнчыгыш юнәлешле уңай үсемтәле өлкәләре урнашкан, алар шул ук юнәлештәге урсыман зоналар хасил итәләр. Бу урсыман зоналарның Алтунино-Шунак ярылышы бе-

ләп чиктәш булган көньяк-көнбатыш очларында яңа тектониканың уңай бүселеш дәрәҗәсе шактый зур, төньяк-көнчыгышка таба бу күрсәткечләр акрынлап азая. Шул ук вакытта, Алтунино-Шунак ярылыш зонасының тискәре хәрәкәт күрсәткечләре уңай хәрәкәтле урсыман зоналар белән тоташкан җирләрдә үсәләр.




Шартлы билгеләр:

1 – яңа тектоник хәрәкәтләрнең дәрәҗә сызыклары;
2 – уңай бүселешле мәйданнар;
3 – тискәре бүселешле мәйданнар;
4 – кристаллик нигез ярылышлары

3нче рәсем. Куакбаш урының кристалик нигезе яңа тектоник хәрәкәтләренең чагыштырма зурлыклары картасы

Бу күренеш Алтунино-Шунак зонасындагы иңү халәтен урсыман зоналарда калку халәте аша тигезләү механизмы белән аңлатыла (изостазия ишарәте).

Алтунино-Шунак ярылышының яңа тектоник халәте төрле җирендә төрлечә: төньяк өлешендә аның иңү күрсәткечләре минус 6 метрга җитә, үзәктә – минус 8 метр, көньякта – минус 10 метрга кадәр. Бу күренеш Алтунино-Шунак ярылыш зонасының яңа тектоника халәте төньяктан көньякка таба активлашуын күрсәтә.

Алтунино-Шунак ярылышының тармагы булган төньяк-көнчыгыш юнәлешле Көньяк ярылышының да яңа тектоник халәте көньякта (көньяк-көнбатышта) активрак (минус 12 метрга җитә). Төньяк-көнчыгыш кырыенда бу күрсәткеч минус 6 метрдан артмый. Күрәбез ки, Алтунино-Шунак ярылышының көньяк очының яңа тектоника халәте башка өлешләреннән активрак.

Өйрәнелгән мәйданның иң көньягында төньяк-көнчыгыш юнәлешле тагын бер тискәре структура (Чиктәш ярылышы) урнашкан. Кристаллик нигезнең неотектоник халәте башка ярылышларга караганда йомшаграк, яңа тектониканың тискәре градиентлары монда минус 6 метрдан артмый, ә көньяк-көнбатыш өлешендә (Алтунино-Шунак ярылышы белән тоташкан урында) алар минус 1 метр чамасы гына.

Чиктәш һәм Көньяк ярылышларыннан төньяктарак кристаллик нигез өслегендә үзара параллель һәм шулай ук төньяк-көнчыгыш юнәлешле I–I, II–II, III–II, IV–IV ярылышлары урнашкан. Алар барысы да Алтунино-Шунак ярылышының тармаклары, буй кисемнәренең яңа тектоник тирбәлешләре минус 7 метрдан артмый.

Абсолют биеклек күрсәткечләренең көньяк-көнбатыштан төньяк-көнчыгышка таба артуы һәм алда тасвирланган ярылышларның үзара параллель булуы мондагы кристаллик нигезнең баскычлы сөзәклек рәвешендә булуын исбатлыйлар.

Төбәк кристаллик нигезенең яңа тектоник халәтен Алтунино-Шунак ярылышы билгели, чөнки җир кабыгы тектоник энергиясенең төп өлеше бу ярылыш аша бушана, башка ярылышлар бу процеста бары ярдәмчел генә булып торалар. Шуны да искәртик, ярылыш зоналары халәтенең тискәре күрсәткечләре урсыман зоналарның уңай күрсәткечләре зурлыгына туры пропорциональ.

Шулай ук, 301–303 нче ятмаларның нефтьбирүчәнлек билгеләре (кырылма анализы, скважиналарны сынау, КИИ-146, КИИ-95) серпухов-башкорт-верей катламнарының яңа тектоник халәте нисбәтендә өйрәнелде. Аныклама, нефть билгеләре булган скважиналарның барысының да әлеге катламнарның неотектоник халәте уңай булган зоналарына туры килүен күрсәтте.

Шулай итеп, үткәрелгән палеоструктур, палеогеодинамик һәм яңа тектоник тикшеренүләр түбәндәге нәтиҗәләрне бирделәр:

– Көньяк-Татар Түбәсе, Куакбаш уры, I нче һәм II нче дәрәҗәле тектоник корылмалар буларак, җир кабыгы үсешенең яңа тектоник чорында хасил булганнар (тектоник караштан яшь корылмалар);

– Ромашкино нефть чыганагы һәм 301–303 нче ятмалар яңа тектоника халәте үтә актив булган Көньяк-Татар Түбәсе һәм Куакбаш уры мәйданнарында урнашканнар;

– Ромашкино нефть чыганагы һәм 301–303 ятмаларның нефть бирүчәнлеген кристаллик нигезнең хәзерге чорда актив булган Алтунино-Шунак ярылышы билгели.

Алдарак, Көньяк-Татар Түбәсе – җир геологик тарихының яңа тектоник чорында ясалган яшь корылма, дигән идек. Моннан, Ромашкино нефть чыганагының хасил булу вакыты Көньяк-Татар Түбәсенең ясалыш вакытыннан да яшьрәк һәм нефть җыю тозагының тулылануы плиоцен-плейстоцен чорларына туры килгәнлеге аңлашыла. ТатНИПИнефть галимнәре И.Ф. Глумов һәм С.Г. Уваров фикеренчә, бу тулыланыш хәзерге геологик чорда да (голоцен) дәвам итә. Бу авторлар, 50 ел дәвамында нефть суырткан 2 меңнән артык скважиналар биргән мәгълүмат буенча Ромашкино чыганагының бер өлеше булган Габдрахман мәйданының паший (Д1) һәм тиман (Д0) катламнарының тирәннән күтәрелгән нефть хисабына тулылануын дәлилләүче уннан артык билге табалар [Глумов..., с. 245 – 251].

Аномаль скважиналар (нефть бирү күрсәткече буенча) нефть җыем инверсияләренә нигезләнеп билгеләнде, ягъни озак вакытлар күзәтелгән җыемның табигый төшүе «кинәт» кенә шулай ук озак дәвам итүче арту белән алышына. Әмма, монда ачыкланмаган бер сорау кала: аномаль нефть бирүчәнлек фараз ителгән феномен белән бәйләнгәнме, әллә ятмаларны үзләштерү чорындагы булган техноген сәбәпләрдән гыйбарәтме? Бу кыенлыклар скважиналарның 40 тан артык түбәндәге аномаль күрсәткечләрен билгеләп хәл ителде:

– скважиналарның гамәли чорларында озак вакыт күзәтелгән түбән күрсәткечле нефть җыемы «кинәт» шулай ук озак дәвам итүче югары күрсәткечле җыем белән алышына;

– максималь җыем вакытыннан соң алдагы 5–10 ел дәвамында нефть җыемы артучы скважиналар;

– хәзергәчә гамәлдә булган һәм су-нефть нисбәте Габдрахман мәйданындагы башкаларныкыннан 2–4 тапкыр түбән булган скважиналар;

– 100 т/сут. җыемлы «рекордсмен скважиналар»;

– тулаем җыемы 1 млн. тоннадан артык булган «миллионер скважиналар»;

– гамәли вакыты 40 елдан артык булган «карт скважиналар»;

– катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү максатыннан үткәрелгән геологик-техник чаралардан соң өстәмә җыемнары зур булган скважиналар;

– гамәлдәге скважиналарның түбән су-нефть күрсәткече һәм башкалар.

2001 ел ахырында (анализ шул вакытка кадәр үткәрелде) нефть скважиналарының гомуми саны 979 була, вакытлыча нефть суыру вазыйфасын үтәүче сукугыч скважиналар – 165, туктатылган скважиналар – 63.

Д1 катламнарына нисбәтән җыемнар инверсиясе булган 526 скважина ачыклана, шулардан 335 скважина 2001елда да гамәлдә була. Шулай ук 1985 елдан ук инверсияле булган 204 скважина табыла; ягъни, Габдрахман мәйданының нефть җыемы кимегән шартларда Д1 катламының 181 инверсияле скважинасы 2001 елда да гамәлдә булалар.

Аныклама Д1 катламының берничә тапкыр инверсиягә дучар булган 47 скважинасын ачыклый, шулардан 39 скважина 2001 елда

да гамәлдә була. Шулай ук, Д1 катламының кыскача туктальп торудан соң эшли башлаган 29 инверсияле скважинасы билгеләнә.

Инверсиядән соң 100 тоннадан да артык өстәмә нефть биргән Д1 катламнарын үзләштерүче 153 скважина һәм шундый ук, ләкин 200 тоннадан да артык өстәмә җыемлы 36 скважина ачыклана. Моннан тыш, Дii – Div катламнарының 14 инверсияле скважинасы билгеләнә, 2001 елда аларның 13е әле гамәлдә була.

ГабдрахманмәйданындагыД1 катламын үзләштерүче 191 скважинаның максималь дебит биргән елдан соң тагын 5 ел дәвамындагы шундый ук югары күрсәткечләре күзәтелә (дебит азаю чорында).

Хәзерге вакытта Габдрахман мәйданындагы девон катламнарының су-нефть нисбәте 1 тонна нефтькә 2 $м^3$ судан гыйбарәт. Бу чагыштырманың зурлыгы 1 $м^3$ аз булса, ул түбән санала, ягъни скважинадан нефть, суга караганда, күбрәк алынган (Qн > Qс). 2001 елдан бирле эшләүче су-нефть нисбәте түбән булган (1 $м^3$ азрак) 228 скважина ачыклана. Болардан 24 скважинада тулай нефть җыемы 0,5 млн тоннадан арта, ә 96 скважинаның һәрберсе 100 мең тоннадан артыграк нефть бирә. Шулай ук, 2001 елда су-нефть нисбәте тагын да түбән булган (0,5 $м^3$ азрак) гамәлдәге 47 скважинаның һәрберсеннән 100 мең тонна нефть алынганы ачыклана.

40 елдан да ким эшләмәгән (төзәту өчен кыска араларда туктатып торылган) 128 һәм 2001 елда да гамәлдә булган тагын 116 искергән скважина ачыклана; 2 миллионер скважина (гамәлдәге чорда 1 млн. тоннадан күбрәк нефть биргән) билгеләнә.

Нәтиҗә буларак Габрахман мәйданындагы уртача еллык җыемнар инверсиясе булган скважиналарның саны түбәндәге рәсемдә тасвирлана (4 нче рәсем).




4 нче рәсем. Габдрахман мәйданындагы уртача еллык җыемнар инверсиясе күзәтелгән скважиналарның саны

Рәсемнән күренгәнчә, һәр 10–11 ел саен алда аталган скважиналарның дебит күрсәткечләре максималь дәрәҗәгә җитә, димәк хәзерге вакытта аз өйрәнелгән механизм Габдрахман мәйданының терриген девон катламнарын нефть белән тулыландырып тора.

Шулай итеп, Көньяк-Татар Түбәсенең нефть бирүчәнлеге аның үтә актив булган яңа тектоника халәте белән билгеләнә. Яңа тектониканың калку халәтендә уңай корылмалар җир кабыгының тирән катламнарыннан пешкәк механизмы ярдәмендә өскә юнәлгән нафтид агымнары тудыралар. Иңү хәрәкәтләре вакытында, киресенчә, нефть корылмалардан кысрыклап чыгарыла. Димәк, Татарстанның көньяк-көнчыгышында тектониканың калку-иңү хәрәкәте утырма тышчада һәр 10–11 ел саен компрессия-декомпрессия халәтен тудыра һәм Ромашкино чыганагының терриген девон катламнарын нефть белән тулыландыра.

## Әдәбият


*Лукьянова Р.Г.* Геологические аспекты поисков залежей нефти в девонском терригенном резервуаре Татарстана.: дис. ... канд. геол.-минерал. наук. Бугульма: ТатНИПИнефть, 2000.

*Глумов И.Ф., Уваров С.Г., Слесарева В.В. и др.* Исследование возможности увеличения извлекаемых запасов нефти терригенного девона за счет современного подтока глубинной нефти на примере Абдрахмановской площади Ромашкинского нефтяного месторождения // Труды ТатНИПИнефть. Бугульма, 2006.

*Дедков А. П.* О денудационных срезах и древних поверхностях выравнивания в Среднем Поволжье. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1972.

*Мингазов М. Н.* Оценка перспектив нефтеносности осадочной толщи палеозоя на основе неотектонических исследований. М.: ВНИИОЭНГ, 2005. 160 с.

*Муслимов Р. Х.* Определяющая роль фундамента осадочных бассейнов в формировании, постоянной подпитке (возобновлении) месторождений углеводородов // Нефтяное хозяйство. 2007. № 3.



***Минһаҗев Миңтаһир Нургата улы,*** *геология-минералогия фәннәре кандидаты, Татар нефть фәнни-тикшеренү һәм проектлау институты, mingaz@tatnipi.ru);*

***Минһаҗев Булат Миңтаһир улы,*** *Казан федераль университетының Нефть-газ технологияләре институты инженеры;*

***Кыямова Ания Галиәкбәр кызы,*** *Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты*

УДК 929:82-94

*Ә.К. Бустанов*

# ТАТАР АРХЕОГРАФЫ АЛЬБЕРТ ФӘТХИНЕҢ ШӘХСИ АРХИВЫ

Альберт Саидович Фатхи (1937–1992) почти полвека проработал в Восточном секторе Отдела рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского Казанского университета. Практически все свое время посвящал изучению татарской литературы, главным образом рукописной. Им проводились археографические выезды в районы Татарской республики, а также инвентаризация рукописей, поступивших в библиотеку в результате работы университетской археографической экспедиции. Фактически Альберт Фатхи за годы своей службы в университетской библиотеке стал единственным специалистом, великолепно знавшим фонд арабографической рукописной книги как в его описанной, так и обширной не инвентаризированной части. В результате каждодневной работы с татарскими рукописями у Альберта Фатхи сложился солидный личный архив, состоящий из его записей по истории книжности и различным аспектам татарской культуры. Предлагаем вашему вниманию первичное описание личного фонда Альберта Фатхи в Отделе рукописей и редких книг НБ им. Н.И. Лобачевского Казанского университета.

**Ключевые слова:** Альберт Фатхи, Отдел рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского Казанского университета, инвентаризация рукописей.

XX гасырда Россия мөселманнары арасында Көнчыгыш кульъязма китапларының социаль функциясе бөтенләй үзгәрә. Кульъязмалар башта очсызлы басма китаплар тарафыннан кысрыклана, ә инде гарәп алфавиты кулланудан төшеп калгач, кульъязма хезмәтләр искелек калдыгына: кадимчелек, схоластика объектына әверелә. Мондый караш 1920–1930 елларда борынгы әдәбиятны күпләп юкка чыгаруга китерә. Шул еллар «Чаян» журналларының берсендә урнаштырылган карикатурадан аңлашылганча, халык күңеленә инкыйлабка кадәргеүле әдәбиятка алмашка яңа, социалистик мәгънә салынган совет әдәбияты киләчәгенә ышаныч сеңдерелә. Карикатурада сурәтләнгәнчә, хаҗи Шәрәфи кебек кадимчелек тарафдарларына «иске режим» китаплары «каберлегендә» үкереп еларга гына кала.

Әмма бу рәсем совет чорының Сталин эпохысына гына характерлы булса кирәк. Сталинның шәхес культы фаш ителеп, сөргенлек газапларыннан исән калган ислам интеллектуальләре туган якларына кайта башлагач, аеруча шәһәрләрдә борынгы ислам әдәбияты актуальләшә башлый. Ислам мәгърифәтчеләре өчен алар рухи ихтыяҗларны тәэмин итүче мәдәни капитал ролен үтиләр, дини белемнәрне саклау һәм аны үзләреннән соңгы буыннарга тапшыру чарасы булып саналалар. 1950 еллар ахырында Совет зыялыларының югары даирәләрендә ислам мирасы ак-

туальлегенең атеистик җәмгыятьтәге яңа формуласы эшләнә.

Көнчыгыш кулъязмалар милли дискурсның бер өлешен тәшкил итеп, аларның әһәмияте милли мирас кысаларында аңлатыла, икенче бер өлеше – Совет идеологиясе якын дип саналганы – прогрессив хезмәтләр буларак кабул ителә. Ислам әдәбиятына болай якын килү аның Советлар илендә массакүләм фикер алышуга мөмкинлек биргән юнәлешләренең читен билгели.

Альберт Сәет улы Фәтхи (1937–1992) Казан университетының Фәнни китапханәсендә Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге Көнчыгыш секторында эшли. А. Фәтхи күп вакытын татар әдәбиятын, аеруча аның кулъязма хәлендәгеләрен өйрәнүгә багышлый. Татарстан районнарында археографик сәяхәтләрдә була, шулай ук университет оештырган археографик экспедицияләр вакытында табылган һәм китапханәгә килеп элеккән кулъязмаларга инвентаризация үткәрә. Альберт Фәтхи университет китапханәсендә эшләгән дәверендә гарәп графикасындагы кулъязма китаплар фондын – теркәлгән өлешен дә, инвентаризацияләнмәгән бик күп кулъязмаларны да – иң югары дәрәҗәдә өйрәнгән бердәнбер белгеч була. Археограф татар кулъязмалары өстендә эшләгәндә китапчылык тарихы һәм татар мәдәниятенең төрле аспектлары буенча үз фикерләрен теркәп бара һәм шулардан шактый бай шәхси архивын туплый. Вафатыннан соң аның барлык хезмәтләре дә китапханәнең Кулъязмалар бүлегенә саклауга тапшырыла. Кызганычка каршы, Альберт Фәтхи архивын эшкәртү сузыла, аның кайбер материаллары шәхси кулларга эләгә.

2013 елның көзеннән башлап, мин үзем Альберт Фәтхинең сакланган хәтле архивын инвентаризацияләдем. Архив материаларының эчтәлеге күп төрле: анда Көнчыгыш секторның 1937 елгы беренче инвентарь кенәгәсе (сак. бер. 142), Көнчыгыш секторның 1937–1959 еллардагы архивы (сак. бер. 120), еллык исәп-хисаплар, галимнәр белән язышкан хатлары, күренекле шәхесләрнең нәшер ителми калган мәкаләләре, кулъязмаларга аннотацияләр һәм татар китапчылыгының төрле юнәлешләре буенча тупланган мәгълүматлар һ.б. бар. Алар барысы да Альберт Фәтхинең шәхси тәҗрибәсе аша үткән һәм татар әдәбиятына, тарихына карата аның карашын чагылдыра. Архивтагы күпсанлы өземтәләр (выписка) мөстәкыйль рәвештә генә табарга бик авыр булган мәгълүматларга юл ача. N номеры белән теркәлгән гарәп графикалы кулъязмалар арасында Габдеррәхим Утыз Имәни шигырьләре бармы-юкмы икәнен белү өчен, җыелмадагы барлык кулъязмаларны да җентекләп карап чыгарга (Альберт Фәтхи шулай эшләгән) яки аның очраклы табылуына өметләнергә генә кала, чөнки китапханәдә әлегә кадәр тәфсилләп эшләнгән каталогның булганы юк.

Альберт Фәтхи тарафыннан киңәйтелеп төзелгән картотекага аерым тукталу урынлы булыр. Ул татар халкының тарихы һәм мәдәниятенә кагылышлы бик күп мәсьәләләрне эченә ала, ә картотеканың иң мөһим өлеше Көнчыгыш сектор кулъязмаларына багышланган. Альберт Фәтхи de visu фонды кулъязмаларының һәркайсын карап, аның нәтиҗәсен, ягъни кайсы кулъязманың фән өчен әһәмиятле икәнлеген карточкага теркәп куйган. Нәкъ менә шул

карточкалар ярдәмендә бөтен фонд буенча таратылган кульязмаларның шәхси коллекцияләрен реконструкцияли, иң борынгы һәм иң популяр кульязмаларның катламын ачыклый алабыз; кульязмаларның колофоннары буенча аның карточкага язылган чыгыш мәгълүматларын системага салуда, шулай ук иллюстрацияле һәм бизәлгән кульязмалар турында күзаллау булдыруда да бу карточкаларның файдасы зур.

А. Фәтхи үзенең язмаларында татар мәдрәсәләре тормышы, мәхәббәт лирикасы һәм татар эпистоляр жанры (моңа караган материаллар зур күләмле монографияләрне хәтерләтә) турындагы мәгълүматларны системага салырга тырышкан.

Археографны кульязмалар белән мәдәни бәйләнештәге башка регионнар да кызыксындыра. Язмаларыннан һәм карточкаларыннан аңлашылганча, А.Фәтхи гарәп графикасында кулдан язуның Төркия, Дагыстан, Якын Көнчыгыш һәм Урта Азия традицияләре арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә дә игътибар итә.

Кайбер сәбәпләр аркасында А. Фәтхинең күп кенә хезмәтләре матбугатта басылып чыкмый. Фәкать татар язучылары кульязмаларының тасвирламалары сериясе генә 1980 елларда дөнья күрә, һәм ул Казан университеты китапханәсендәге гарәп графикалы кульязмалар буенча озак елларга бу юнәлештәге бердәнбер басма булып кала. Альберт Фәтхинең хезмәтләрен бастырып чыгару, миңа калса, кирәкле эш, аларда, автор тарафыннан тәкъдим ителгән концепцияләр һәм фикерләр белән бергә, әлегә кадәр фәнни әйләнешкә кертелмәгән гаҗәеп бай фактик материал да бар. Ул мәгълүматлар Төньяк Евразия мөселманнарының соңгы берничә гасырлар дәвамындагы рухи тормышы үсеше турында безнең күзаллавыбызны күпкә баетыр иде. 1950 еллар ахырында киң таралыш алган татар мирасчылыгы күп төрле мәдәни чараларны эченә ала: татар поэзиясе антологиясен һәм татар әдәбияты тарихын бастырып чыгару, татар тарихы буенча уку курслары булдыру, шулай ук 1963 елдан башлап археографик экспедицияләр оештыру. Нәкъ менә экспедицияләр, аерым галимнәр тарафыннан оештырылсынмы ул, яки фәнни учреждениеләр тарафыннанмы, татар мәдәнияте хакындагы белемнәрне эре архив сакланмаларында туплау бурычын үз өсләренә алалар.

Альберт Фәтхинең ниятләре зурдан була, әмма аларның һәм ул башкарган эшләрнең бик азы гына безгә мәгълүм. Без хәзер аның мирасына мохтаҗбыз. Бу хакта ул үзе болай яза:

«Эшнең бөтен этабында иман йөртә мине: мин гадәти булмаган бер эш эшлим; ул минем үзем өчен түгел, минем халкым өчен кирәк. Чөнки аның мирасы тормышта бик аяныч язмыш кичергән, ул фән-гыйлем дөньясында да дөрес бәяләнә, гәүдәләнә алмаган. Ничек кенә булса да, табылырга мөмкин нәрсәне кулга төшерергә кирәк! Хәзер бу эшне эшләүнең көне – бүген, быел гына, иртәгә – соң булачак. Мөмкин булмаячак. «Интернационал»да әйтелгәнчә, бу безнең иң соңгы көрәш. Бу эш, бер татар өчен генә түгел, прогрессив кешелек культурасы өчен кирәк.»

Альберт Фәтхи эш буенча да, үзе турында да көндәлек язмаган. Аның бөтен идея һәм эшләнмәләре А4 форматлы күп санлы кәгазь битләрендә калган. Андый язма-

лары, гадәттә, аның үз-үзе белән әңгәмәсенә кайтып кала. Ул үзенә латин хәрефләрендә Albert дип мөрәҗәгать итә һәм татар китапчылыгын өйрәнү буенча үзенә нәрсә дә булса эшләргә тәкъдим итә.

А. Фәтхинең экспедицион тикшеренүләре аерым тарихи-мәдәни районга, төгәлрәге, үзенең туган ягы – элеккеге Уфа губернасының Минзәлә өязе территориясенә карый. Археограф үзенең язмаларында татар китапчылыгы тарихы өчен ул якларның гаять нигезле булуын кат-кат ассызыклый, материалларыннан чыгып фикер йөрткәндә, ул, тикшеренүче буларак, татар мәдәниятенең фундаменталь характеристикалары турында белергә өметләнгән. А. Фәтхи язганча, 1930 еллар репрессиясе татар халкының югары культурасына зур зыян сала. Ул татар культурасын репрессияләр тарафыннан очы кисеп төшерелгән, әмма фундаменталь кыйммәтләре сакланып калган пирамида белән чагыштыра, һәм үзе дистә елга якын (1969–1978 елларда) шуларны эзләп юлга чыга. Бу эзләнүләрнең нәтиҗәсе булып, Минзәлә өязеннән генә дә 2 меңгә якын кульязманы эченә алган коллекция барлыкка килә. Чыннан да, эчтәлеге белән дә бу районга тиңнәр юк.

Альберт Фәтхи, археограф кульязмалар язмышын үз язмышыдай, шәхси фаҗигаседәй кабул итәргә тиеш, дип фикер йөртә. Беренче экспедицияләрдәге кичерешләре турында ул, соңрак, болай яза:

«Ходил с болью. На каждом шагу известие о гибели... по разным причинам... Что погибло? Погибли все материалы Тлянчи-Тамак медресе – очага культуры, библиотека медресе. Олы Чакмак, ведущего мударриса, личн. библиотека. А ведь эти личности были просветителями на местах. Тукай – классик центра, но культура – вся татарская книжная среда держалась, была живой благодаря вот таким местным труженикам.

В крупных селах – админ. центрах совет. времени – ничего нет. Рассеянные через шакирдов рукописи находятся в радиусе 30–60 км. Было очень много, но погибло целиком в 1930е годы. Маленькие села – у них более благоприятный микроклимат в отношении культурного наследия. В маленьких селах была своя “книжная атмосфера”».

Совет чорында аграр сәясәт археографлар ягында булмый: совхозларны эреләндерү максатыннан зур тарихлы, нык нигезле күп кенә авыллар, күчерелеп, юкка чыга. А. Фәтхи бу хакта авыллардагы социаль, сәяси һәм мәдәни процессларның ролен тасвирлап яза. Җирле тарихны, генеологияне өйрәнү турындагы кульязмалар, кыйммәтле әдәби хезмәтләр, истәлекле язмалар миграциягә дучар ителә. Зирәк фикерле, тирән хәтерле затлар күпләп Себергә, Урал буйларына, Казакъстанга, Урта Азиягә күчеп китәләр.

Шулай да нәрсәләрдер сакланып кала, кайсыларыдыр – юк. А. Фәтхи билгеләп үткәнчә, рухи мирасыбызның түбәндәге төрләре бик күп сынауларны узып, исән кала:

– җәдитлек чорыннан (1905–1917, өлешчә 1890–1909 еллардан) иң гади кешеләрнең шәхси дәфтәрләре (мәсәлән, Г. Тукайның);

– борынгы классик культурага – кадими эпохага караган зур калын китаплар;

– төрки телдәге китаплар;

– җирле чичәннәр иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» һәм XVIII–XX гасырлардагы татар авторларының кайбер кулъязмалары (Сөбател гаҗизин, Мөхәммәдия);

– XVIII – XIX гасырга караган гарәп һәм фарсы телендәге хезмәтләр. Ягъни сан ягыннан югары күләмле, күп таралган материаллар сакланган.

– җәмгыятьтәге үзгәрешләрне үтеп чыга алмаганнар:

– совет чорында, революция елларында, коммунистларның беренче буыны тарафыннан язылган, җәдитчелек дәвере, ягъни шул чор башында ук иҗат ителгән кулъязмалар;

– күренекле кешеләрнең – галимнәр, мөдәррисләрнең шәхси дәфтәрләре;

– авыллар тарихлары;

– шәҗәрәләр;

– җирле авторларның сирәк очрый торган әдәби әсәрләре;

– кадимчелек чоры һәм борынгы классик культура хәзинәләре, зур кыйммәткә ия булган күчермәләр, әдәби кулъязмалар.

Болар хакында А.Фәтхи болай яза: «В эпоху массовой гибели… Что пошло в подземелье, под почву… в макулатуру, на крышу. Как прощупать все это? Как найти какие-то контуры, хотя бы слабо заметные. Нет такого прибора. По оставшимся рукописям наметить ориентир. Таким произведением, как показал итог первого обхода, оказалось «Кыссаи Юсуф» – самое распространенное сочинение в татарской книжной культуре, его скрупулезное изучение – это изучение всей татарской книжной культуры, степени его распространенности, живучести. В результате получается топографическо-статистическая картина культуры определенного микрорайона – пусть по менее достоверным показателям, причем с конкретными хронологическими срезами, потому что все рукописи практически датированы или датируемы в пределах десятилетия, четверти века. И если рукописи местных авторов вроде Хәнәфия Тышлыяри являются уникальными явлениями культуры, дошедшими до наших дней, то “Кыссаи Йосыф” принадлежит к массовому, фундаментальному в татарской культуре».

Шунысы игътибарга лаек, А.Фәтхи татар археографиясе тарихындагы күчемлелек тәртибен төзи. Ул аны, кул астында булган кулъязма материалларга таянып, Шиһабетдин Мәрҗани белән Риза Фәхретдиннән башлый, аннан 1920 еллар каһарманы Сәет Вахиди; катлаулы 1930 елларда да шул ук Вахиди һәм Габделхәй Хәбибуллин, Вәли Зәбиров, Сабир Алимов, Нәкый Исәнбәт; 1940–1955 еллар рухи хәзинәләребезне бөртекләп туплаучылар Нәкый Исәнбәт һәм Зәйнәп Максудова дәвере булып кала; 1956–1962 елларда Җәвад Алмаз, Хатыйп Госман, Нил Юзиев; ә 1963 елдан татар археографик кыйммәтләрне туплауны Альберт Фәтхи, Миркасыйм Госманов, Марсель Әхмәтҗанов һ.б. дәвам итәләр. Үз хезмәтенең үзенчәлекләре турында язганда ул эзләнүләре вакытында социаль катлауларның барысын да колачлавын, халык рухына демократларча якын килүен ассызыклый.

А. Фәтхи кулъязмалар тирәлеге атмосферасына, аны саклаучы шәхесләрнең кем булуларына игътибар итә, ләкин, кызганычка каршы, язмаларына алар хакында теркәми. Ул, проблема аларның динилек дәрәҗәләрендә: алар атеистлар да түгел, фана-

тиклар да түгел, дип яза. Башка чыганаклардан аңлашылганча, 1970–1980 елларда авылда кешеләрнең дини рухы көчле булган һәм җирле руханиларның варислары, мәгърифәтле кешеләр яшәгән. Аларның кайберләрендә йөзләгән кулъязма китаплар сакланган. Шулай да А. Фәтхи бервакыт, бик тырышса да Хәнәфия Ташлыяри тарафыннан төзелгән гарәпчә-татарча сүзлекне үзендә булдыра алмый, чөнки авыл картлары гарәпчә китапларны тәрҗемә иткәндә шуннан файдалана торган булганнар.

Шул ук вакытта А.Фәтхи зур кызыксыну уяткан китап-кулъязмаларны зәвыкъ белән сайлап туплаучы библиофилны ул елларда бер авылда да очратмавы турында яза. Әмма, кайбер чыганаклардан аңлашылганча, реабилитацияләр башлангач, кулъязмаларның элеккеге хуҗалары кемдәдер сакланган китапларны күчереп алып, алар нигезендә яшерен рәвештә, ислам белемен торгыза башлыйлар.

Экспедицияләр вакытындагы очрашуларда кулъязма яки басма китап хуҗалары А. Фәтхине төрлечә каршылыйлар: кайберләре, дини китапларны юкка чыгарырга тели, дип, аңа үзләрендәге рухи хәзинәне күрсәтмиләр; икенчеләре аларны сатып бирергә генә риза була; ә рухи мирасының әһәмиятен аңламаган урта яшьтәгеләр археографны макулатура җыючы сәер кешегә саныйлар.

А. Фәтхи Татарстанда норратив чыганакларны өйрәнүче белгечләр аз булуга борчыла. Китап культурасы тарихчысы, мәсәлән, Татарстан шартларында мәдәниятне торгызучы, бөртекләп тупланган аерым табышлар буенча аның тарихи барышын һәм бәйләнешләрен өйрәнүче археологны хәтерләтә. Әмма, беренче чиратта, Идел буе татарлары иҗатларын, аларның барлык күчермәләрен барлап, һәркайсын монографик планда өйрәнү зарур.

Чыннан да, А. Фәтхи архивында татар әдәбиятының юлъязмалар, этика, авылларның җирле тарихы өлкәсенә караган күренекле әсәрләренең кайберләре турында тәнкыйди һәм аналитик бәяләмәләр саклана. Әмма аларның күбесе төгәлләнмәгән һәм берсе дә басылып чыкмаган. Безнең бурыч – эшне ахырына җиткерү һәм аларны бүгенге заман укучысы хөкеменә тәкъдим итү.

Безнең көннәрдә татар археографиясе алдында торган һәм Альберт Фәтхинең төгәлләнеп бетмәгән планнары турында сүз йөрткәндә, Көнчыгыш секторның А.Фәтхитарафыннантөзелгәнозак сроклы перспектив эш планын карап үтү урынлы булыр (ул, автор үзе язганча, рус телендә бирелә):

Рукописи татарских писателей и ученых. Поступления в НБ КГУ (1960–1990).

Татарская рукописная книга XVI – 1-й четверти XX вв. Некоторые проблемы эволюции и бытования (культурно-историческое, книговедческое и литературно-источниковедческое осмысление итогов археографической деятельности Казанского ун-та в 1956–1990 гг.

Археографический центр Татарстана – история сектора восточных рукописей НБ КГУ 1920–2000 гг. образование и развитие фонда, деятельность.

Рукописи «Кысса-и Юсуф» и их значение для татарского книговедения, для изучения жизни татарской книги, опыт полевой и камеральной кодикологии.

Жизнь книги в окраинной провинции в XVIII – 1-й четверти

XX вв. Осмысление результатов полевых исследований Фатхиева в Северо-восточном Закамье (Мензелинский уезд) по материалам археографической экспедиции 1969–1978 гг.

Татарская рукописная книга XVI – 1-й четверти XX вв. Аннотированный иллюстрированный каталог достопримечательных культурно-исторических памятников из поступлений в восточный сектор за 30 лет (1960–1990).

Фикерләремне йомгаклап шуны ассызыклыйсым килә, Альберт Фәтхинең фәнни эшчәнлегенең төп нәтиҗәсе шуннан гыйбарәт: аның архивындагы материаллар университет тупланмасының Көнчыгыш кульязмаларга бай булуын чагылдыра һәм университет китапханәсенең Көнчыгыш секторына мөрәҗәгать иткән һәр тикшеренүче өчен үзенчәлекле юлкүрсәткеч вазифасын үти ала.

Альберт Фәтхи архивы исемлеге

| № | Тасвиры | Датасы | Күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | «Ун мең китап» арасыннан утыз китап. Кульязмаларның колофоннары, шифр белән | Датасыз | 7 кгз |
| 2. | Гали Чокрый архивыннан күчермәләр, шифр белән | Датасыз | 24 кгз |
| 3. | Күчермәләр: Татар галимнәргә багышланган мәдхия һәм мәрсия (Нәҗметдин б. Мөхәммәт остаз, шәех Вәли Мөхәммәд б. Мөхәммәд Әмин әл-Каргали, Габделхалик б. Ибраһим Курсави, Хасан б. Хәмит әл-Мөслими, Эстәрлебаш ишаны, дамелла Исмагыйл әл-Кышкари, Хәйрулла мәхдүм Әлмәти, Мөхәммәдзәкир б. Габделваһһап әл-Чистави һ.б.) | Датасыз | 70 кгз |
| 4. | Күчермәләр: Утыз-Имәни һәм Каюм Насыйри. Шигырьләр | Датасыз | 12 кгз |
| 5. | Күчермәләр: Сәгыйт Вахиди коллекциясеннән китап фрагментлары (1142-51 т, 1127 т, 1111-1112 т) | Датасыз | 6 кгз |
| 6. | Татар библиофилиясы. Китаплар исемлекләре | Датасыз | 14 кгз |
| 7. | Күчермә: Сәфәр әл-Җайыки (тәрҗемәче). «Тәзкирәи әүлия» | Датасыз | 2 кгз |
| 8. | Күчермәләр: хатлар, 1907–1923.<br>Шәкерт хәле, Түнтәр авылы хакында мәгълүмат бар, Диния Нәзарәте документлары.<br>Персоналия: М.-К. Мөзаффаров, Х.-Г. Габаши, Мөхәммәд Нәҗип Түнтәри, Мөяссәр әл-Карамали Дусаев, Гали ишан Түнтәри һ.б. | Датасыз | 87 кгз |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 9. | Мәрҗани коллекциясеннән китаплар, шифр белән | 1959? | 1 кгз |
| 10. | Бәдәвам китабы турында | 1977 | 14 кгз + 16 бит оригинал |
| 11. | 1970–1971 нче елларда табылган кульязмалар эчтәлеге. Шифрлар юк | Датасыз | 44 кгз |
| 12. | Актаныш АЭ – 1969. Кулъязмалар эчтәлеге. Шифрлар юк. | Датасыз | 12 кгз |
| 13. | АЭ – 1973/74. Кулъязмалар эчтәлеге. Шифрлар юк. | Датасыз | 8 кгз |
| 14. | Гатаулла бине мелле Йәһүдә әл-Бикбауи милкендә булган китаплар. Шифр белән. | 1973 | 10 кгз |
| 15. | Күчермәләр: Шәҗәрә | 1975 | 70 кгз |
| 16. | Татарлар укыган поэзия әсәрләре. Шифр белән | Датасыз | 10 кгз |
| 17. | Мәҗмәгъләр. АЭ-1975. Азнакай, Минзәлә районы. Эчтәлек, күчермәләр. Шифры юк | Датасыз | 14 кгз |
| 18. | XVIII гасыр татар кулъязмалары | Датасыз | 64 кгз |
| 19. | Татарлар укыган проза әсәрләре. Исемлек, шифры белән | Датасыз | 12 кгз |
| 20. | Яңа Казан татар әдәби теле. Фәнни терминологиядә иске традицияләр. Күчермәләр, сүзлек | Датасыз | 18 кгз |
| 21. | Күчермәләр: Мәдрәсә тормышы. Шифры белән | Датасыз | 28 кгз |
| 22. | Күчермәләр: Рәсми хатлар. Шифры юк. Фәүзия Идиятуллина (Иске Әлем ав.) коллекциясеннән. 1878 | Датасыз | 25 кгз |
| 23. | Мөхәммәд-Хәнәфия бине дамулла Фәтхулла әл-Ташлыяри «Насыйхәтнамә». Күчермәләр, критический текст, анализ, биографик мәгълүмат. 1874 | 1970 еллар | 96+ 1 битлек имтихан шәһадәтнамәсе |
| 24. | Альберт Фәтхи. Замана һәм мирас | Датасыз, 1970 еллар? | 4 кгз |
| 25. | Татар китапчылыгы турында аерым фикерләр, теркәү кәгазьләр. XVII –XX гасыр. | Датасыз | |
| 26. | Университет коллекциясеннән кульязмалар. Шифр, әсәрләр исемлеге, эчтәлек, күчермәләр | Датасыз | 97 кгз |
| 27. | Альберт Фәтхи. Каюм Насыйри: татар китап әдәбияты һәм мәгърифәте тарихчысы (биографик очерк язу). Каюм Насыйри автографлары | Датасыз | 33 кгз |
| 28. | Татарда география, астрономия, математика фәннәре | Датасыз | 5 кгз |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 29. | Игътикад, фикъһе, татар җәмгыятендәге ислам гыйлемлекләре тарихы. Кулъязма номеры 2155т. 1917–1928. Эчтәлек | Датасыз | 5 кгз |
| 30. | Колофоннар. | 1970 еллар | 41 кгз |
| 31. | XIX гасыр татар китабы. Экспедиция материаллары | Датасыз | 92 кгз |
| 32. | Автобиографик-мемуар әсәрләр. Каталог | Датасыз | 1 кгз |
| 33. | Альберт Фатхи. История татароведения | 1982 | 15 кгз |
| 34. | Альберт Фатхи. Кыссаи Юсуф и судьба татарского народа | 1983 | 64 кгз |
| 35. | Китапның күчерү вакыты | Датасыз | 21 кгз |
| 36. | Нисбәләр | Датасыз | 19 кгз |
| 37. | Китап язмышы. Теркәү фикерләр | Датасыз | 91 кгз |
| 38. | Бохарадагы татар шәкертләре | Датасыз | 3 кгз |
| 39. | Татарлар һәм үзбәк әдәбияты | Датасыз | 71 кгз |
| 40. | «Тәгъриф-ел-вилдан». Эчтәлеге | Датасыз | 2 кгз |
| 41. | Иске татар әдәбияты христоматиясе. Күчермәләр | Датасыз | 113 кгз |
| 42. | Көнчыгыш халыклар (казакълар, азәрбайҗан, иран) белән әдәби бәйләнешләр | Датасыз | 27 кгз |
| 43. | Совет чорында мираска мөнәсәбәт | Датасыз | 4 кгз |
| 44. | 1969 елда Балтач авылында Камал Закиров коллекциясендә табылган җәмәгать дәфтәре. 1844–1867 еллар. Эчтәлек | Датасыз | 53 кгз |
| 45. | Күчермәләр: төрле документлар. 19 гасыр | Датасыз | 130 кгз |
| 46. | Коръән нөсхәләре, татарча тәфсир. 19 гасыр | Датасыз | 11 кгз |
| 47. | Халык әкияте. Күчермә. Кулъязма 723 т | Датасыз | 15 кгз |
| 48. | Мөхәммәдъяр. Төхфәи мәрдан. Текст. Кулъязма 1909 т | Датасыз | 56 кгз |
| 49. | Курсави һәм Мәрҗани әсәрләре. Кулъязмалар шифрлары | Датасыз | 6 кгз |
| 50. | Кыссаи Чингиз-хан. Күчерелгән текст | Датасыз | 46 кгз |
| 51. | Мөхәммәд-Нәҗип Түнтәри турында материал | Датасыз | 98 кгз |
| 52. | Кулъязма җыентыклар. Шифр һәм эчтәлеге белән | Датасыз | 23 кгз |
| 53. | Татар җәмгыятендәге ислам дине. Руханилар катлавы, аның көнкүреше, мәгърифәт – язу-китап-укымышлык һәм аның татар демократиясенә, фольклорына ясаган прогресив тәэсире. Татар укымышлыларының оригиналь әсәрләре | Датасыз | 43 кгз |
| 54. | XVII гасыр татар кулъязмалары | Датасыз | 7 кгз |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 55. | Татар китап әдәбиятында табышмаклар | Датасыз | 9 кгз |
| 56. | Татар сәяхәтнамәләр. Күчерелгән текстлар. Исмәгыйл Бикмөхәммәт углы, Гали Чокрый, Мәрҗани, Габделхәбир Габделҗәлил углы «Рисала ал-Булгарийа фи сабил ал-хаджж», | Датасыз | 290 кгз |
| 57. | Әбүбәкер Мөхәммәтхафиз улы Фәтхуллин (1887–1959). Ташлыяр авылы, Мөслим районы. Аның тарафыннан язылган ике дәфтәр. Кара: 6029 Т | Датасыз | 8 кгз |
| 58. | Габделхалик бине Ибраһим Курсави (1770-1843). Гарәпчәдән төркичәгә (татарчага) тәрҗемә, хәдисләр | Датасыз | 11 кгз |
| 59. | Татар китап әдәбиятында Россия патшаларының Идел буе татарларын җәберләү политикасына каршы протест мотивлары | Датасыз | 2 кгз |
| 60. | Татарлар һәм төрек әдәбияты | Датасыз | 59 кгз |
| 61. | Татар галимнәре турында мәгълүмат (каталог өчен) | Датасыз | 95 кгз |
| 62. | Татарның нәфис кульъязма сәнгате тарихы буенча материаллар. Татар китап сәнгатенең шедеврлары | Датасыз | 70 кгз |
| 63. | Борынгы татар әдәби телендәге текстлар җыентыгы. Төзүчесе Альберт Фәтхи. Казан, 1965. Кульъязма | 1965 | 42 кгз |
| 64. | Китаплар илендә илле ел (1750–1800). Альберт Фәтхи белән телетапшыру | Датасыз | 15 кгз |
| 65. | А.С. Фатхиев. Рукописи татарских писателей и ученых второй половины XIX – начала XX века в в фондах Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского и некоторые вопросы их научно-библиографического описания. Кульъязма | Датасыз | 116 кгз |
| 66. | А.С. Фатхиев. Татарская кириллическая книга и ее историческое значение. Кульъязма | Датасыз | 63 кгз |
| 67. | А.С. Фатхиев. Некоторые вопросы изучения татарского литературного наследия. Кульъязма | Датасыз | 26 кгз |
| 68. | Марсель Ахметзянов. Результат кропотливых трудов [«Татар эдипләре»нең 4нче томына рецензия]. Кульъязма | 1970 нче еллар | 12 кгз |
| 69. | Альберт Фәтхи. «Голос библиотекаря» өчен язылган мәкаләләр. Русча. Кульъязма | 1960–1963 | 29 кгз |
| 70. | Сәхипгәрәй ярлыгы. 1523. Тексты | Датасыз | 8 кгз |
| 71. | Альберт Фәтхи. «Татар әдипләре» хроникасы. Черновиклар, документлар | 1976 | 220 кгз |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 72. | Альберт Фатхи. Некоторые особенности письменно-книжной культуры населения бывшего Мензелинского уезда Уфимской области. Кулъязма. | 1970 нче еллар | 119 кгз |
| 73. | Альберт Фатхи. К вопросу диахронического изучения книжного репертуара поволжских татар XVI-XIX вв. (истоки казанской печатной книги XIX в.). Кулъязма. | Датасыз | 70 кгз |
| 74. | Татар төбәк тарихы. Атамалар | 1982 | 38 кгз |
| 75. | Сирәк татар басма китабы хронологиясе. 1785–1930 | 1965 | 65 кгз |
| 76. | Кырым татарлары белән Идел буе татарларының багланышлары | Датасыз | 84 кгз |
| 77. | Керәшен татарлары. Материаллар. | Датасыз | 367 кгз |
| 78. | Альберт Фәтхи тарафыннан басылган мәкаләләр җыентыгы. | 1958–1973 | 37 кгз |
| 79. | Альберт Фәтхи. «Коллективная биография круга татарских просветителей: Ш. Мәрҗани» | 1988 | 376 кгз |
| 80. | Татар крестьяны һәм китап | 1970 нче еллар | 27 кгз |
| 81. | Урал татарлары. Татарлар һәм башкортлар | Датасыз | 51 кгз |
| 82. | Әхмәтшәех Әхмәтшакир әл-Куяни. Карт бабаларыбызның тарихы. Куян авылы, 1968. Кулъязманың эчтәлеге һәм тасвирламасы. Кулъязманың номеры бирелмәгән. | Датасыз | 17 кгз |
| 83. | Әхмәтшәех Әхмәтшакир әл-Куяни. Карт бабаларыбызның тарихы. Тәнкыйди текст гарәп һәм кирилл хәрефләре белән | Датасыз | 82 кгз |
| 84. | Тәварихе Алты Ата. Кулъязманың эчтәлеге | Датасыз | 8 кгз |
| 85. | Мәхүбҗамал Шәяхметова Әфләтүн кызы. Югары Суыксу авылы (Чаллы районы) тарихы. Текст | 27 июль 1975 | 30 кгз |
| 86. | Хәй Нәҗип улы Хәкимов. Чалпы авылы (Азнакай районы) тарихы. Кулъязманың эчтәлеге | 1970 нче еллар | 5 кгз |
| 87. | Аллаһияр Беләшев. Әҗе авылы хакында. Казан, 1924. Күчермә | Датасы | 33 кгз |
| 88. | Авыллар тарихы жанры. Материаллар. | Датасы | 100к гз |
| 89. | Альберт Фәтхи. Көндәлек язмалар | 1969 | 95 кгз |
| 90. | Альберт Фәтхи. Көндәлек язмалар | 1960 еллар | 78 кгз |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 91. | Хәсәнгата Габәши архивыннан күчермәләр. | Датасыз | 171 кгз |
| 92. | Солтан-Әхмәт Габәши язмаларыннан күчермәләр | Датасыз | 56 кгз |
| 93. | Татарларда музыка | Датасыз | 36 кгз |
| 94. | Мөхәммәд-Камал Мозаффаров архивыннан күчермәләр. | Датасыз | 107 кгз |
| 95. | Татар әдәбиятында эпистоляр сәнгате. Күчермәләр. Номерлар белән | Датасыз | 240 кгз |
| 96. | Габделҗәббар Кандалый шигырьләренең күчермәләре | Датасыз | 147 кгз |
| 97. | Татар әдәбиятында гыйшкый хатлар. Күчермәләр, номерлар белән | Датасыз | 163 кгз |
| 98. | Галимҗан Ибраһимов. Татар телен җиңеләйтү турында тезислар. 1924. Күчермә | Датасыз | 178 кгз |
| 99. | Утыз-Имәни кульъязмалары, шифр белән | Датасыз | 21 кгз |
| 100. | Татар галимнәренең әсәрләре, шифр белән. Биографик материал бар | Датасыз | 55 кгз |
| 101. | А. Фатхи. Отчет о работе Восточного сектора ОРРК НБ КГУв 1980 году. Кульъязма | 1981 | 14 кгз |
| 102. | А. Фатхи. Отчет о работе Восточного сектора ОРРК НБ КГУв 1981 году. Кульъязма | 1982 | 36 кгз |
| 103. | Шәрык фонды тарихыннан. Хатлар | 1953–1988 | 81 кгз |
| 104. | В. Аристов. Докладная записка [о проверке восточного сектора ОРРК] | 30 май 1965 | 5 кгз |
| 105. | Альберт Фәтхи. Үземнең язма хезмәтләрнең тармаклары, төрләре, хронологиясе | 1968 | 22 кгз |
| 106. | Кульъязмалар фонды эш тарихы | 24 июнь 1983 | 11 кгз |
| 107. | Альберт Фатхи. Долгосрочный перспективный производственный план Восточного Сектора ОРРК НБ КГУ | 12 май 1986 | 4 кгз |
| 108. | Альберт Фәтхи. Мәгарәдә алынган сабаклар. Тарих вакыйгага әверелгән бер доклад тексты. | 1964 | 4 кгз |
| 109. | Д. Абдуллина. Татар кульъязма мирасы өстендә эшләүче галимнәр. | Датасыз | 5 кгз |
| 110. | КДУ ФК КСының эшчәнлеге | Датасыз | 104 кгз |
| 111. | Альберт Фәтхи. Автобиография өчен | Датасыз | 6 кгз |
| 112. | Решение заседания партийного бюро Научной библиотеки КГУ | 12 гыйнвар 1962 | 13 кгз |
| 113. | Протоколы отчетных собраний ОРРК | 1970–1973 | 35 кгз |
| 114. | Отчет о проверке фонда ВС ОРРК | 1963 | 14 кгз |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 115. | А. Фатхи. Отчет о работе Восточного сектора ОРРК НБ КГУв 1974 году. Кулъязма | 1974 | 9 кгз |
| 116. | Акт сдачи фонда восточного сектора ОРРК Нугмановым М. Фатхиеву А.С. | 12 сентябрь 1959 | 6 кгз |
| 117. | Объяснительная записка Фатхиева А.С. об акте по составлению Акта проверки восточного сектора | 19 декабрь 1963 | 22 кгз |
| 118. | Д. Абдуллина. Шәрык секторы хезмәткәрләре | Датасыз | 47 кгз |
| 119. | Отчет восточного сектора ОРРК за 1982 г. | 28 декабрь 1982 | 4 кгз |
| 120. | Шәрык секторының архивы. | 23 июль 1937 – 12 сентябрь 1959 | 168 кгз |
| 121. | Ризаэддин б. Фәхретдин. Асар. Альберт Фәтхи тарафыннан кириллицага күчерелгән | Датасыз | 530 кгз |
| 122. | Татар халкының аң-белем үсешендәге дәверләр хакында Риза Фәхретдин | Датасыз | 6 кгз |
| 123. | Ризаэддин Фәхретдиннең татар тарихы һәм язма мираска, методологиясенә караш | Датасыз | 24 кгз |
| 124. | Китапчылык һәм мәдрәсә тормышының информациясе һәм документлары. Шәкерт көнкүреше | 1991 | 178 кгз |
| 125. | Альберт Фәтхи. Мирас сабаклары. Мәгариф, фән, мәдәният буенча төрле чыганаклардан күчермәләр. | Датасыз | 97 кгз |
| 126. | Татар-башкорт мөселман мөфтилеге тарихы | Датасыз | 51 кгз |
| 127. | Наратлы (Мәчти) авылы мәдрәсәсендә күчерелгән китаплар | Датасыз | 13 кгз |
| 128. | Татар мулласының хәле. Күчермәләр | Датасыз | 59 кгз |
| 129. | «Мәдрәсәи Галия диния»нең ачылуына 10 ел тулу мөнәсәбәте белән булган дога мәҗлесе. 1916. Күчермә | Датасыз | 34 кгз |
| 130. | Татарларны чукындыру турында материаллар | Датасыз | 91 кгз |
| 131. | Кулъязма китаплар җеназасы турында язмалар | Датасыз | 29 кгз |
| 132. | Идел буйларының борынгы тарихына караган батыр дастаннары | Датасыз | 17 кгз |
| 133. | Татар китап шигыренең ритм-мелодия чаралары. Метрик формулалар һәм график схемалар | Датасыз | 27 кгз |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 134. | Румын татарлары шигырьләре | Датасыз | 2 кгз |
| 135. | Азәрбайҗан телендәге текстлар | Датасыз | 79 кгз |
| 136. | Борынгы төрки тел буенча курс материаллары | 1990 | 100 кгз |
| 137. | Татар халкы белән төрек халкының һәм аларның әдәбиятларының бәйләнышлары | Датасыз | 167 кгз |
| 138. | Татар тыйб гыйлеме | Датасыз | 104 кгз |
| 139. | XVIII–XIX гасыр татар медицинасының тәҗрибәләре | Датасыз | 238 кгз |
| 140. | Татар басма китабы | 1986 | 186 кгз |
| 141. | Татарская книжная среда | 1984 | 173 кгз |
| 142. | Шәрык секторының беренче инвентарь китабы | 1937 | 72 кгз |
| 143. | Список книг на татарском языке, имеющихся в фондах ЦНБ АН КазССР | Датасыз | 27 кгз |
| 144. | М. Госманов тарафыннан төзелгән фиһрист китабы. Экспедицияләрдә табылган кулъязмалар | 1989 | 25 кгз |
| 145. | Отчет об археографической поездке в Актанышский район ТАССР | 1970 | 5 кгз |
| 146. | Отчет об археографической поездке в Актанышский район ТАССР | 1971 | 7 кгз |
| 147. | Отчет об археографической поездке в Муслимовский район ТАССР | 1972 | 8 кгз |
| 148. | Отчет об археографической поездке в Сармановский район ТАССР | 1973 | 13 кгз |
| 149. | Отчет об археографической поездке в Нижнекамский, Заинский и Мензелинский районы ТАССР | 1974 | 10 кгз |
| 150. | Отчет об археографической поездке в Челнинкий, Мензелинский и др. районы ТАССР | 1975 | 7 кгз |
| 151. | Отчет об археографической поездке в Актанышский район ТАССР | 1976 | 4 кгз |
| 152. | Отчет об археографической поездке в Альметьевский и Актанышский районы ТАССР | 1977 | 4 кгз |
| 153. | Яңа кергән кулъязмалар. Актлар, хатлар, исемлекләр | 1959–1981 | 62 кгз |
| 154. | Нигездә сакланып яткан кулъязмаларның югалу тарихы | 1976 | 8 кгз |
| 155. | Кыр археография методикасы | 1969–1978 | 143 кгз |
| 156. | Татарское источниковедение | 1987 | 23 кгз |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 157. | Архео.информ.архив | 1987 | 7 кгз |
| 158. | Ун ел (1987–1987) дәверендә эшләүнең перспектив планы | 1987 | 7 кгз |
| 159. | Минзәлә төбәге һәм рәсем сәнгате | Датасыз | 6 кгз |
| 160. | Татар китап, мәгърифәт дөньясы һәм сынлы сәнгать | 1982 | 15 кгз |
| 161. | Шәмаил | 1982 | 9 кгз |
| 162. | Эш перспективасы | 1987 | 14 кгз |
| 163. | Этика обращения с рукописями | 1983 | 4 кгз |
| 164. | Библиографик белемлек | Датасы | 3 кгз |
| 165. | Археографическая работа в КГУ | 1987 | 64 кгз |
| 166. | Татар китап мохите | 1984 | 58 кгз |
| 167. | А.С. Фатхи. Культурно-историческое значение новых поступлений рукописей, найденных археографической экспедицией в Сергачевский район | 1960 нчы еллар | 17 кгз |
| 168. | Татар кулъязма китабы | 1985 | 29 кгз |
| 169. | Археографик тикшерү ысулы | 1963–1976 | 43 кгз |
| 170. | Альберт Фәтхи. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязма мирасын саклау һәм тасвирлау эшенең кайбер йомгаклары һәм перспективалары (Казан университеты Фәнни китапханәсенең Көнчыгыш кулъязмалары секторында соңгы 15 ел эчендә эшләнгән эшләргә кыскача күзәтү | 1970 нче еллар | 63 кгз |
| 171. | Альберт Фатхи. Моя биография | 1990 | 753 кгз |
| 172. | Материалы к биографии Альберта Фатхи | 1990 | 380 кгз |
| 173. | Дагстан белән бәйләнешләр | 1961 | 66 кгз |

***Әлфрид Кашаф улы Бустанов,***
*Россия ислам халыклары тарихы буенча ТАИФ профессоры,*
*Санкт-Петербургның Европа университеты*

УДК 821.512.145

*М.И. Әхмәтҗанов*

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА АЛТЫН УРДА ПОЭЗИЯСЕН ФӘННИ НИГЕЗДӘ ТИКШЕРҮНЕҢ БЕРЕНЧЕ ТӘҖРИБӘСЕ

Статья посвящена исследованию произведения средневекового автора Хисама Кятиба «Джумджума султан» (1369). Автор статьи признает вклад Дж. Алмаза в этом направлении, обращается к источникам, сравнивает поэму с «Божественной комедией» Данте, проводит параллели с творчеством современников, прослеживает поэтические традиции в татарской литературе более позднего периода.

**Ключевые слова:** литература периода Золотой Орды, творчество Хисама Кятиба, дастан «Джумджума султан», Джавад Алмаз.

Билгеле булганча, Алтын Урда чоры татар әдәбияты истәлекләреннән (XIV йөз) безнең замангача санаулы гына шигъри әсәрләр сакланып калган. Алар татар әдәбияты тарихында, абсолют алганда, XX гасыр урталарында гына өйрәнелә башладылар. Шулар арасыннан берсен – Хисам Кятибнең «Хикәйәте Җөмҗөмә солтан» поэмасын – татар наширләре беренче мәртәбә 1872 елда Казан университеты басмаханәсендә аерым китап рәвешендә бастырып чыгардылар. Ләкин татар әдәбияты тарихын тикшерүчеләр соңгы елларгача аның басылу вакытын 1881 ел дип күрсәтәләр [Татар..., б. 231; Исламов].

Хисам Кятибнең безнең көннәргәчә сакланып калган әлеге бердәнбер поэмасының 1970–2008 еллар археографик экспедицияләре вакытында табылган ун күчермәсе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Кулъязмалар һәм музыкаль мирас үзәгенең 39 коллекциясендә саклана. Аларның алтысы бу юлларның авторы тарафыннан Татарстан авылларында табылды.

Җәвад Алмаз үзенең Хисам Кятиб мирасын өйрәнүгә багышлаган эшчәнлегендә «Җөмҗөмә солтан» дастанын төрле яктан якын килеп тикшерә. Ул аны поэзия теле белән хәзерге татар әдәби теленә һәм, мәгънәсен саклап, юлга-юл урыс теленә тәрҗемә итә. Аның сюжет үзенчәлекләрен, поэтикасын тикшереп мәкаләләр дә яза. [Әхмәтҗанов, б. 41–56]. Кызганычка каршы, галимнең бу темага кагылышлы эшчәнлеге искә алып киткән татар телендәге тәрҗемәсе мисалында гына матбугатка чыгу бәхетенә иреште. Аның кулъязмасының гарәп язуындагы тексты күчермәсен шагыйрьнең апасы Мөгаззәмә ханым Казанга минем үземә адреслап җибәргән иде. Бу текст фән кешеләренә, борынгы татар поэзиясен сөючеләргә бик ошады һәм аңа сылтамалар фәнни басмаларда да күренә (гәрчә аның тулы чыганагы турында мәгълүматларын бирмәсәләр дә).

Киләчәктә талантлы галимебез Җәвад Алмазның филологик һәм әдәби хезмәтләренең тупланмасын чыгару да изге бурыч, чөнки тирән белемле, сәләтле галимнәрнең хезмәтләре фәнгә хезмәт итәргә, һичшиксез, лаек.

## Җөмҗөмә дастаны

Дөнья әдәбиятында мифологик сюжетлы борынгы әсәрләр, мифны куллануда күздә тотылган максаттан чыгып, ике төркемгә бүленә ала. Беренче төркем әсәрләрдә миф динне пропагандалау максатында кулланыла. Мондый әсәрләргә мисал итеп XIII гасырдагы Иран суфиларыннан шагыйрь Шәех Фәридетдин Гаттар әсәрләрен күрсәтергә була. Икенче төркем әсәрләрдә исә миф аркылы реаль тормыш эчтәлеге бирелә. Һәм шагыйрь яшәгән чорның тарихи чынбарлыгы чагылдырыла. Байронның «Каин»ы (Кабил), Джоне Мильтонның «Югалган оҗмах»ы һәм Италия шагыйре бөек Дантеның «Илаһи комедия»се, сюжетлары белән мифка корылган булуларына карамастан, әнә шундый әсәрләрдән санала.

1370–1377 елларда Хисам Кятиб тарафыннан Идел буенда язылган «Җөмҗөмә дастаны»ның сюжеты да мифологиядән алынган. Бу сюжетны без Шәех Гаттар иҗатында да очратабыз.

Ләкин Хисам Кятиб язган «Җөмҗөмә дастаны»н, «мифның гомуми сызыкларын саклаган булуына карамастан, дини әсәрләр рәтенә кертергә ярамый» [Бертельс, с. 272]. Чөнки дастандагы төп идея феодализм җәмгыятендәге иҗтимагый тигезсезлеккә каршы юнәлдерелгән.

Билгеле булганча, феодаллар, җәмгыятьтәге сыйнфый тигезсезлекне аклар өчен, «ак сөякләр» һәм «кара сөякләр» хакындагы тәгълиматны уйлап чыгарганнар. Бу тәгълимат буенча, Алла феодал-аристократларны ак сөяк итеп, гади халыкны исә кара сөяк итеп яраткан имеш.

Татар феодаллары гына түгел, үз вакытында рус дворяннарына да гасырлар дәвамында халыкны изәргә теоретик нигез булып килгән менә шул тәгълимат «Җөмҗөмә дастаны»ның кереш өлешендә инкарь ителә. Хәлбуки, динчеләр бу тәгълиматны яклаганнар. Алар, ак сөяк феодалларга халыкны эксплуатацияләү хокукын Алла үзе биргән, шуңа күрә феодаллар сезне күпме генә җәберләсәләр дә түзегез, дип, халыкның колагына дин исеменнән, Алла исеменнән тукып торганнар. Дөнья фани, ул барыбер бетәчәк, шуңа күрә дөньяны түгел, ахирәтне кайгыртыгыз, янәсе.

Ак сөякләр хакындагы тәгълиматны инкарь итүче кеше логика буенча дингә дә каршы булырга тиеш иде. Ләкин Хисам Кятиб, үз чорының вәкиле буларак, бала чагыннан ук җәмгыятьтәге хаким идеология булган дин рухында тәрбия алган. Дастаннан күренә ки, аның авторы дингә, Аллага ышана. Шуңа күрә, шагыйрь үзенең дастанын:

*Әй, җиһан бакыйдыр, тигән*
*кане* (диючеләр кайда)?
*Ишетең дөнья эшен, белең,*
*белең аны:*
*Чөн бу галәм гакыйбәт* (ахырда)
*юк булысар* (булачак)...

дип, дини догма белән башлап китә. Ләкин шагыйрь бу догманы тар рамка белән чикләп, кеше гомере, җан ияләренә карата гына куллана. Һәм дастанның:

*Бондагылар һич бакый*
*калмасалар...*
(яшәп торучыларның берсе дә мәңге калмаячак)
*Нә кибар мәхлукат барча китәр*
(барлык җан иясе дә, яшәгәч, үләчәк)

дигән юлларында инде реаль чынбарлык чагыла.

Яшәп торган кеше үлми калмый. Бу хакыйкать. Ләкин динчеләр, «барыбер үләсез, дөнья ул өч кенә көнлек. Үз хокукыгызны яклап маташмагыз» дип, бу хакыйкатьне гади халыкны пассивлыкка өндәр өчен файдаланалар, ә Хисам Кятиб аны феодалларга каршы бора. Залимлыклары белән мәшһүр булып, үлеп киткән борынгы патшаларны санап киткәндә, шагыйрь аларның язмышын:

*Йатдылар бер парә бүзгә*
*чолганып,*
*Тәнләре үз канларыга болганып,*

дигән юлларда тасвирлый.

Моңа охшаш тасвир ул чордагы Идел буе әдәбиятының икенче бер үрнәге булган Хөсрәү вә Ширин романында:

*Ничә күп адәмиләр йиргә керде,*
*Ничә күп дустны бу дусдин*
*азырды* (аерды),
*Ничә шаһман тигәнне йиде*
(ашады) *бу йир,*
*Тәкый куймады тотшу (тоташ) тиңмәдән бәр* (берсен дә)

дигән юлларда бирелә. (Бу дүртьюллык һәм бу әсәрдән китерелгән башка өзекләр А. Зайончковскийның 1958 елда басылып чыккан факсимилесеннән алынды). Ләкин Хөсрәү вә Ширин заманында ул абстрактлылыкка ия. «Җөмҗөмә дастаны»нда исә шагыйрь яшәгән чордагы дәүләт башлыкларына – залим ханнарга ишарә бик көчле.

Ләкин болар дастандагы төп фикер – идеяне әйтер өчен әзерлек кенә әле. Шагыйрь аңа бик саклык белән, шактый уратып якынлаша. Башта ул укучының дикъкатен башка якка – җир өстенә борып җибәрә. Гомәр Хәйям мотивларын хәтерләтә торган сокландыргыч гыйбарәләр белән шагыйрь җир өстен тасвирларга тотына. Менә бакчада үскән сөмбел һәм нәркиз чәчәкләре. Аларның берсе гашыйкларның күзен, икенчесе чәч бөдрәләрен хәтерләтә. Алар туфракта үсеп чыкканга шулай. Туфрак исә черегән үлекләрдән тора...

Табигать ташкынының мондый эзлексезлеген, материянең бер формадан икенче формага: кешенең – туфракка, туфракның – чәчәкләр, гөлләр, үсемлекләргә, аларның исә җан ияләренә күчеп, туктаусыз үзгәреп торуын сизмләү тойгысы Идел буе әдәбиятында «Җөмҗөмә дастаны»на гына хас түгел. Мәсәлән, «Хөсрәү вә Ширин» романындагы:

*Һавада тикмә* (һәрбер) *заррә*
(бөртек) *кем очра, бел,*
*Фәридун ул йа Кәйхосрәт фикер*
*кыл.*
*Әвуҗ* (бер уч) *тупрак бу йир үзә*
*табулмаз,*
*Кем анда адәминең каны*
*булмаз.*

дигән юлларда шундый ук тойгы бар. Бу юлларны «Җөмҗөмә дастаны»ндагы:

*Бу кара йир /кем/ күрәсән*
*туп-тулуг*
*Адәм угланларыйдур кечек һәм*
*олуг*
*Һәр кадәм* (адым) *кем йир*
*өстенә басарсән,*
*Һәр адымда адәм йөзенә*
*басарсән.*

юллары белән чагыштырганда һәр ике шагыйрьдәге тойгы һәм фикер берлеге ачык күренә. Ләкин шагыйрьләрнең бу тойгыдан файдаланулары ике төрле: Котб гафил ятмаска өнди, Хисам Кятиб исә яшьнең дә, картның да, ярлының да, байның да, патшаның да, колның да бер үк туфракта ятып черегәнлеген тасвирлагач, бердән аларның өстеннән туфрак пәрдәсен ачып ташлый:

– Әнә, карагыз – ди ул – аларның сөякләрен җил ачып киткән. Тик бу сөякләрнең кемнеке икәнен генә белеп булмый. Колныкымы алар, әллә ханныкымы? Байныкымы, әллә ярлыныкымы?

*Олуг, кечек, бай, юксул –*
*билгүсез,*
*Әмир, мискин, кол, солтан –*
*билгүсез,*

ди шагыйрь, буш шыр сөякләргә кулы белән төртеп күрсәткәндәй.

Нәкъ шул чорда Хисам Кятибнең замандашы Сәйф Сараи үзенең «Гөлестан» тәрҗемәсендә:

*Бер кеше бакса ачып гүр эченә,*
*Белмәгәй яткан мәлик* (патша)
*му йа гада* (хәерче),

дип Хөсамга аваздаш фикерне язып чыга.

Югарыда китерелгән фактларның барысы да Алтын Урда ханнарының золымына каршы көрәшүчеләрнең ул чакта ялгыз булмаганнары, аларның көрәше шактый көчле һәм киң колачлы булганы хакында сөйли. Ханнар тираниясенең егылуына идеологик җирлек әзерләүдә «Җөмҗөмә дастаны» кебек әсәрләрнең роле шактый зур булган, диясе килә.

Җыеп әйткәндә, дастанның көрәш өлешендә автор феодалларның ак сөякле, гади халыкның исә кара сөякле булып яратылулары хакындагы догманың табигый дөрес түгеллеген фаш иткән. Бу тәгълиматның абсурдлыгын сокландыргыч образлы тел, стиль чаралары белән тасвирлап биргән.

Шулай итеп «Җөмҗөмә дастаны»ндагы идея түбәндәгедән гыйбарәт: җәмгыятьтә кешеләрне ак һәм кара сөякләргә бүлүнең һичнинди нигезе юк. Кешеләрнең, җәмгыятьтә кем булуларына карамастан, сөякләрендә һичнинди аерымлык юк.

Дөрес, дастанда ак сөякләр тәгълиматның дөрес түгеллеге фәнни исбатлау юлы белән түгел, бәлки тасвирлау юлы белән күрсәтеп бирелгән. Дастанның художство көче шунда ки, андагы идея образлы тасвирлар артына бик нык яшерелгән. Дастанда ак сөякләр тагълиматы хакында һичнинди сүз юк. Шул ук вакытта укучы бу тәгълиматның дөрес түгелле хакындагы идеяне дә бик яхшы аңлый.

Шиксез, «Җөмҗөмә дастаны»ның авторы феодализмны инкарь итәргә теләми, ул бары тик дини-дидактик һәм гуманистик күзлектән карап, җәмгыятьтә иҗтимагый тигезсезлекне төзәтмәкче була. Ләкин фикер әйтелгән. Һәм ул, шагыйрьнең ихтыярыннан башка, аның замандашлары – ак сөякләр золымы астында изелүчеләр аңында «биологик яктан бер булгач, кешеләрнең җәмгыятьтәге хокукла-

ры да тигез булырга тиеш» дигән фикер тудырмый калмаган. Шуңа күрә булса кирәк, дастан соңрак динчеләр тарафыннан бидгать (ересь) әсәрләр рәтенә кертелгән. Аны мәктәпләрдә укудан тыйганнар. Нөсхәләре исә итек астыннан гына күчереп йөртелгән. XIX гасырның ахырында Казанда басылган нөсхәләрдә дастанның иң мөһим урыннары (Чынгызның Бохтеннәсар белән тиңләштерелүе, дөнья тоткан патшаларның канга батып, кәфенгә чолганып ятуларын тасвирлаган юллар һәм башкалар), шул җөмләдән, череп яткан сөякләрнең кемнеке булуы билгесез, дип язылган юллар да төшерелгән. Нәтиҗәдә, Казан басмаларындагы текстларда дастанның дини ягы көч алган. Кыскасы, татар буржуазиясе дастанның эксплуататорларны фаш итә торган юлларын төшереп, әдәби мирасны бозып бастырган. Шул фактның үзе генә дә, бер яктан, дастан файдасына сөйләсә, икече яктан, дастанны өйрәнү безнең өчен бик әһәмиятле икәнен күрсәтә.

* * *

Җөмҗөмә дастанын укыганда аны ирексездән бөек Дантеның (1265–1321) «Илаһи комедия»се белән чагыштырасы килә. Бу ике әсәр арасындагы охшашлык шулкадәр зур ки, ул беренче караудa ук күзгә ташлана. Һәр ике шагыйрь да, динчеләргә каптма-каршы буларак, миф аркылы үзләре яшәгән чордагы тарихи чынбарлыкны чагылдыралар һәм укучыны, динчеләр кебек, чынбарлыктан ераклаштырмыйлар, бәлки аның эченә алып керәләр. Моңа игътибар иткән профессор Е. Бертельс тә үз вакытында «Җөмҗөмә үзе хакында сөйләгәндә ачык рәвештә Алтын Урда ханнарының сарай тормышын тасвирлый» [Бертельс, с. 272] дигән иде. Бу дөрес, ләкин тулы түгел. Чөнки дастанда сарай тормышы гына түгел, бәлки феодализм чынбарлыгы үзенең капма-каршылыклары белән нәкъ көзгедәгедәй чагылган.

Дастанда бер якта җәмгыятьнең бөтен байлыгын үзләштергән феодаллар: ханнар, солтаннар, бәкләр, вәзирләр тасвирлана. Алар алтын сарайлар эчендә, җыр һәм музыка астында эчемлек эчеп, җарияләр кочагында көне-төне кәеф-сафа коралар. Хаким сыйныфның шатлыклы тавышы сарайларны яңгыратып, күкләргә аша. Икенче якта исә ак сөякләр тарафыннан изелгән, таланган ач, ялангач, мохтаҗ халык Җөмҗөмә солтанга ярдәм сорап килгән ярлылар образында тасвирлана. Ул, феодализм чорындагы хокуксыз халыкның нәкъ үзе кебек, хәтта сөйләү хокукыннан да мәхрүм. Бу образ дастанда бер сүз дә сөйләми. Аның хәтта исеме дә юк. Шуңа карамастан, ул онытылмаслык булып истә кала. Дастанны укыгач та ханның ишегенә мохтаҗлыктан ярдәм сорап килергә мәҗбүр булган сәләмә киемле, өс-башы каткан, күзләре, яңаклары эчкә баткан мескен фәкыйрь күз алдыннан китми. Аның ирennәре сүзсез генә ярдәм сорап кыймылдыйлар, селкенәләр төсле. Ләкин аңа ярдәм бирмиләр генә түгел, хәтта каты сүзләр белән сүгеп, куып җибәрәләр. Ул исә килгәндәге кебек үк, сүзсез генә сынык күңел белән борылып, кире китә.

Бу образны гомумиләштерү, типиклаштыру көче шулкадәр зур ки, аның аркылы феодализм чорындагы хезмәт ияләренең барысы да шул мохтаҗ, телсез образның миллионнарча

тапкыр күбәйтелгән суммасы кебек гәүдәләнә.

Дастан авторының бу образга мөнәсәбәте уңай. Бу, бер яктан, ярлы куылганны белгәч, Җөмҗөмәнең:

*Китте ул мискин күңелле,*
*йыкыйур* (елгыр),
*Чөн күңел йыкылды, – ир-ат нә*
*кылур?*
*Калды вәйран, ул күңелне*
*йапмадым*
*Соңрак аны күп эстәдем, –*
*тапмадым,*

дигән үкенү сүзләрендә чагыла. Икенче яктан исә, хезмәт ияләренең тәмугта җәзаланмавында күренә.

Тәмуг образы дастанда, динчеләр кебек, кешеләрне Алладан куркытыр өчен түгел, бәлки Дантеның «Илаһи комедия»сендәге кебек, җирдәге тормышны тулырак күрсәтү һәм гуманистик фикерләр пропагандалау өчен файдаланыла. Тәмуг дастанда җирдәге тормышны төзәтү, кешеләрне турылыклы һәм гадел яшәргә мәҗбүр итү максатына хезмәт итә.

Тәмугта җәзаланучылар галереясының тасвирлануы, ниһаять, үткер, сәяси төс алган. Дастанның бу урынында шагыйрьнең фикер угы җәмгыятьтәге хаким сыйныф вәкилләре: байларга, риба (бурычка бирелә торган акча өчен алына торган зур процент) ашаучыларга (ростовщикларга), ришвәтче судьяларга, ханның урыннардагы вәкилләренә, ниһаять, баш феодалның үзенә – ханга, солтаннарга, патшаларга каршы юнәлгән.

Тәмуг феодализм вәкилләре белән тулы. Шагыйрь бу образларга тискәре мөнәсәбәттә. Феодализмдагы хаким сыйныф вәкилләренең берсендә дә уңай сыйфат юк. Алар бар да кеше талаучы, ришвәтче, ятимнәр хакын ашаучы, хезмәт ияләрен җәберләүче кешеләр. Шагыйрь, бөек художник буларак, феодаль чынбарлыкны дөрес чагылдырган. Хәтта күршеләрен рәнҗетүче, яла ягучы, гайбәтче, борын күтәрүче, юл басучы һәм башка шундый образларның бу җәмгыятькә турыдан-туры мөнәсәбәте бар. Чөнки мондый типлар сыйнфый җәмгыять, шул җөмләдән феодализм җәмгыятенең дә котылгысыз нәтиҗәсе. Шуңа күрә бу образлар дастанда хаким сыйныф вәкилләрен тулырак күрсәтергә, аларны контраст фонда тасвирларга ярдәм итәләр.

Данте үзенең «Илаһи комедия»сендә, кеше җәмгыятьтә нинди начарлык эшләгән булса, аңа тәмугта шундый төрдәге җәза бирелә, ди. Бу символик характердагы алымны без Хисам Кятибтә дә күрәбез. Мәсәлән, башкисәрләрнең утлы кылыч белән башларын кисәләр. Киселгән җиргә яңа баш үсеп тора. Утлы кылыч исә аны туктамый кисеп тора. Сансыз алтын-көмеш җыйган саран байларның битләренә, күзләренә алтын акча кыздырып басалар. Оятсызларның битләрен утлы чылбыр белән кыйныйлар. Ялангачларга кием бирмәгәннәр – мәңге киемсез йөрергә, ятимнәр малын үзләштерүчеләр – ут ашарга, борын күтәрүчеләр – башлары белән йөрергә, кеше гаебен генә күрүчеләр күзсез яшәргә дучар ителгәннәр.

Шул планда патшаларга бирелгән җәза аерата характерлы. Аларны елан, чаяннар тулган табутка салалар. Алар чага, тешли һәм патшаларнаң итен ашый. Ашалган җиргә яшь ит үсеп бара, елан, чаян исә аны тагын ашар-

га тотына. Бу газаплы процесс туктамастан кабатланып тора. Бу җәза да символик характерга ия: халык кул көче белән хезмәт итеп, азмы-күпме рәтләнергә өлгерә алмый, аның бар тапканын патшалар төрле салымнар белән алып баралар. Халык тагын эшли, тагын таба. Патшалар да өзлексез аның тапканын ашап торалар. Шуңа күрә тәмугта аларның үзләрен дә тере килеш чаяннар ашый. Табутка салынган Җөмҗөмәнең:

*Мару-у гакрәб* (елан-чаян) *терт йаруга* (дүрт якка) *барсам мән.*
*Кеми санчар* (чагар), *кемисе тешләр иде.*
*Ул камуг* (барысы) *мән кылганым эшләр иде.*

дигән сүзләрендә патшалар халык өчен елан-чаяннар белән бер, дигән фикер бик ачык әйтелгән. Шуңа күрә дә шагыйрь иҗтимагый тигезсезлекнең иң югары баскычында торган патшаларга җәзаның иң авырын биргән, аларны тамугның «әсфәл» дигән иң газаплы җиренә урнаштырылган.

Кыскасы, феодалларга хаким сыйныф вәкилләренә һәм патшаларга шагыйрьнең мөнәсәбәте тискәре. Ләкин, шул ук вакытта, Хисам Кятиб сәяси карашы белән көчле утопист. Бу сәяси караш шагыйрь яшәгән феодаль тормыш шартлары белән чикләнгән. Чикләнгәнлек шагыйрьнең Җөмҗөмә образына мөнәсәбәтендә бик ачык күренә. Ә ул исә катлаулы һәм капма-каршылыклы.

Хисам Кятиб, художник буларак, бер яктан, Җөмҗөмә солтанны халыкка күрсәткән начарлыклары өчен, ягъни патшалардан бер патша булганы өчен тәмугта җәзалый. Җөмҗөмәнең үз сүзе белән әйткәндә, ул үзе халыкка нишләгән булса, елан-чаяннар да аңа шуны күрсәтәләр. Икенче яктан исә, шагыйрь Җөмҗөмә образында үзенең шәхси сәяси карашларына туры килә торган гадел патшаны тасвирларга омтыла. Шагыйрь хыялында Җөмҗөмә образы башка ханнар өчен үрнәк булырга тиеш булган. Шуңа күрә аңа патшаларга хас булмаган сыйфатлар бирелгән: Җөмҗөмә үз халкы өчен яхшы, игелекле, рәхимле, юмарт һәм ярлыларга ярдәмле итеп тасвирлана. Ул ярлыны да, байны да тиң күрә. Шуңа күрә башка патшалар тәмугта мәңге калсалар да, Җөмҗөмә мәгълүм бер вакыттан соң тәмугтан азат ителә. Шунысы характерлы: шагыйрь фикеренчә, әгәр патша гадел булса, аның мөселман яки кяфер булуының да әһәмияте юк. Шагыйрьнең үз сүзе белән әйткәндә:

*Бакмаң аның көференә һәм җәһләнә* (наданлыгына),
*Кем кәрәмләү* (юмарт) *ирде ул үз әһленә.*
*Һәм бакар ирде фәкыйрь, гәдайны*(теләнчене),
*Тиң тотарде* (күрә иде) *йарлыны һәм байны.*

Бу – шиксез, шагыйрь хыялындагы «идеал» патша образы гына. Чынбарлыкта мондый патша булмаган. Шуңа күрә, Җөмҗөмә образы, шагыйрьнең үз карашлары кебек үк, капма-каршылыклы.

Бу образ аркылы шагыйрь, бер яктан, үзе яшәгән чорны дөрес чагылдыра, феодализмның төзәлмәс яраларын ачып, фаш итеп ташлый. Икенче яктан исә, шул ук образ аркылы, патшаларны Алла һәм дин исеме

белән гадел булырга өндәп, җәмгыятьнең төзәлмәс яраларын төзәтергә уйлый. Җөмҗөмәнең, терелгәч, гади кешеләр, хәтта дәрвишләрчә яшетелүен дә шул планда аңларга кирәк. Шагыйрь моның белән патшалар, ханнарга «әнә, сез дә Җөмҗөмә кебек, гади кешеләр ничек яшәсә, шулай яшәргә тиешсез», димәкче. Шагыйрь хыялындагы утопия аның гуманистик һәм дини-дидактик карашлары белән үрелеп бара. Дастан башыннан ахырына кадәр гуманизм белән сугарылган. Дастанның ахырында гуманизм аерата көчле.

*Мохтасар* (кыскасы), *будыр кем,*
*адәм угланы*
*Һәркем ирсә нә игәр, ургай аны*
(ни иксә, шуны урачак)...
*Тапмас ирмеш кеше дөньядан*
*морат,*
*Бәс калур ирмеш җиһанда изгүн*
*ат,*

дип, шагыйрь патшалар, ханнарны «ни чәчсәң, шуны урырсың» дигән образлы халык мәкале белән куркыта, аларны яхшы булырга, үзләреннән соң изге ат калдырырга өнди.

Башкача әйткәндә, шагыйрь феодаль җәмгыятьтәге явызлыкның иҗтимагый сәбәпләрен аңлый алмый. Һәм шуңа күрә бу явызлыкка каршы җәмгыять әгъзаларының, беренче чиратта, ханнарның әхлагын төзәтү юлы белән көрәшергә мөмкин, дигән ялгыш караштa тора.

Хисам Кятибнең, шагыйрь буларак, чынбарлыкны дөрес чагылдыруы белән аның сәяси карашлары арасындагы килешә алмаслык тирән капма-каршылыкларны шагыйрь яшәгән чор белән аңлатырга кирәк. Ул Хисам Кятибкә генә хас сыйфат түгел. Гадел хан хакында хыяллану ул чордагы Идел буе әдәбиятында, мәсәлән, югарыда телгә алынган Хөсрәү вә Ширин романында да бар. Бу Хөсрәүгә Ширин авызыннан әйттерелгән түбәндәге үгет-нәсыйхәттә бик ачык күренә:

*Үкүш* (күп) *ил каргышын алма,*
*сакынгыл* (саклан),
*Рәгыйәт* (халык) *асрамак яхшы*
*ирүр, бел.*
*Каю* (кайсы) *хандин рәгыйәт*
*булса азар,*
*Тимешләр кем, калур ялгур,*
*булып хар* (хур).
*Сән үз файдаң өчен бер пәндем*
*алгыл* (сүземне тыңла).
*Рәгыйәткә золым кылма, гадел*
*кыл.*
*У шул ханлыкда мән һич файда*
*күрмән* (күрмим),
*Кем, иркем бар, тип ил азарласаң*
*сән.*

Гадел патша хакындагы фикер ул чорда дөнья әдәбиятында бик киң таралган була. Хисам Кятибнең өлкән гасырдашы Данте дә, император гадел булса, җәмгыять яхшы булачак дигән караштa торган, «Илаһи комедия» кебек бөек әсәр яза алган.

Хисам Кятиб, бер яктан, гаделлек эзләүче утопист, үз чорының вәкиле буларак, гуманизмны дөньядан аермаслык дәрәҗәдә, дини рухта тәрбияләнгән бер кеше. Икенче яктан исә, Дантеның «Илаһи комедиясе»нә тиң булырлык «Җөмҗөмә дастаны»н барлыкка китергән бөек художник. «Комедия» белән «Җөмҗөмә дастаны» арасындагы охшашлык шулкадәр зур ки, ихтыярсыздан, берсенең икенчесенә тәэсире булмаган микән, дигән сорауны куярга туры килә.

Академик В.В. Радлов тарафыннан татар теленең мишәр сөйләшенә якынлыгы исбатланган [Радлов, с. 52–53]. «Кодекс Куманикус» сүзлеге XIII гасыр башында итальянлылар тарафыннан ике телдә – кыпчак-латин телләрендә төзелгән. Сүзлекнең асыл нөсхәсе Хисам Кятибнең замандашы, поэзиядә исә Дантеның шәкерте һәм фикердәше булган Италия шагыйре Ф. Петрарка (1304–1374) тарафыннан Венеция республикасына 1362 елда бүләк ителгән [Радлов, с. 3].

Бу сүзлекнең Петрарка кулында булуы очраклы хәл түгел. Петрарка Венеция белән Генуя арасындагы көнчыгыш «варвар» дәүләтләр, беренче чиратта Алтын Урда белән сәүдә конкуренциясеннән килеп чыккан низаглы мәсьәләләрне тыныч юл белән хәл итү эшләренә якыннан катнаша. Италиядән Алтын Урдага бара торган төрле илче-делегатлар арасында Петрарка кебек кешеләр дә булган һәм алар Алтын Урдадагы Хисам Кятиб кебекләрне Италия культурасы белән таныштырмый калмаганнардыр, дип уйларга кирәк.

Чит ил кешеләрен, башлап, сарайда кабул иткәннәр. Кабул мәрасиме, кагыйдә буларак, кятиб яки бетекче дип аталаган сарай сәркәтипләре тарафыннан оештырылган. Бер үк вакытта алар тылмач та булганнар. «Җөмҗөмә дастаны»ның авторы Хисам үзен кятиб дип атый. Бу сүз гарәб телендә язучы, әдип һәм сәркәтип мәгънәләрендә кулланыла. Беренче мәгънә күздә тотылганда Хисам үзен шагыйрь дип атаган булыр иде, шуңа күрә кятиб сүзе Хисамның гражданлык вазыйфасын, ягъни сарай сәркәтибе булуын белдерә, дип аңлау дөрес. Ул Хисамның бу тормышны бик якыннан белгәннән раслый һәм бу яктан дастан документаль төс ала.

Кыскасы, сарай кятибе булган дип уйлаганда да, үз чорының алдынгы укымышлысы буларак та, Хисамның Италия белән Алтын Урда арасындагы культура мөнәсәбәтләрендә якыннан катнашканын фараз итәргә нигез бар. Хәтта аның үзенең Италиядә булып, ул чакта ук бөтен Италиягә мәшһүр булган «Илаһи комедия» белән теге яки бу формада танышкан булуы бик мөмкин.

Бәхетсезлеккә каршы, Хисам Кятиб хакында мәгълүматлар бөтенләй сакланмаган диярлек. Бу өлкәдә тикшеренүләр әлегә көткән нәтиҗәне бирмәде. Бары тик француз телендә төзелгән төрки кульязмалар каталогында Әлхөссам Кятиб дигән кешенең Исагуҗи әсәренә шәрехнамә язуы теркәлгән. Бу кешенең «Җөмҗөмә дастаны»н язган Хисам Кятиб икәнлеге исбатланып җитсә, аның шагыйрь генә түгел, зур галим дә булганлыгы ачыкланачак.

Ул чордагы алдынгырак фикерле кешеләр Алтын Урдадагы золымнан еш кына Мисыр мәмлүкләре янына качып киткәннәр. Мәсәлән, «Гөлестан» тәрҗемәсенең авторы Сәйф Сараи да шундый мөһаҗирләрнең берсе булган [Нәҗип, б. 99]. «Җөмҗөмә дастаны»ның ахырында:

*Җөмҗөмә дастаны ишетәсән,*
*Кем Мисыр тәңрендин ирде*
*ошбу тән,*

дигән юллардагы «тән» сүзе Җөмҗөмәгә түгел, бәлки, шул юлны җәя эченә алып караганда,

авторның үзенә мөнәсәбәтле дип уйласак, Хисам Кятибнең, ниндидер сәбәпләр белән, Алтын Урдадан качып, Мисыр мәмлүкләренә барып сыенганы һәм дастанның Мисырда язылып, аннан үз Ватанына кайтканы хакында фикер йөртергә туры килә. Болай булганда, дастанның автографын яки күчереп алынган нөсхәләрен Мисыр китапханәләреннән, мәмлүкләр чорындагы кулъязмалар эченнән эзләргә кирәк була.

Кыскасы, Хисам Кятиб үз заманының алдынгы, укымышлы кешеләреннән булган һәм аның «Илаһи комедия» белән таныш булуы, гадәттән тыш, дип карала алмый. Һәр ике шагыйрьнең дә образлар барлыкка китерү ягыннан охшашлыклары «Илаһи комедия»нең «Җөмҗөмә дастаны»на тәэсире хакында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Дастандагы образлар, нәкъ «Илаһи комедия»дәге кебек, оста скульптор кулыннан чыккан һәйкәл кормасын хәтерләтә. Тел-стиль чараларыннан оста файдалану ул образларны шулай һәйкәлләштерә алган. Шагыйрь кыска, шома һәм көчле гыйбарәләрне үз урынында куллана белә. Шуның нәтиҗәсендә кыска гына җөмләләрдән торган 2–3 юллык шигырьдә тулысынча бер образ гәүдәләнеп күз алдына баса. Мәсәлән, тәмугта җәзалanучы саран байлар образы

*Зөбанилар алтын акча*
*кыздырып,*
*Баса анларның йөзенә*
*сыздырып.*
*Йәнә алып, күзләренә сызгурур*
(эретеп салыр),
*Нә күзе калур, нә йөзе...*

дигән дүрт юлда тулысынча тасвирланган.

Сурәтләү чаралары дастанда гаять көчле. *«Кан тутырмыш аска биңзәр* (охшар) *һәр күзе, төн тик кара золыф* (тән тик кара толым), *мисле арыслан идем»,* кебек чагыштырулар образлылык тудыруда зур роль уйныйлар.

Шагыйрь хәтта чынбарлыкта мөмкин булмаган сыйфат белән мәсәлән, *«күзе юк ирдә, күзендин акты яшь»,* яки:

«*...Тәңре фәрманы белә, теле-теше юк икән, килде телә* (телгә)» дип, образны гаять җанлы, контраст сурәтләүгә ирешкән.

Дастанда образлылык барлыкка китерү өчен, шагыйрь гиперболадан киң файдалана. Мәсәлән, ул Җөмҗөмә сараеның биеклеген тасвирлау өчен болай ди:

*Өстенә менгән йөкегән ирде*
*мәгәр,*
*Юкса, торса башы болытка*
*тигәр.*

Вәзирләрнең көчле икәнлеге *«тотып арыслан менәрлек һәрбере»* дигән гипербола ярдәмендә тасвирлана. Дастанда саннар да гиперболоик планда кулланыла. Алардан иң күп кулланыла торганнары мең һәм ун мең саннары: ун мең кол, ун мең хатын, ун җария, музыкантлар да меңәрләп санала. Җөмҗөмәнең бер сугышчысына мең кеше түзми. Казанда мең ат, мең сыер, мең җәя, ун мең куй пешә һ.б.

Шагыйрь шахмат гыйбарәсен кулланып көчле поэтик параллель тудыра. Бу гыйбарә, билгеле булганча, фарсыча «шаһ» һәм гарәбчә «мат» (матә) – (үлде) дигән сүзләрдән тора, ягъни шахмат – шаһ үлде дигән сүз була. Менә шуңа параллель буларак, Җөмҗөмәнең тормыш тактасында да, үлем килгәч, мат

була. Шахмат образы борынгы әсәрләрдә еш очрый. Мәсәлән, ул Котбның «Хөсрәү вә Ширин» романында:

*Ул уендан ерак тип ошбу*
*шаһмат*

дигән юлда кулланыла. (17 б. 12 юл). Ләкин ул «Җөмҗөмә дастаны»ндагы кебек гүзәл параллелизм түгел.

«Җөмҗөмә дастаны» Алтын Урда борынгы әдәби телендә язылган. Шуңа күрә аны ата-бабалары Алтын Урдада яшәгән хәзерге төрки халыкларның уртак мирасы дип карарга кирәк. Шул җөмләдән беренче чиратта «Алтын Урдада иҗат ителгән әдәбиятның турыдан-туры варислары булып, нигездә хәзерге татарлар белән башкортлар санала [Дилектологик..., б. 183–184]. Шулай булгач, бу дастанның борынгы татар әдәби теле әсәре дип танылуы бәхәссез булырга тиеш. Моннан тыш, дастанның кайбер үзенчәлекләре аның авторының ул замандагы кайсы диалект вәкиле булуына ишарә иткән. Дастан телендә хәзерге татар теленә генә хас булган сүз һәм тезмәләр бар. Мәсәлән: адым, болганып, борчы, иш, ират, иңсә, йавыз, каты, корсагым, кош-корт, тузан-туфрак, чолганып, чура [Дилектологик..., б. 183–184] тирә, агыз (авыз) суы корыды, борынын күтәреп, данлы йир (җир) йөзенә иңде, каным качты, кул сон (ды), таңга калды, тик йөрер, тәнем сызды, телә (телгә) килде, сүз әйтмәгә хәл (булмау) һ.б.

Дастанда хәзерге татар телендә кулланылмый торган борынгы төрки сүзләр: агаз кылды (башлады), ан тик (шушындый), дәгел (түгел), куңшы (күрше), кайра (кире), калуг (барысы), кане (кайда), карнак (җария), тирмән (җипкерү, ирештерү), саг сулә (уңга-сулга), сәрч, (хрусталь) уган (алла), ярмак акча һ.б.

Дастандагы бу борынгы төрки сүзләрнең барысы да «Кыйссай Йосыф»тан Г. Тукайгача дәвам иткән татар әдәби телендә кулланыла. Бу сүзләрнең күбесе – угыз-кыпчак сүзләре. Ләкин дастан, асылда, борынгы уйгур, угыз һәм кыпчак телләре элементларыннан укмашкан тел белән язылган һәм шул яктан ул борынгы татар әдәби теленең типик үрнәге булып тора. Дөрес, дастанның кулъязма нөсхәләре XVIII–XIX гасырларда гына күчерелгән. Һәм, шуңа таянып, ул нөсхәләр күчереп язучылар тарафыннан тел ягыннан яңартылган дип уйлыйлар [Дмитриева, с. 146]. Шуңа күрә, югарыда татар теленә хас дип китерелгән сүзләр барлык нөсхәләрне чагыштырып карау юлы белән алынды. Дастанда татар теленә хас булган сүз һәм гыйбарәләрнең күплегенә карап, «Җөмҗөмә дастаны»ның авторы хәзерге татарларның этногенезын тәшкил иткән төрки кабилә яки халыкларның бер вәкиле булса кирәк, дигән фикерне әйтергә була. Чөнки Алтын Урда чорындагы әдәби тел «берничә диалект йогынтысында формалашкан. Авторның кайсы кабиләнеке булуына карап, ул иҗат иткән әдәби әсәр дә билгеле бер дәрәҗәдә шул диалект элементларын чагылдыра» [Нәҗип, б. 95].

Дастандагы «чолганып», «каты», «кайра» кебек сүзләр һәм аерым гыйбарәләр болгар-татар теленә хас. «Тоз үтмәк ашау», «тоз үтмәк күңелен белмәү», «тоз үтмәк (хакын) саклау» кебек сүз тезмәләре сыйлану,

хөрмәт күрү мәгънәсендә кулланыла. Шул ук мәгънәдә бу гыйбарә «Кыйссаи Йосыф» дастанында һәм Кандалыйгача булган татар әдәби теле әсәрләрендә еш очрый.

Моннан тыш, дастанның хәзергәчә мәгълүм булган күчермә нөсхәләре татарлар арасында гына таралган. Санкт-Петербургтагы ике нөсхә дә Казаннан җибәрелгәннәр. Элекке Касыйм ханлыгы территориясе, хәзерге Рязань өлкәсе мишәрләрендә сакланган бер нөсхә минем тарафтан табылып, 1957 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы китапханәсенә тапшырылды. Нөсхәне саклаган кешеләрнең әйтүләренә һәм кәгазенә карап, бу нөсханең XVIII гасырның икенче яртысында язылганын чамаларга була. Казан университеты китапханәсендәге кулъязма нөсхәнең тексты да бик игътибарсыз күчерелгән.

Дастан Казанда берничә мәртәбә басылган. Шулардан минем кулымда 1872 елда басылган һәм Казан университетында 1882 елда басылган ике нөсхә саклана. Һәр ике басманың дә тексты бер. Бары тик соңгысында 1872 елгы басманың беренче юлындагы «тигән» сүзе «дигән»гә алмаштырылган.

«Кыйссаи Җөмҗөмә» дигән исем белән 1910 елда Казанда басылган тагын бер әсәр бар. Ул казакъ һәм татар телләре аралаш бер телдә язылган. Ләкин бу әсәр Хисам Кятиб дастанының тәрҗемәсе түгел. Сюжет берлегеннән башка бу ике әсәр арасында уртаклык юк.

Шул ук сюжетка үзбәк телендә язылган бер кулъязма әсәр 3696 номер белән Ташкентта, Үзбәкстан Фәннәр академиясенең кулъязмалар фондында саклана. Ләкин бу әсәрнең дә Хисам Кятиб дастанына мөнәсәбәте юк, ул, казакъ варианты кебек, турыдан-туры Шәех Гаттарны кабатлаудан тора. Сюжет детальләре белән дә әсәр Хисам Кятиб дастаныннан шактый аерыла. Мәсәлән, Җөмҗөмәгә ярдәм сорап килгән ярлы образы һәм феодалларны җәзалау урыны булган тәмуг образы үзбәк вариантында бөтенләй юк. Анда Җөмҗөмә ауда йөргәндә авырый. Дастан Җөмҗөмәнең Гайсаны үз шәһәренә кунак итәргә алып киткәне, ләкин шәһәр урынында хәрабәләр генә күргәч, гыйбадәткә керешкәне, ниһаять, мөселман булып үлгәч, фәрештәләр тарафыннан җәннәткә озатылганы тасвирлана. Хисам Кятиб дастанында боларның берсе дә юк. Үзбәк варианты күләм ягыннан да кечкенә (290 юл). Хисам Кятиб дастаны исә 584 юлдан тора.

Б. Яфаров тарафыннан төзелеп, басылгач та сәүдәгә чыга алмый калган борынгы татар әдәбияты хрестоматиясендә «Җөмҗөмә дастаны»ның бер нөсхәсе Кырымда, Сәхибгәрәй хан үтерелгәч аның архивыннан табылып, Төркиягә алып кителгәне һәм анда төрек теленә тәрҗемә ителгәне хакында мәгълүмат бар. Билгеле булганча, Сәхибгәрәй бер вакытлар Казанда хан булып торган. Киткән чакта исә дастанның бер нөсхәсен үзе белән Казаннан алып киткән булса кирәк. Бу нөсхә, сакланган булса, хәзер Төркиядә булырга тиеш.

Җыеп әйткәндә, Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә дастаны» гуманистик идеяләр белән сугарылган, антифеодаль характердагы дөньяви бер әсәр. Ул үзенең идея тирәнлеге, мифологик

сюжеттан файдаланудагы үзенчәлекләре ягыннан Дантеның «Илаһи комедиясе» белән бер рәткә куеп каралырга тиеш.

Билгеле булганча, Илаһи комедиядә дини-аллегорик һәм мистик образлар шактый көчле. «Җөмҗөмә дастаны», дини рухта язылган булуына карамастан, мистикадан ерак. Данте, тәмуг образы белән беррәттән, җәннәт образын да тасвирлый. Дөрес, бу образ аркылы ул гуманистик идеяләр үткәрә. Ләкин, шул ук вакытта, оҗмах образы аркылы Дантеның феодализм вәкилләре арасыннан уңай образлар табарга омтылганын да инкарь итеп булмый. Хисам Кятиб исә феодаллар арасында андый уңай образларны күрмәгән һәм аларны тудырып та маташмаган. Чөнки алар реаль тормышта булмаган. Бу исә Хисам Кятибнең чынбарлыкны сиземләү көче Дантега караганда көчлерәк булганын күрсәтә.

Башкача әйткәндә, реализмның көчлелеге белән «Җөмҗөмә дастаны» «Илаһи комедия»дән өстен.

Кыскасы, «Җөмҗөмә дастаны» татар әдәбияты һәм әдәби теле тарихында өйрәнелергә тиешле әсәр. Аның хакында укучы үзе тиешле хөкем чыгарсын өчен дастан тулы килеш югарыда телгә алынган биш нөсхәне берләштереп, хәзерге татар теленә күчерелде. Тәрҗемә иткәндә мөмкин кадәр текстка якын булу максаты куелды. Кайбер урыннарда исә текстның, формасыннан элек, мәгънәсен бирү күздә тотылды. Бер урында, Җөмҗөмәне тәмугта сөйрәп йөрткәндә, зәбанилар тарафыннан Җөмҗөмәгә карата әйтелгән сүзләр нөсхәләрдә бозып бирелгән. Шуңа күрә алардан ике төрле мәгънә аңлашыла. Мәсәлән, Җөмҗөмә халыкны ашаткан булса да, тәмугта җәзалана, дип аңларга мөмкин. Җөмҗөмәнең үлеменә сәбәп – бер ярлыга ярдәм итмәү булганын күздә тотсак, болай аңлау дөрес кебек күренә. Ләкин ул дастанның гомуми локикасына туры килеп җитми. Шуңа күрә Санкт-Петербург нөсхәсендәге «нигъмәт халык ашады» дигән сүзләрне «нигъмәте халаек ашады» дип уку дөресрәк булыр, дип уйлыйм. Болай укыганда Җөмҗөмә халыкныкын ашаган булып чыга. Халыкны ашату исә аны ныграк талар өчен бер сылтау гына булып кала. Шуннан чыгып, бу нөсхәләрдәге буталчык ике юлны:

*Мин халыкны ашатам, дигән*
*булып,*
*Тиресен биш кат аның алды*
*суеп,*

дигән юллар белән логик тәрҗемә итү дөресрәк булыр дип уйладым. Борынгырак нөсхәләр табылса, бу төзәтелергә тиеш.

Кыскасы, дастанның бу тәрҗемәсе шигъри һәм мәгънәви тәрҗемә. Анда нигездә дастанның рухын, идеясен, теленең образлылыгын һәм шагыйрьнең үзе яшәп торган чынбарлыкны чагылдырудагы осталыгын укучыга җиткерү максат итеп куелды. Дастанның тәнкыйди тексты белән фәнни тәрҗемәсе әзерләнә. Аны бастырып чыгару якын киләчәкнең эше.

**Әдәбият**

Татар әдәбияты тарихы: Урта гасырлар дәвере. Казан: Татар кит. нәшр., 1984.

*Исламов Р.Ф.* Алтын Урда һәм Мәмлүкләр Мисыры: язма мирасы, мәдәни багланышлар. Казан: Матбугат йорты., 1998.

*Әхмәтҗанов М.* «Җөмҗөмә дастаны» тәрҗемәсе // Әдәби мирас җыентыгы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Өченче китап.

*Бертельс Е.* Литература народов Средний Азии // Новый мир. 1939. № 9.

*Нәҗип Ә.* XIV йөз шагыйре Сәйф Сараи һәм аның заманы // Совет әдәбияты. 1957. № 4.

Диалектологик сүзлек. Казан, 1948.

*Дмитриева Л.В.* Тюркские рукописи института востоковедения АН СССР // Проблемы востоковедения. 1959. № 4.

***Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы,*** *филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145'35

*Г. Шәрәф*

# БЕРЕНЧЕ БУЫН (ИҖЕКТӘГЕ) «О», «Ө» АВАЗЛАРЫНЫҢ ҮЗЕННӘН СОҢГЫ АВАЗЛАРГА ТӘЭСИРЕ ҺӘМ БУ ТӘЭСИРНЕ ЯЗУДА КҮРСӘТҮ-КҮРСӘТМӘҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

Предлагаемая вашему вниманию статья Галимзяна Шарафа посвящена вопросам татарской орфографии на основе арабской письменности и выполнена из оттиска, хранящегося в Центре письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (ф. 20, оп. 1, ед. хр. 36).

**Ключевые слова:** Галимзян Шараф, орфография татарского языка, арабская письменность, гласные звуки, согласные звуки.

«Ө», «о» авазлары «у» авазы шикелле иреннең катнашы белән әйтелә торган авазлардандыр. Бу авазлар, бер яктан, телнең торышы белән аерылсалар, икенче яктан иреннең торышы белән аерылалар: «о» – «ө»не әйткәндә иреннәр күбрәк ачыла һәм кимрәк алга чыга. «У»да иреннәр арасындагы ачыклык «о» га караганда кимрәк, иреннәрнең алга чыгуы артыграк була.

Калын «о» белән нечкә «ө» авазы телнең торышы белән генә аерылалар. Иреннең торышы икәвендә дә бер төсле. «Ө» – «о» авазлары ачык булып беренче буын иҗектә генә ишетелә. Бу кагыйдә, ягъни «о», «ө»нең беренче буында гына булуы татарчада шундый нык утырган кагыйдәләрдән, хәтта кушма сүзләрнең берегеп бер сүз булып киткәннәрендә дә сүзнең төбендә булган «о», «ө»ләрнең дә «е» («э») гә әйләнгәнен күрәбез. «Бу көн»дән ясалган «бүген», «ак-кош»тан ясалган «аккош», «кар-боз»дан ясалган «карбыз» сүзләрендә икенче иҗекләргә туры килгән «о», «ө» ләрнең «ы», «э» авазына әйләнүен күрәбез.

Бу «о» үзеннән соң килгән һәммә авазга диярлек тәэсир итә. Аларның мәхрәҗен (әйтелешен) үз мәхрәҗенә таба тарта. Бу тәэсир һәммә гласныйларга булган кебек, согласныйларның да кайберләренә булуы сизелә. Бу сүзләрдән беренче иҗек кенә «о» авазы булмаган сүзләр морад; беренче иҗегендә «о» булган сүзләр алда аерым каралалар.

**«Ы» – «э»гә тәэсире** – бардым, бәрдем, булдым, бөлдем сүзләрендә «д» белән «м» арасында ишетелгән ы-э авазы, тордм, бордм, төрдм, бөлдм, тордыгз кеби беренче иҗегендә «о» – «ө» булган сүзләрдә «о» – «ө»гә якынаеп «тордом, бордом, төрдөм, бөлдөм, тордогоз» дигән шикеллерәк итеп сөйләнә. Гомумән, беренче иҗегендә «о» – «ө» булган сүзләрнең соңгы иҗекләрендәге «ы» – «э» ләре берникадәр «о» – «ө» гә якыная төшәләр.

**Башка гласныйларга тәэсире.** «О» – «ө» бер «ы» – «э»

сузыкларына гына тәэсир итми – башка гласныйларга да тәэсир итә. Татар, ата, томан, кара сүзләрендәге «а» лар белән тотар, отар, томан, томау, корал сүзләрендәге «а» лар бер төрле әйтелмиләр. Соңгы «а» лар урыс «о» сына якынрак аваз белән әйтеләләр (тәтә, этәч), (тетя) көтәм дигән сүзләрне чагыштырып карасак, беренче иҗектә «о, ө» булган сүзләрдә «ә» нең икенче төрлерәк «ө»ләшеп әйтелгәнен күрәбез. («У»га тәэсире турысында алда.)

**Согласныйларга тәэсире** – бу аваз үзеннән соңгы согласныйларга да берникадәр тәэсир итә: каш, кош, кар, кор дигән сүзләрдәге «ш, р» авазларына әһәмият биреп тыңласак, боларның ишетелүләрендә һәм мәхрәҗләрендә (әйтелешләрендә) (иреннең торышы ягыннан) аерма булуын күрербез.

Бу тәэсирнең сәбәбенә килгәндә, бу тәэсир ирен тирәсендәге мышца (мускул) (ит һәм сеңерләрнең) «о» авазын әйткәндә иткән хезмәтләрен, аннан соңгы авазларны әйткәндә дә дәвам иттерүләреннән гыйбарәттер. «О–ө» не әйткәндә иреннәрнең кырыйларын бер-беренә якынайта торган мышцалар, шулай ук иреннең уртасын ача торган мышцалар «о–ө» не әйткәндә иткән хезмәтләрен аннан соңгы авазларны әйткәндә дә дәвам иттерәләр һәм шуның аркасында «о–ө» дән соңгы иҗекләрдәге «ы, е, а, ә, р, ш» ләрнең мәхрәҗе башка әгъзаларның (мәсәлән, тел, аңкау) мөнәсәбәте ягыннан гади торышта калса да, иреннең торышы ягыннан берникадәр үзгәрә, колакка ишетелүе дә башкара төшә.

Бу тәэсир, ягъни авазның мәхрәҗе-ишетелүе, башкаруы төрле авазларга төрлечә була.

Гласный авазлар өчен иреннең торышы согласныйларга караганда әһәмиятлерәк булганга, гласныйларда без «о–ө» нең тәэсирен ныграк сизәбез, гласныйларда һәммәсенә бердәй түгел.

Гласныйлар арасында үзе кыска, мәхрәҗе ачык булмаган саңгыраурак гласныйларда бу тәэсир тагын да ныграк сизелә: «э, ы» авазы татарчадагы гласный авазларның иң кыскасы, иң билгесез (индеферентный) мәхрәҗлесе булганга, «ө» нең тәэсире бу авазда иң көчле рәвештә сизелә. Кайбер урыннарда (мәсәлән: өчен, очын, кошым, котым, төсем кеби, беренче иҗеге ачык иҗек булып, икенче иҗеге ябык булган сүзләрнең икенче иҗекләрендә) бу тәэсир шулчаклы көчле була ки, хәтта болардагы икенче иҗектәге гласный «е, э» га караганда «о, ө» гә артыграк ошый.

Бу урыннардагы асыл аваз «ы, э» икәнен дә (чәчм, бышм, чәчн, кеби башка сүзләрнең шул ук сыйгалары белән чагыштырып һәм сүзләрнең тарихына карап кына беләбез.

Ләкин һәрхәлдә бу урыннардагы аваз «о» авазына якын булса да «о» авазы ук түгел. Мәсәлән: хотм дигән сүзне алдан «котом» дип икенче иҗектә ачык «о» белән әйтеп, аннан соң котым дип ачык «ы» белән әйтеп, шуларны гади «котм» белән чагыштырып карасак, бигрәк тә һәр өчәвен дә икенче иҗектәге гласныйны сузыбрак әйтсәк, гади «котм» да «к» дан соң ишетелгән авазның «о» да, «ы» да булмаган, ике арадагы бер аваз икәнен күрербез.

Татар телендә, гомумән, ябык иҗекләрдәге гласныйлар ачык иҗектәгеләргә караганда озынрак ишетелә һәм мәхрәҗләре дә билгелерәк була. Шуңа күрә ачык

иҗектәге гласныйларга, беренче иҗектәге «о, ө» ләрнең тәэсире шул ук авазның ябык иҗектәгеләренә караганда кимрәк була (түтә – төтәп, тотам, томау, өчө, очн) сүзләрендәге шикелле, гомумән дә, гласный аваз ни чаклы кыска әйтелсә, «о» ның тәэсире шул чаклы куәтлерәк була. Мәсәлән: тору, тору сүзләрендә «у» ның актыктагы у тәэсире бик аз, әмма торууы – торуы дигән сүзләрдәге «р» дән соңгы иҗек ясый торган, «вау» ның кыска сөйләнеп тәмам «у» мәхрәҗен алып та өлгермәгәнгә бу урында «о» ның тәэсире бик көчле рәвештә сизелә: торуы, йөрүе дигән шикеллерәк ишетелә (ләкин боларда һаман «о – ө» түгел, монда «баруүы», «бәрүүе» сүзләре

Татар телендәге гласныйларның озынлыгы турысындагы экспериментальный фонетика приборлары белән тәҗрибәләр (бер иҗекле сүзләрдә гласныйның озынлыгын үлчәү түбәндәге нәтиҗәләрне бирде: татар телендәге иң озын (озак әйтелә торган) авазлар: у, ү, а.

Уртача озынлыктагылары: и, ый.

Иң кыскалары: о, ө, ы, э. Бу авазлар озынлык тәртипләре белән язылдылар. бер үк авазларның ачык иҗектә дә, ябык иҗектә дә тикшерелгәннәре, ачык иҗекләрдә гласныйның дәвамы ябык иҗекләрдәгегә караганда ике өлеш чамасы артык икәнен күрсәтте.

Чагыштырып карап белергә мөмкин: «о» ның гласныйларга тәэсире иң көчлесе икенче иҗектә була. Өченче, дүртенче иҗекләргә киткән саен бу тәэсир кими. Арага ябык иҗекләр дә керсә, тәэсир тагын кими төшә: төр, төрле, төрп, төрдм, тордрдм, тордрйде сүзләрендә моны чагыштырып карарга мөмкин. Арага «А – ә», «о – ө», «ый – и» кеби ачык мәхрәҗле гласныйлар керүе тәэсирен бетерү дәрәҗәсенә җиткерә: коралы, корулы, төрлесе, төрлисе сүзләренең актыккы авазларыннан моны чагыштырып белергә мөмкин.

Кайбер гласныйларда (бигрәк тә иреннең катышы белән әйтелә торганнары, ягъни «о» – «ө» не ясалгандагы мышцаларга икенче хезмәт йөкләтә торганнары) «о – ө» нең тәэсирен киметәләр: төбе, төбегезне, өфе, өфенеке сүзләрендәге «э – ө» авазлары беренче иҗектәге «ө» нең тәэсирен киметәләр.

Ирен белән әйтелә торган сузыкларның үзеннән соңгы авазларга тәэсирен фәндә лабиализация (губная ассимиляция – иренләштерү) диләр. Иренләштерү бер татар теленә махсус сыйфат түгел; башка төрек телләрендә дә бар: бездә «о – ө» авазы гына иренләштерә, башка төрек телләренең кайберләрендә, мәсәлән, госманлычада һәм кыргызчада бу тәэсир безнең «о – ө» тугрысындагы авазларда гына түгел, безнең «о» тугрысындагы авазларда да бар. Мәсәлән: күзм, йулм сүзләре аларда күзөм, йүлөм шикеллерәк сөйләнә.

Иренләштерү төрек телләрендә искедән булуы күренә. Моны чыгтай имлясы күрсәтеп торганы кебек орхон язуларында да төрлечә язылалар. Мәсәлән, Күлтәгин ташының беренче юлында торосен, 13 нче юлында шул ук сүз «торосон» сурәтендә, 3 нче юлында өчөн, тутп рәвешендә язылалар. Иренләштерү тәэсиренең булуын һәм бу урындагы беренче иҗекнең тәэсире астында ясалган авазларның, «о» да, «ы» да булмый, ике арадагы авазлар булганын күрсәтә.

Инде беренче аваздагы «о»ларның тәэсирен язуда күрсәтү мәсьәләсенә килик. Алдан башка төрк телләрендә мәсьәләнең куелышын карыйк.

Орхон язмаларында югарыда күрсәтелгәнчә иренләштерү тәэсирен күрсәтүдә билгеле бер әсас тотылмаган: Чыгтай имлясының иң төпле һәм последовательный (эзлекле) булганы Нәваи имлясында да бу мәсьәләдә билгеле бер юл тотылмаган (тордм, тордк, торды, тордылар, түшде, түшлик) сүзләре «турдум, турдук, турды, турдилар, түште, түшлик» рәвешендә язылып, «о» тәэсире белән үзгәргән урыннарда бәгъзан вау, бәгъзан йа белән язганнар. Госманлыларның хәзергә чаклы язып килгән имляларында күбесенчә бу тәэсир күрсәтелми: торды, тордыгм сүзләре: турды, турдигм (турдгм) сурәтендә языла. Яңа имлячылары бәгъзан күрсәтәләр, бәгъзан юк. Кыргызларның хәзер кабул иткән һәм һәммә мәктәп китапларында вә гәзитләрендә кабул ителгән имляларында иренләштерү тәэсире язуда күрсәтелми: өчн, тотп, көзге сүзләре үчн, тотп, көзге рәвешендә языла.

Ориенталистлар – тюркологлар иренләштерү тәэсирен язуда бик куәтле рәвештә, хәтта бу тәэсир телдә булмаган урыннарда да күрсәтәләр (гомумән, фикеремчә, төрк телләрендә иренләштерү мәсьәләсен тюркологлар өчен яңадан карап чыгарга һәм бу мәсьәләдә төплерәк әсаслар куярга ихтыяҗ бар). татар телен академия транскрипциясе белән язганда тюркологлар «о – ө» артындагы һәммә «ы» лар урынына «о – ө» язалар: төрде, төрдм, төргздм сүзләрен төрдө, төрдөм, төргөздөм язалар; «о – ө» нең (а – ә) ләргә тәэсирен дә язуда күрсәтәләр: моның өчен астында о хәрефе булган а, ягъни аерым галәмәт истигъмал итәләр; «о» артындагы «а – ә» ләр өчен дә аерым галәмәтләре бар. «О» (ۇ) ның башка гласный һәм согласныйларга тәэсирен язуда күрсәтмиләр.

Хәзерге көрәш имлясында шул тюркологларның тәэсире белән булса кирәк, «о» ның үзеннән соңгы «ы» ларга тәэсире. Боларның һәммәсе урнына «о» язу ысулы белән күрсәтелә, башка гласныйларга тәэсирен алар язуда күрсәтмиләр.

Татар язуында «о» ның тәэсире бәгъзан (үзеннән соңгы «ы», «э» ләр урынына өчөн, болот, толоп дигән сүзләрдәге кеби) күрсәтәләр, бәгъзан торды, тордм, озңборн, борнгы дигәндәге шикелле күрсәтелми. Мондый урыннарда кайда «о», кайда «ы» язу турысында әлегә кадәр куелган бер кагыйдә юк, тәкъдим иткән кеше дә минем күземә чалынганы юк.

Имлячыларыбыздан Гыймад Нугайбәк, Мөхетдин Корбангалиев, Шакирҗан Таһири кеби авазларга бик әһәмият бирүчеләр дә, басылган әсәрләренә караганда, бер билгеле юлдан бармаганнар, төрле вакытта төрлечә язганнар.

Нинди дә булса бертөрле имля утыра алсын өчен, бу мәсьәләдә, бер юл белән хәлителергә, хәтердә калдыруы җиңел булган кагыйдәләр астына алынырга шиксез тиеш.

Мин үзем бу мәсьәләне хәл итү өчен бик әсаслы, бик мантыйкый юл, бу тәэсирне гади истигъмал өчен булган язу – имляда күрсәтмәү (ягъни бу урыннарда хәрфе морфология әсасыннан караганда шул ук сыйгадагы башка сүзләр белән чагыштырганда),

нинди авазлар булырга тиеш булса, шул авазларны язу ягындамын. Сәбәпләр:

1. Беренче иҗектәге «о»ның үзеннән соңгы «ы – э» һәм башка гласный вә согласныйларга тәэсире сыймагы булмаенча, мәхрәҗе (физиологический) сәбәбләрдән булганга һәм бу тәэсир беренче иҗегендә «о – ө» булган һәммә сүзләр өчен гомуми булганга, бу тәэсирне язуда күрсәтергә ихтыяҗ юк: тәэсир мәхрәҗе сәбәбләрдән булганга укуга бераз мәләкәләнгән татар баласы «о» артыннан килгән «ы»ларны саф «ы» рәвешендә укый да алмый. Ул теләсә дә, теләмәсә дә бу авазны ике арадагы күчмә (переходный) аваз итеп укый. Башка авазларның да тәэсире булган урыннарда булган кадәрлесен теләсә дә, теләмәсә дә ясарга мәҗбүр. Әмма бу тәэсирне сознательный ясарга һәм белдерергә кирәк булганда (мәсәлән, ят тел кешеләрен татарча укытканда) аның язуда күрсәтелүенә һич тә ихтыяҗ юк. Ул вакытта бу тәэсир татар теленең тәҗвит кагыйдәләреннән берсе ителеп кенә өйрәтелергә тиеш.

2. Бу тәэсир югарыда күрсәтелгәнчә һәммә сузыкларга, хәтта тартыкларга да бар һәм төрлесенә төрлечә. Тәэсир, авазның ничәнче иҗегендә һәм нинди иҗекләрдән соң булуына да карый. Гомумән, тәэсир үзгәрә торган – иррациональный. Шуңа күрә бу тәэсирне язуда аерым ачык күрсәтергә мөмкин дә түгел.

3. Бу тәэсирне кайберәүләр күрсәткәнчә «ы – э» тугрысында гына күрсәтеп, башкаларга тәэсирен күрсәтмәү мантыйксызлык (непоследовательность) булачак. «О – ө» нең, «ы – э» ләргә тәэсирен күрсәтү өчен һәммә урыннарда, «о – ө» язу үзе әсассыз тәкъдим. Чөнки урыннардагы аваз, югарыда күрсәтелгәнчә, «о» авазы түгел, «ы» белән «о» арасындагы бәгъзан «өчн» дигәндәге кеби «ө»гә бәгъзан «өфенеке төпсезлек» дигәндәге кеби «э» гә якынрак аваз (бәгъзан кайсына якынрак икәнен дә билгеләве авыр). Шуңа күрә ишетелгәнчә язу әсасыннан «о» артындагы һәммә «ы – э» ләр өчен «ىٚ» язуны тәрҗих итүгә гомуми әсас юк, үзгәрә торган аваз булганга өченче бер хәреф алып һәммә урыннарда язуга да әсас юк.

4. Әлегә чаклы булган язуыбызда торды, төрле, корды, көзге, колы, колм кеби сүзләрнең күбрәгендә «ы» (шул тавышка йөргән «и») язылып килгән. Очон, озон, толоп кеби бик аз сүзләрдә генә «о» язылган. Шуңа күрә бу тәэсирне күрсәтмәү хәзергә кадәр булган язуга якынрак; ягъни бу юл бер төслелек кертү өчен ватуны азрак ясаячак.

5. «О» ның үзеннән соңгы иҗекләргә тәэсирен язуда күрсәтү сыйгаларның берлеге (морфологический якынлыкның) язуда күренеп торуын бетерәчәк шуның белән үк һәм аңлауны авырайтачак.

Уку агымын (процесс чтенияне) тикшерү күрсәтә ки, укуга берникадәр мәләкәләнгән (грамотный) кеше укыганда һәрбер хәрефне йә һәр иҗекне укып җыеп бармый. Сүзнең әсас кисәкләренең гомуми сурәтен, бөтен сүзне, хәтта кечерәк сүзләрдә берничәсен бергә күзенә алып укып бара. Мәсәлән: «сөйләнсә дә» дигән сүзне укыганда без: «сөй-лә-нсә дә», сөйлән-сә-дә, сөйләнсә дә рәвешләрендә бөтен сүзне авазларга бүлми, аны аерым мәгънә аңлаткан әсас кисәкләргә генә бүләбез. Сөй (шәкл, хәрефләре) башыбызда

«сүз» понятиесе аңарга «лә» шәкле арттырылуы клк (фигыль) мәгънәсен «э» мәҗһуллек мәгънәсен арттыра вә сөйләм кисәге бөтенесе бергә алынганда, сүз «сөй» гә мөнәсәбәтле бер фигыль мәҗһүлне аңлата: «сә» – шәкеле шарт мәгънәсен, «дә» гатф мәгънәсен башыбызга китерә һәм мидә шул шәкелләрнең тудырган мәгънәләре бергә вә шул тәртиптә җыелуы «сөйләнсә дә» сүзенең бөтен мәгънәсен уегызга китерә. Укыганда без күбесенчә сүзнең нинди авазлардан төзелүенә һәм нинди хәрефләр белән язылуына әһәмият тә бирмибез. Тик билгеле мәгънә аңлата торган кисәкләрнең, мәсәлән, сөйлән-сә-дә кисәкләренең генә гомуми шәкелен тотып алабыз. Хәтта эчтән (тавышсыз) укыганда авазларның бөтенләй диярлек әһәмиятләре бетә. Без шәкелләрдән мәгънәләрен генә укып барабыз.

Уку агымын югарыда күрсәткәнчә тәхлил, безгә сүзнең бер мәгънәгә дәләләт иткән аерым кисәкләре мөмкин кадәр бер төрле, бер шәкелдә язылуы укуны сүзләрнең шәкелләреннән мәгънә аңлап баруны җиңеләйтүен күрсәтә.

Очн, очды, очдыңмни сүзләрен алсак, алар түбәндәге кисәкләренә аерылалар: оч, (ы) н; оч, ды; оч, дыг, (ы) мни. Мозаф һәм мәфгулн иләиһи сыйгасын белдерү өчен булган (ы)н ялгауының башк, угн, кулн, очн кеби һәммә сүзләрдә бер төрле язылуы, үткән чак, гаеп сыйгасының белдерү өчен булган «эл – ыл» мәфгул адате «ни» ялгаулары бер төрле язылуы укуны-аңлауны җиңеләйтә. Шуңа күрә башка әһәмиятле сәбәбләр булмаганда бер сыйга ялгаулары бер төрле, мәсәлән, югарыдагы мисалларда һәммәсендә (ы) белән язылырга тиеш (хәзерге рус имлясы бөтенләе диярлек нимс һәм француз имлялары күбесенчә шул әсаска корылган. Бу әсасны фәндә сарфы этимологический (морфологический) әсас дип атыйлар.

Бу грамотный (укуга бернИкадәр мәләкә хасил иткән) кешенең уку агымы яңа өйрәнүченең уку агымыннан башкачарак. Тәгълим вә тәрбия фәнен яңа өйрәнүчеләрне дә (мәсәлән, балаларны) мөмкин кадәр югарыда күрсәтелгән уку агымына тизрәк күнектерүне, шуңа өйрәтүне идеал итеп тоту.

6. Без имлябызга әсас салганда мөмкин кадәр шул әсасларның башка төрк телләре өчен дә кабул ителүен һәм шуның аркасында язуларның ераклашмый, якыная баруын, бер-беренең әдәбияты белән файдалану җиңеләюен күз алдында тотып эшләргә тиешбез (билгеле бу якынайтырга тырышу билгеле чиккә – уку-язуның гавамлашуына зарар китерә башлау дәрәҗәсенә җитмәскә тиеш).

Югарыда күрсәтелгәнчә, иренләштерү тәэсире төрле төрк телләрендә бер төрле түгел. Без дә һич диярлек иренләштерелми торган тугз, сүзм, тунм, утн сүзләрендәге «о – ө» авазы кыргызчада, госманлычада (һәм башка төрк телләренең күбесендә) туқоз (дуқоз, туғоз) сузом, туном, утон (удон) шикеллерәк сөйләнә. Тюркологлар бу сүзләрне токуз, одун, отун, докуз, тонум сурәтендә язалар да. Кыргызлар үзләренең яңа имляларында (гәзитләре һәм мәктәп китаплары өчен гомуми уларак кабул ителгән вә хәяткә кертелгән имляларны да) бу иренләштерү тәэсирен язуда күрсәтмиләр. Бу мәсьәләдә төрк телләренең язуда-имляда якынлыгын

саклау өчен мин безгә дә кыргызлар күрсәткән юлдан китеп, иренләштерү тәэсирен күрсәтмәү яхшы булыр дип исәплим. Без бу мәсьәләдә кыргызлар белән бер юлдан китсәк, бәлки башка төркләр дә безнең юлдан китәрләр.

Югарыдагы әсаслардан, бигрәк тә баштарак китерелгән әсасларда мин «о – ө» (وُ – وُ) авазларының үзеннән соңгы авазларга тәэсирен язуда һич бер төрле күрсәтмәскә, бу урыннарда сыйгалар морфология әсасыннан караганда нинди авазлар булырга тиеш булса, шул авазларны бар дип исәпләргә һәм язылa торганнарын язарга тәкдим итәм. Бу әсас гамәлдә «وُ» «о – ө» хәрефе беренче иҗектә генә язылыр дигән кагыйдәгә килеп чыга.

Үзләренең яңа имляларында (гәзитләре, мәктәп китаплары өчен гомуми буларак кабул ителгән вә хаятка кертелгән имляларында) бу иренләштерү тәэсирен язуда күрсәтмиләр. Бу мәсьәләдә төрек телләренең язуда – имля якынлыгын саклау өчен, мин, безгә дә кыргызлар күрсәткән юлдан китеп иренләштерү тәэсирен күрсәтмәү яхшы булыр, дип исәплим. Без бу мәсьәләдә кыргызлар белән бер җирдән (эздән) китсәк, бәлки башка төрекләр дә, безнең юлдан китәрләр.

Югарыдагы әсаслардан, бигрәк тә баштарак китерелгән әсасларда, мин «о – ө» авазларының үзеннән соңгы авазларга тәэсирен язуда һич бертөрле күрсәтмәскә, бу урыннарда сыйгалар – морфология әсасыннан караганда нинди авазлар булырга тиеш булса, шул авазларны бар дип исәпләргә һәм язылa торганнарын язарга тәкъдим итәм. Бу әсас гамәлдә «о» хәрефе беренче иҗектә генә язылыр дигән кагыйдәгә килеп чыга.

*Басмага әзерләде:* ***Асылгәрәев Шәрифҗан Нурлыгәрәй улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 37

*А.В. Әхтәмова*

# ПЕДАГОГИК ТИКШЕРЕНҮ ҮЗӘКЛӘРЕ (1960–1970 ЕЛЛАР)

В статье рассматривается деятельность педагогических научно-исследовательских центров, общественной научно-педагогической организации ТАССР в 1960–1970-х годах, выделяются их основные научные направления, показывается вклад татарстанских ученых и передовых учителей в развитие советской педагогики. Автор уделяет внимание вопросам национального образования.

**Ключевые слова:** педагогика, национальная школа, вуз, научно-исследовательский институт, ТАССР.

Татар халкының гасырлар буена тупланган бай педагогик фикере бар. Әлбәттә, җәмгыять үсешендә татар мәгарифенең милли үзенчәлеген саклап калу татар зыялылары өчен төп бурыч булып тора. XX йөзнең икенче яртысында Казан галимнәре гомумпедагогика үсешенә зур өлеш кертә. ТАССР башкаласы Казан шәһәре узган гасырның алтмышынчы еллар башына бөтенсоюз күләмендә педагогика өлкәсендәге фәнни-тикшеренү эшләренең үзәгенә әверелә. Биредә галимнәрнең һәм алдынгы укытучыларның педагогик эш тәҗрибәсе төрле юнәлешләрдә алып барыла. Мәкаләдә 1960–1970 елларда Татарстанда гамәлдә булган педагогик тикшеренү үзәкләренең [Мәхмүтов] фәнни эзләнүләренә кыскача күзәтү ясала.

Өйрәнелә торган дәвердә Казан дәүләт педагогия институты галимнәре, гомуми белем бирү мәктәпләре өчен яшь педагоглар әзерләү белән беррәттән, Татарстанда педагогика фәнен үстерүгә дә әһәмиятле өлеш кертә. Укучыларның танып белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерү, проблемалы укыту, укучылар белән индивидуаль эшләү, татар мәктәбендә рус теленә өйрәтүнең эчтәлеге һәм методикасы, татар халык педагогикасы тарихы, авыл мәктәпләрендә укыту-тәрбия процессын оештыру үзенчәлекләре, яңа совет мәктәбе нәзари мәсьәләләренә аеруча игътибар бирелә. 1969–1990 елларда педагогика кафедрасы мөдире вазифасын күренекле галим-педагог Якуб Исхак улы Ханбиков башкара, һәм кафедра тиз арада педагогика-психология өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләрен координацияләү үзәгенә әверелә [Садыйков, б. 79].

В.И. Ульянов-Ленин исем. Казан дәүләт университеты педагогика үсешендә аеруча әһәмиятле урын били. Кайбер мәгълүматларга караганда, бу югары уку йортында татар телен укыту 1928 елның көзеннән ук кертелә (мәсәлән, совет хокукы факультетында) [Сегаль]. 1944 елда филология факультетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылганнан соң, бу фәннәрне укыту методикасы өлкәсендә эшләүче белгечләрнең саны республикада тагын да арта. Бүлекне оештыруга ифрат зур көч куючы Рабига Афзал кызы Хәкимова татар теле

һәм әдәбияты кафедрасының мөдире итеп билгеләнә. Төрле елларда кафедра җитәкчесе булып Х.У. Усманов, М.З. Зәкиев, Д.Г. Тумашева эшли. 1970 елларда татар теле кафедрасы хезмәткәрләре «Татар әдәби теле үсешенең закончалыгын өйрәнү» темасы буенча фәнни-эзләнү эше алып баралар [Казанский..., с. 15], дистәләгән гыйльми хезмәтләр, дәреслекләр язалар.

Алабуга дәүләт педагогия институтында тәрбияви мәсьәләләр күтәрелә. Педагогика һәм психология кафедрасы (җитәкчесе З.С. Әхмәрев) пионерия хәрәкәте, укучыларны интернациональ рухта тәрбияләү, атеистик тәрбия, коммунистик әдәп мәсьәләләре буенча фәнни тикшеренүләр үткәрә [ТР МА, б. 6–8]. 1961 елда татар мәктәпләре өчен рус теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерли торган бүлек ачыла. 1959 елда ачылган «Башлангыч белем бирү методикасы һәм педагогика» факультеты 1979 елда Яр Чаллы шәһәренә күчерелә [Елабужский..., с. 9, 54].

Югары уку йортларыннан тыш, фәнни-тикшеренү институтларының эшчәнлеген шәрехләү мөһим. Автономияле республикаларда мондый үзәкләр РСФСР Педагогия фәннәре академиясе Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының филиаллары формасында алтмышынчы еллар башында ачыла. Аерым алганда, Милли мәктәпләр институтының филиаллары Татарстанда, Башкортстанда, Дагстанда, Якутиядә була, һәм алар арасында тыгыз элемтә урнаша. Институт үзенең эшчәнлеген милли республикадагы күпсанлы терәк мәктәпләргә таянып алып бара.

РСФСР Педагогия фәннәре академиясе (1977 елдан РСФСР Мәгариф министрлыгы) Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының Татарстан филиалы Казанда 1961 елда оештырыла. Филиал Казан шәһәренең 35 нче мәктәбе бинасында урнаша (бүгенге көндә Казан шәһәре, Вахитов районының 1 нче номерлы татар гимназиясе), аның методик лабораториясе буларак Буа районы, Иске-Суыксу сигезьеллык мәктәбе сайлана. Беренче мөдире итеп милли мәктәпләрдә рус теле укыту методикасы өлкәсендә эшләүче иң зур белгечләрнең берсе – Лия Закир кызы Шакирова билгеләнә, ә 1963 елның апреленнән бу вазифаны 1984 елга кадәр Гөлсем Азиз кызы Жданова башкара.

Кадрлар мәсьәләсенә килгәндә, филиал эшчәнлегенең башлангыч чорында, мөдир вазыйфасыннан тыш, алты фәнни хезмәткәр исәпләнә (ө.ф.х. З.М. Вәлиуллина, Н.М. Хәсәнев; к.ф.х. А.А. Михеева, А.Х. Нуриева, М.З. Әхъярова, А.Г. Әминев). Алдагы ун ел эчендә кадрлар составы бераз үзгәреш кичерә, шул исәптән күләм ягыннан да – барысы 14 штат берәмлеге карала [ТР МА, б. 6, 10]. Институтның штаттан тыш фәнни хезмәткәрләре саны 49га җитә (югары уку йортлары педагоглары, ТАССР Мәгариф министрлыгы, Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләре, Татарстан укытучыларының белемен күтәрү институтының методистлары һ.б).

Филиал эшчәнлегенең төп юнәлеше милли мәктәпкә караган гомуми педагогик мәсьәләләрне һәм татар мәктәпләрендә, беренче нәүбәттә, рус һәм ана телләрен, шулай ук әдәбиятларын укытуның эчтәлеген һәм методикасын билгеләүдән, республикадагы мәгариф һәм фәнни-педагогик

учрежденияләргә, методистларга ярдәм итүдән гыйбарәт була. Биредә укыту барышында ана һәм рус телләренең үзара йогынтысы мәсьәләләре дә тикшерелә [Жданова, б. 53–54]. Әлеге фәнни оешманың хасияте, әлбәттә, аның мәктәпләр белән тыгыз бәйләнешендә чагыла. Чыннан да, фәнни хезмәткәрләр байтак вакытларын филиалның терәк мәктәпләрендә (Казан шәһәренең 35 нче мәктәбе, Буа районының Наратбаш сигезьеллык мәктәбе, ул вакыттагы Арча районының Әтнә сигезьеллык һәм урта мәктәпләре) фәнни-тикшерену эшләренә багышлыйлар. Бердәм иҗат итү мәсьәләне төрле яссылыктан өйрәнү мөмкинлеге бирә, үз нәүбәтендә укытучыларга да алдынгы тәҗрибәләрен гомумиләштерергә ярдәм итә. Әйтик, Казандагы 35 нче мәктәп укытучылары (Х. Бермелеева, А. Хәбибуллина, С. Урманова, Ф. Хәлиуллина һ.б.), 91 нче мәктәп укытучысы Ш. Шәмсетдинова, пенсионер методист Е.Яхонтова кулъязмаларны дәреслек итеп әзерләүдә дә актив катнашалар, аларның күпчелеге штаттан тыш фәнни хезмәткәр булып исәпләнә. Шунысын да искәртик, 1961/1962 уку елыннан филиалның терәк мәктәбе – Казанның 35 нче мәктәбе – инглиз телен тирәнтен өйрәтүгә күчә: инглиз теле сәгатьләре туган тел сәгатьләрен киметү хисабына кертелә [ТР МА, б. 11].

1969 елда РСФСР Педагогия фәннәре академиясе Милли мәктәпләр фәнни-тикшерену институтының Татарстан филиалы хезмәткәрләре РСФСР Педагогия җәмгыятенең Татар бүлеге әгъзалары составына кабул ителә [ТР МА, б. 1]. Әлеге педагогия җәмгыяте, яшьләрне уку-укыту һәм тәрбияләү мәсьәләләрен хәл итү максатыннан, республика күләмендә галим-педагогларны, укытучыларны, тәрбиячеләрне берләштерүгә бинһая зур өлеш кертә. 1960 елда барлыкка килгән иҗтимагый оешма кысаларында 9 секция (эстетик тәрбия, дидактика, мәктәпкәчә тәрбия, атеистик тәрбия, кичке һәм читтән торып укыту, гаилә тәрбиясе, интернат-мәктәпләр, программалаштырылган укыту, политехник белем бирү), төрле лабораторияләр эшли, соңрак аларның саны арта. Мәсәлән, югары мәктәп педагогика секциясенең эшчәнлеге активлаша: ул республикадагы югары уку йортларында студентларны укыту һәм тәрбияләү мәсьәләләре буенча алып барыла торган фәнни тикшеренүләрне гамәлгә кертә, югары уку йортларының күпчелеге исә педагогия җәмгыятенең юридик әгъзалары була. Лаборатория һәм секцияләр эшчәнлегенең төп формасын конкурслар һәм конференцияләр оештыру, диафильм (математика, физика, тел предметларыннан) һәм методик ярдәмлекләр чыгару тәшкил итә. Билгеле ки, 1967–1968 елларда 35 мең диафильм чыгарыла [ТР МА, б. 1].

Бу елларда гыйлем-тәрбия өлкәсендә яшь буынны тормышка әзерлекле, совет җәмгыятенә файдалы җитештерүчән хезмәткә әзерләү актуаль бурычларның берсе санала. Халык хуҗалыгы өчен югары квалификацияле эшчеләр әзерләүне күздә тотып, яңа типтагы уку йорты – урта һөнәри-техник училищелар (СПТУ) оештырыла. Укучыларны гамәли хезмәт күнекмәләренә өйрәтү буенча дәвамлы эш алып барыла. Республикада профтехбелем систе-

масы тормыш мәйданында әһәмиятле урын били: сиксәненче еллар урталарында 124 профтехучилище гамәлдә була, алар һәр районда ачыла [Хәсәнев, б. 2–6]. Ил күләмендә һөнәри-техник училищелар өчен фәнни-методик кулланмалар һәм дәреслекләр (математика, физика, химия, биология предметларыннан) төзү мәсьәләсе килеп баса.

Шул рәвешле, 1976 елда Казанда СССР Педагогия фәннәре академиясенең Профессиональ-техник педагогика фәнни-тикшеренү институты оештырыла. Аның оештыручысы һәм беренче директоры итеп 1958–1976 елларда Татарстан АССР Мәгариф министры булып эшләгән күренекле галим-педагог Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов (ул бу вазифаны 1992 елга кадәр башкара). М.И. Мәхмүтовның мәктәп укыту системасында проблемалы укыту теориясен куллану мәсьәләсенә багышланган фәнни хезмәтләре җитмешенче еллар дәвамында җәмәгатьчелек фикерендә көчле яңгыраш ала. 1970 елда ук, галимнең проблемалы укыту идеясен яклап, СССР Педагогика фәннәре академиясе үзенең Гомуми педагогика фәнни-тикшеренү институты дидактик лабораториясен Казанда ача һәм ул Татарстан укытучыларының фәнни-методик үзәгенә әверелә. Әлеге дидактик лабораторияне М.И. Мәхмүтов җәмәгать тәртибендә үзе җитәкли [Виртуальный музей-библиотека...].

СССР Педагогия фәннәре академиясе Президиумы тарафыннан әлеге Институтны оештыру максаты белән 5 административ-идарә һәм 57 фәнни-тикшеренү штаты бүлеп бирелә. Фәнни бүлекчә 7 лабораториядән тора. Кадрлар туплау мәсьәләсе аеруча кыенлыклар тудыра, чөнки Казан шәһәрендә генә түгел, ә ил күләмендә дә профтехпедагогика юнәлешендә эзләнү эшләре алып баручы, дипломлы белгечләр санаулы гына була. Институт эшенә Казандагы һәм башка шәһәрләрдәге уку йортлары һәм фәнни-тикшеренү институты хезмәткәрләре тартыла. Институт аспирантурасында берничә дистә кеше укый, яшь галимнәр илнең төрле төбәкләреннән гыйльми советта гомуми һәм һөнәри-техник педагогика буенча докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре якларга килә.

Институт оешу белән алдагы елларда түбәндәге эзләнү проблемаларын өйрәнү күздә тотыла:

– гомуми политехник һәм һөнәри белем бирүнең үзара бәйләнеш теориясенең методологик нигезләре;

– урта һөнәри техник училище укучыларына гомуми белем бирүнең психологик һәм дидактик нигезләрен камилләштерү;

– урта һөнәри техник училище укучыларына коммунистик тәрбия бирүнең эчтәлеген һәм ысулларын камилләштерү мәсьәләсе;

– заманча укыту һәм җитештерүгә өйрәтү шартларында урта һөнәри техник училище укучыларын профессиональ ориентация һәм адаптациянең социаль, психологик һәм физиологик нигезләре [ТР МА, б. 1–4].

Бу чорда Татарстан галимнәренең һәм укытучыларының педагогик эш тәҗрибәсе һәм осталыгы укучыларның танып белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерүгә, һөнәри белем бирүне камилләштерү, укучылар белән индивидуаль эшләү, проблемалы укыту һәм

башка максатларга юнәлтелә. Педагогик тикшеренүләрнең аерым тармагын татар мәктәпләрендә рус теле, ана теле һәм әдәбиятларын укыту методикасын эшкәртү тәшкил итә. Шулай итеп, татар педагоглары, мәртәбәле Казан укытучылары һәм галимнәренең бүген дә зур әһәмияткә ия теореотик хезмәтләре – кыйммәтле педагогик мирасы туплана.

**Чыганаклар һәм әдәбият**


Виртуальный музей-библиотека Академии наук Республики Татарстан [Электрон ресурс] // museum.antat.ru/p/makhmutov/biography/life/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 06.02.2015).

Елабужский педагогический. История и современность. Изд-во Елабужского пединститута. Елабуга, 1988.

*Жданова Г.* Милли мәктәпләр институты филиалы һәм татар мәктәпләре // Совет мәктәбе. 1965. № 3.

Казанский университет имени В.И. Ульянова-Ленина. Историко-филологический факультет. Краткая справка. Казань, 1974.

*Мәхмүтов М.* Педагогика фәне үсештә. 10 б. URL: vml.antat.ru>files/ Mahmutov/article/article_in (мөрәҗәгать итү вакыты: 06.02.2015).

*Садыйков М.* Күренекле галим-педагог // Мәгариф. 2008. № 10.

*Сегаль М.* Новое завоевание нацполитики. Кафедра татарского языка в КГУ // Красная Татария. 1929. 30 августа.

ТР МА. 248 ф., 1 тасв., 79-эш.

ТР МА. 248 ф., 1 тасв., 8 эш, 2 б.; 99 эш.

ТР МА. 248 ф., 1 тасв., 8 эш.

ТР МА. р-232 ф., 1 тасв., 23 эш, 1–6 б., 43 эш, 1 б.; 51 эш.

ТР МА. Р-425 ф., 1 тасв., 26 эш.

ТР МА. Р-6559 ф., 2 тасв., 200 эш, 4, 5, 9 б.; 590-эш.

*Хәсәнов М.* Халык мәгарифен камилләштерүнең төп мәсьәләләре // Совет мәктәбе. 1985. №6.



***Әхтәмова Алсу Вазыйх кызы,*** *тарих фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.*

УДК 745

*Л.М. Шкляева*

# САМАРА ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ АВЫЛ ТӨЗЕЛЕШЕНДӘ ТӘРӘЗӘ ЙӨЗЛЕКЛӘРЕН ТРАДИЦИОН ОРНАМЕНТЛАР БЕЛӘН БИЗӘҮ (2014 елгы экспедиция материаллары буенча)

В статье рассматривается декоративно-прикладное искусство татар Самарской области, в частности раскрываются способы использования традиционного орнаментального узора в украшении наличников окон сельских строений. Материал подготовлена по результатам комплексной экспедиции, предпринятой в 2014 г. Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ в Самарскую область РФ.

**Ключевые слова:** татары Самарской области, татарское декоративно-прикладное искусство, традиционный татарский орнаментальный узор, украшении наличников окон.

Самара өлкәсенә оештырылган экспедиция вакытында татарлар яши торган унике авылда булдык. Билгеләнгән максатны күздә тотып, анда тупланган материаллар осталарның этник чыгышлары принцибы буенча бүленде. Бер төркемгә Казан татарлары иҗаты буенча Похвистнево районының Гали (Алькино), Нугай, Красный Мост, шулай ук Камышлы районының Камышлы, Иске Ярмәк, Яңа Ярмәк, Балыклы авыллары керде. Икенче төркем уеп-кисеп ясау үрнәкләре буенча Похвистнево районына караган Яңа Мансур, Иске Мәчәләй, Яңа Мәчәләй, Сукаево авылларын берләштерде. Өченче төркемне Келәүле районының керәшен авылы Назаровка осталары тәшкил итте.

Самара татарларының өй шартларындагы нәселдән килә торган һөнәрчелеге XXI гасыр башына кадәр дәвам итә, ә аның башлынгычы XVI гасыр урталарында аларны күпләп яңа җирләргә күчереп урнаштыру чорына барып тоташа. Яңа яши башлаган урыннарда да алар үзләренең көнкүрешләрен туган илләрендәгечә (Казанны Иван IV яулап алгач, бу яклардагы бик күп татарлар күчеп китәләр) итеп оештыралар. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, составы ягыннан урманнарның охшашлыгы татар осталарына үзләренең гадәти торакларын агачтан эшләргә мөмкинлек бирә. Материалны эшкәрткәндә бизәлеш детальләрен матурлауның үзенчәлекле алымнары саклана, ә төрле бизәк элементлары авыл кешеләренең эстетик күзаллавы буенча, матурлыктан тыш, кешеләрне төрле зарарлардан саклаучы (оберег) ролен дә үти. Йортның тәрәзә йөзлекләрендәге агачка уеп төшерелгән орнаментларны игътибар белән караганда, аларда тасвирый күренешнең символик эчтәлеге чагылышын тоясың, ул авыл кешеләренең мәдәни кыйммәтләре формалашуга йогынты

ясаучы әйләнә-тирәлекне эстетик кабул итү позициясеннән чыгып күзалларга ярдәм итә.

Күзәтүләр нәтиҗәсе раславынча, сәнгатьтә үсемлек орнаментлары куллану гасырлар дәвамында файдаланылган. Хәзерге вакытта пластик рамлы тәрәзәләр, сайдинг эшләнмәләр (бизәкләр) торакларның йөзен югалта. Ә менә Самара өлкәсендәге татар авылларында традицион агач йортлар салу, аларны матур орнаментлар белән бизәү дәвам итә һәм болар авыл күренешенә этник үзенчәлек өсти. Декоратив бизәк образлары эчтәлеге Урта Идел буе татарлары тормышының тарихи үсеш этапларын чагылдыра. Сәнгать белгечләре (П. Дульский, Ф. Вәлиев, Г. Сөләйманова-Вәлиева, Д. Вәлиева һ.б.), агачка уеп бизәкләр төшерүнең башлангыч чыганагы, дип, Болгар мирасын саныйлар. Иске шәһәрләрнең XIII–XIV гасырлардан сакланып калган һәйкәлләрендә әле дә күп яфраклы розеткаларны, сабагында бөгелеп торган тукранбаш чәчәкләрен очратырга була.

Бу элементлар бик күп авылларда, Казан татарларында, татар-мишәрләрендә һәм керәшеннәрдә торакларга агач бизәкләр эшләгәндә кулланыла торган типик орнаментлардан санала. Салтово-Маяцки декорына барып тоташкан тукранбаш чәчәге орнаментлары композициясенең еш кабатлануын билгеләп үтәргә кирәк (мәсәлән: Яңа Ярмәкнең Центральная урамындагы 12 нче йортта, Иске Ярмәктәге Школьная урамы, 49 нчы йортта, Камышлының А. Давыдов урамы, 18 нче йортта). Мондый орнаментны традицион һәм халыкчан дип атарга була, чөнки ул Камышлы районының без булган барлык авылларында да тәрәзә йөзлекләренең өске өлешен бизәүдә кулланылган. Симметрик формада эшләнгән, тоташ структураның бөтенлеген гәүдәләндергән мондый орнаментлар тәрәзә йөзлекләренең ике үлчәмле яссылыгына төшерелә. Бизәкләр башта агачтан кисеп алып эшләнгән, аннан аларны Евклид яссылыгының геометрик өслегенә (үсемлек орнаментлары калынлыгындагы өченче үлчәмне барлыкка китереп) урнаштыралар. Монда күреп кабул итү, табигый яктылык төшкәндә, агач рельфындагы яктылык күләгәләре шәүләсе белән баетыла. Ә бизәкләр, тоташ тасвирый элемент тәшкил итеп, тәмамланган сәнгати бөтенлекне аңлата.

Агачтан кисеп эшләү техникасы буенча ясалган бер типтагы композиция вертикаль буенча да, горизонталь яктан да көзгедән чагылгандагыча симметрияле була. Капма-каршы юнәлдерелгән тамчысыман формалар тукранбашлар рәвешендә тәмамлана. Тамчы эчендәге бушлык горизонталь итеп урнаштырылган һәм очлары белән капма-каршы якка юнәлдерелгән йөрәкне хәтерләтә. Җирлек бөтен композициянең үзәге буйлап тагын бер узор барлыкка китерә, анда да шул ук тукранбашлар, тик алар кечерәк үлчәмле була. Гомуми күренешнең нәкъ уртасында кисеп эшләгән ромб яки түгәрәк урнаштырыла (Балыклы, Центральная ур., 68 йорт). Ромбның дүрт очын да үзәк тукранбашлар каймалап торырга (Камышлы, Советская ур., 85 йорт) яки аларның икесе уңга һәм икесе сулга юнәлдерелергә мөмкин (Дәүләткол, Центральная ур, 13 йорт). Тәрәзә йөзлекләренең өске бизәлешендәге шундый ук орнаментларга охшаш төсләр чишелеше Наза-

ровкада да очрый (Центральная ур., 86 йорт), аларда йөрәксыман бизәлеш, эчләрендә тукранбаш орнаментлары булаганлыктан, бик ачык күренәләр.

Урта Идел буе татарларының агачны кисеп бизәкләр төшерүдән тыш кулланылган сәнгать һәйкәлләрендәге чәчәк мотивларын өйрәнү нәтиҗәләре татарларда тукранбашны тасвирлау алымнарының Салтово осталары традицияләре белән охшашлыгын күрсәтә. Салтово-Маяцки культурасы һәм Идел Болгарстаны осталары элемтәсе уртак орнаменталь мотивлар барлыкка килүгә дә нигез була. Н.А. Фонякова фикеренчә, Салтово тукранбашларының беренчел үрнәге (прототибы) борынгылыкның Урта Азия даирәсендәге көмеш әйберләргә төшерелгән лалә (тюльпан) чәчәге булса кирәк, ул, исламга хәтле хөкем сөргән табыну күзаллавы буенча, табигать көченең яңарышын символлаштырган. Урта Идел буе (шул исәптән Самара өлкәсе) татарларының чәчәк орнаментлары Якын һәм Урта Көнчыгышның дөньяны кабул итү традицияләре нигезендәге бизәкләү алымнарын трансляцияләүне раслый.

Ульяновск өлкәсе татар-мишәрләре дә торак тәрәзәләрен бизәкләүдә әйтелгән композицияләрне файдаланалар (Инза районы, Дракино авылы). Шуңа охшаш бизәкне Казанның Иске Татар бистәсендә (Тукай ур., 71 нче йорт) очратырга туры килде. Күрәсең, элек аннан Казан татарлары да киң файдаланган. Бу орнамент татарларның барлык субэтник төркемнәренә дә хас һәм ул Самара өлкәсе татарларының торакларында да тотрыклы саклана.

Бизәкләүнең автор тарафыннан үзенчә чишелеше очраклары да бар. Мәсәлән, Назаровка авылы керәшене Василий Афанасьев (1961 елда туган) тәрәзә йөзлегенә сабаклары белән үрмәләп үскән розетка чәчәген төшергән. Ул агачтан кисеп бизәкләр төшерү остасы, мәктәптә хезмәт дәресләрен алып бара, авылдашларының йортларына агач бизәкләр ясый. В. Афанасьев әйтүенчә, агачтан кисеп эшләнгән ак төсле бизәкләр тормышның матурлыгын символлаштыра. Агач остасы, мишәр Масоль Әбҗәлимов (1936 елда туган) йортының (Яңа Мансур, Колхозная ур., 50 нче йорт) экстерьеры да күп таҗлы розеткалар һәм нәфис үрмәле сабак фрагментлары белән бизәлгән. Ул тәрәзә йөзлеге бизәлеш композициясен юкә агачын лобзик белән кисеп үзе иҗат иткән. Хикмәтле бизәкләрен ул «челтәр» дип атый. М.Әбҗәлимов йортына сайлаган төсләр турында: «Сары өй – бусы кояш төсе, ә аңа ак төстәге бизәкләр төшерү – сафлыкны (чисталыкны) аңлата», – ди.

Тәңрегә табыну белән бәйле архаик мотивларда Кояш сурәтләнгән. Агачтан кисеп розетка чәчәкләре төшерү мишәрләрнең, керәшеннәрнең, Казан татарларының йортларын бизәүдә уртаклыкка ия. Мондый бизәкләр казакъларның агачтан кисеп эшләнгән орнаментлары арасында аеруча өстенлеккә ия, ул аларда Тәңге образын гәүдәләндерүче дала төркиләренең гарәпләргә кадәрге сәнгать элементларын – бүлгәләнгән түгәрәк яки розетка чәчәген хәтерләтә. Кайбер тәрәзә йөзлекләренең өске өлешендә тонык техника (тактага башта бизәкнең рәсеме ясала һәм өтерге, пәке кебек кораллар ярдәмендә орнамент тирәләре чокып, уеп чистартыла, рельеф барлыкка

китерелә) нигезендә эшләнгән орнаментлар да сакланган (Назаровка, Центральная ур., 87 йорт). Улаксыман сигментларга бүлгәләнгән фигура (түгәрәк, ярымтүгәрәк яки розетка таҗлары) композициянең үзәгенә урнаштырыла. Ф. Вәлиев аңа охшаш үрнәкләрне Казан арты авылларындагы кәрниз асты өлешләрендә очратуын теркәгән. Шундый ук символик бизәкләр рус йортларының славяннар алласы Ярила образын гәүдәләндергән декорында да очрый, болар төрле халыкларның дөньяга карашы формалашу процессларындагы охшашлыкны раслый. Хәзер Самара өлкәсе татарлары йортлары бизәлешендә кояш сурәтен агачтан кисеп, ябыштырып эшләүнең күп төрле вариантларын очратырга була. Әйтик: чыгып кына килүче кояшны турысызыклы нурлар белән реаль чагылдыру (Яңа Мәчәләй, Нариман ур., 56 нчы йорт), яки фронтонның зәңгәр фонына күптаҗлы розетка чәчәге урнаштыру һ.б. (Назаровка, Центральная ур., 71, 83, 84 нче йортлар). Розетка таҗлары да төрле формада бирелгән: алар йә ярымтүгәрәк, йә очлы. Кояш Назаровка авылындагы йотларның экстерьеры бизәлешендә төп мотив булып тора, бу керәшен авылында кояш орнаменты ике кыеклы күп кенә йортлар фронтонының үзәгенә урнаштырылган. Ул Яңа Мәчәләй авылындагы йортларның почмагы каймасының өске өлешендә очрый (Главная ур., 4 нче йорт). Красный Мост авылында кояштан алты вертикаль нур (өчесе дискның өске, өчесе аскы өлешенә урнашкан) чыгарылып эшләнгән орнаментка тап буласың (Центральная ур., 5, 27 нче йортлар). Бизәк пилястраның үзәк өлешенә урнаштырылган. Нугай авылында шушындый ук композиция белән капка баганаларын бизәгәннәр (Центральная ур., 59, 65 нче йортлар).

Казан татарларында, керәшен һәм мишәрләрдә тәрәзә йөзлекләренең өске өлешен ромб рәвешендә бизәү күптәннән яшәп килгән күренеш. Самара өлкәсендә зәңгәр йөзлекнең өстенә, нәкъ урта бер җиренә горизонталь буена сузып эшләнгән ак төстәге эре ромб белән бизәү күзәтелә (Назаровка, Центральная ур., 92, 101 нче йортлар; Нугай, Центральная ур., 55 нче йорт; Камышлы, Советская ур., 85 нче йорт; Иске Ярмәк, Клуб ур., 2 нче йорт). Тораклар экстерьерындагы агачтан кисеп эшләнгән бизәкләрнең символик эчтәлеген галимнәр төрлечә аңлаталар. В.С. Воронов, мәсәлән, аны славяннарның мәҗүсилек, тәңречелек символы – кояш билгесе дип саный, Е.П. Бусыгин ромбны басуның игенчелек билгесе, орлык белән бәйли.

Яңа Мансурда яшәүче, белеме буенча төзүче, тәрәзә йөзлекләре эшләүче оста Әхмәт Сафиуллин (1953 елда туган) иҗатында исламга кадәрге табыну кайтавазы чагыла. Үз йортын ул 1997 елда торгызган. Ә. Сафиуллин йорт фасадына фон итеп зәңгәр төсне сайлаган, ә кисеп эшләнгән бизәкләрне акка буяган. Бу авылда күбесе өйне шулай бизи. Оста тәрәзә йөзлегендәге кисеп бизәлгән орнаментны «тамчылар» дип атаган. Уңыш алу өчен кирәкле шартларның бер компоненты буларак, су Урта Идел буенда яшәүче күп кенә халыклар тарафыннан изгеләштерелгән.

XX гасыр урталарыннан Самара өлкәсе татар авылларында йортларның һәм башка

корылмаларының экстерьерын бизәүдә башка төрле геометрик мотивтагы орнаментлар да күренә башлый. Красный Мост авылы балта остасы Газинур Вакказов (1936 елда туган) (Центральная ур., 27 нче йорт) мондый декоратив эшләнмәләрнең киң таралуын әйтте, ул йортларны агачтан кисеп бизәкләүдә үз авылында гына түгел, күрше-тирәләрдә дә эшләгән кеше буларак, бу хакта яхшы белә, әлбәттә. Аның әйтүенчә, өчпочмак формасындагы орнаментны үз араларында «өчпочмак бизәк», ә түбә фронтонындагы ярымтүгәрәк формадагы челтәр күрнизне «түгәрәк бизәк» дип йөртәләр икән. Г. Вакказов, 1950 елларга кадәр авыл йортлары нигездә фәкыйрь, агач өйләрнең түбәләре камыш белән ябылган иде, дип сөйли. Шуннан соңгы елларда торак йортларны яңарту башлана, һәм бу күренеш агачны сәнгати бизәкләүгә дә этәргеч бирә. Бизәкләрне нарат яки юкә агачыннан ясыйлар. Шул чорда кемдер «өчпочмак бизәк»не уйлап чыгара, аны эшләү җиңел булганлыктан, яңа салынган йортларны шундый орнаментлар белән бизәү киң таралыш ала (Алькино, Садовая ур., 33 нче йорт). Шулай итеп, XX гасыр урталарыннан Самара өлкәсендә өйләрне матурлауда агачтан кисеп эшләнгән орнаментларның җиңелрәкләрен сайлыйлар, алар, символик мәгънәгә ия булмыйча, декоратив функцияне үтәүгә генә кайтып калалар.

Шулай да агачтан кисеп бизәү техникасы нигезендә эшләнгән бизәкләр үзләрендә ерак үткәннәрнең генә түгел, күптән түгел генә булганнарның да символикасын саклыйлар. Самара өлкәсендә биш канатлы йолдыз белән бизәү Советлар Союзы таралганчы төзелгән йортларның күбесенә хас күренеш. Аннан соң торакларның тышкы бизәлешендә ислам дине белән бәйле тамгалар күренә башлый, андый символларны бигрәк тә Самара өлкәсендә яшәүче Казан татарлары куллана. Мөселман темалары, һәркемгә мәгълүм булганча, шушы диндәге осталар иҗатында чагылыш таба. Нугай авылы имамы Тәлгат Муллакаев (1938 елда туган) үз йортының өч тәрәзәсенең дә йөзлекләрен акка буялган ярымай белән бизәгән (Центральная ур., 33 нче йорт).

Татар авылларындагы күп кенә осталар йортларның тышкы күренешен матурлауны зарурилык дип саныйлар һәм аны кире кагарга уйламыйлар да. Күбрәк агачны кисеп бизәү яки кисеп алынган бизәкләрне ябыштырып эшләү кулланыла. Кисеп эшләнгән бизәкләр йортның фронтонына, тәрәзә йөзлекләренә, капкаларга урнаштырыла. Кешеләрдән сорашып белүләрдән аңлашылганча, өйләрнең экстерьеры орнаментлары символик эчтәлеген кабул итүнең тагын бер юнәлеше ачыкланды. Мәсәлән, йортның тышкы бизәлеше өчен элекечә үк 3–4 төскә өстенлек бирелә. Татарларның барлык субэтник төркемнәре өчен дә ул көрән (кызгылт көрән), зәңгәр, яшел, сары төсләрдән гыйбарәт. Бизәкләр, кагыйдә буларак, ак төскә буяла. Самара өлкәсе керәшеннәре дә хәзер йортларын бизәүдә күптөслелекне өстен күрәләр.

Самара өлкәсе татарларының агачны кисеп бизәкләү сәнгате йорт һөнәрчелеге белән иҗади кәсепчелек кушылмасын тәшкил

итә, һәм ул авыл кешеләренең эстетик зәвыгын формалаштыру процессында әйләнә-тирәлекнең күргәзмәлелеген арттыра. Агачны сәнгати эшкәртү традициясе Урта Идел буе татарларының мәдәни үзенчәлекләрен саклауга ярдәм итә, күп буыннар тарафыннан тупланган тәҗрибәнең эчтәлеге яңа буынның дөньяны кабул итүен формалаштыруга йогынты ясауда чагыла.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 75.052

*А.Р. Москвина*

# ТАТАРСТАНДА МОНУМЕНТАЛЬ СЫНЛЫ СӘНГАТЬ ҮСЕШЕНЕҢ БҮГЕНГЕ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

Статья освещает основные тенденции формирования и развития монументальной живописи в Татарстане на современном этапе. Исторический экскурс позволяет выделить характерные региональные особености данного вида изобразительного искусства. Проблема, поднимаемая в статье, актуальна на сегодняшний день. Так как после периода забвения 90-х гг. XX века, в монументальной живописи наступила пора динамичного развития.

**Ключевые слова:** монументальная живопись, батик, витраж, смальтовая мозаика, гобелен.

Монументаль сынлы сәнгатьнең төп кулланылыш сферасы күренекле эшлеклеләрне, мөһим тарихи вакыйгаларны мәңгеләштерүдән гыйбарәт. Аның тематикасы һәм стилистик юнәлеше дөньяга караш һәм иҗтимагый тормышта өстенлек яулаган атмосфера белән бәйле.

Бу мәкаләдә сүз Татарстандагы монументаль сынлы сәнгать үсешенең төп тендецияләре турында барачак. Тикшеренү методологиясенең нигезе итеп совет чорындагы һәм аннан соңгы монументаль сынлы сәнгать объектларын (витраж, гобелен, мозаика, батик) чагыштырма планда анализлау алынды. Әлеге методика тасвирый сәнгатьнең хәзерге вакытта киң кулланылган бу төре үсешенең яңа тенденцияләрен аерып карарга мөмкинлек бирә.

Инкыйлабка кадәрге чорда монументаль сәнгать үсеше һәм аны пропагандалау өчен җитәрлек дәрәҗәдә шартлар булмый. Татарстанда сынлы сәнгатьнең монументаль үрнәкләре барлыкка килү һәм аның үсеше 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң тәкъдим ителгән ленинчыл план белән бәйле. В.И.Ленин, монументаль (сынлы) сәнгать әсәрләре киң аудиториягә ачык аңлаешлы образлар рәвешендәге белемнәр бирү белән генә чикләнмичә, хезмәт ияләрен патриотизм һәм югары гражданлык рухында тәрбияләүгә хезмәт итәргә тиеш, диде. Шул вакыттан башлап, сәнгатьнең әлеге төрен үстерү планлы рәвештә алып барыла башлый, һәм монда дәүләтнең роле чиксез зур була. Казан сәнгатькәрләре бу чакыруга җавап итеп, төрле истәлекле һәм әһәмиятле вакыйгалар уңаеннан, урамнарны бизи башладылар. Әмма, шул вакыйгалар чордашы П.М. Дульский сүзләренә караганда, ул вакытта иҗат ителгән объектларның фотографияләре дә, рәсемнәре дә, эскизлары да сакланмаган [Дульский, с. 3]. Бу чорда Татарстанның монументаль сынлы сәнгате үсеше Совет монументаль сәнгатенең гомуми кысаларында бара.

Сугыш алдыннан һәм сугыш чорындагы дистә еллар

дәвамында Татарсанда монументаль сәнгать үсеше бөтенләй кими.

1960 еллар ахырыннан башлап, 1980 еллар крайда монументаль сынлы сәнгатьнең торгызылган чоры буларак билгеле. Бу чорда ул архитектурада актив кулланыла, җирле ансамбльләрнең мөһим пластик һәм мәгънәви доминантасына әверелә. Төрле төстәге тонык пыялалардан һәм керамикалардан иҗат ителгән мозаикалар бизәлеше киң тарала. Мәсәлән: «Татарстан» кунакханәсе вестибюлендәге «Кунакларны болгарларча каршылау» композициясе (С.М. Бубеннов, 1969), шушы ук кунакханә рестораныдагы «Татарча чәй эчү» мозаикасы (В.К. Федоров, 1969), Яр Чаллы шәһәрендәге «Энергетик» мәдәният йорты экстерьеры (Р.А. Килдебәков, 1973).

1980–1990 елларда Республиканың Яр Чаллы, Әлмәт, Яшел үзән, Лениногорск, Бөгелмә һәм башка шәһәрләрендә монументаль сынлы сәнгать үсеше дәвам итә.

2000 еллар башында Татарстандагы җәмәгатьчелек биналары интерьер һәм экстерьерларын бизәүдә монументаль сынлы сәнгать бөтенләй диярлек кулланылмый. Моның төп сәбәбе дәүләт заказларының кимүе белән бәйле була.

Казанның 1000 еллыгына әзерләнү барышында әлеге төр сәнгать үсеше өчен иң уңай шартлар тудырыла. Яңа биналар салу һәм искеләрен реконструкцияләү монументалистлар тарафыннан бүгенге дөнья таләпләренә җавап бирердәй яңа әсәрләр тудырылуына китерә. Монда шуны искәртеп үтү мөһим, монументаль сынлы сәнгать гомум сәнгать төрләреннең дәүләт, хакимият куйган бурычларга җавап бирергә тиешле юнәлеше булып санала һәм әлеге тарихи-мәдәни контекстта аның җәмәгатьчелекнең дөньяга карашын чагылдыруы зарур.

2005 елда моументаль сынлы сәнгатьнең өр-яңа үрнәкләре кулланыла. Әйтик, Кол Шәриф мәчетенең михрабы һәм гөмбәзе төрле төстәге тонык пыялалардан төзелгән мозаика, аның гыйбадәтләр залы керамик панно белән бизәлә (Р.А. Килдебәков, Р.В. Сәлахетдинов, Р.С. Сатаров, Н.Т. Хаҗиәхмәтов).

Казан метрополитенының «Тукай» һәм «Кремль» станцияләрен мозаик панно рәвешендәге монументаль сынлы сәнгать элементлары белән бизәү дәүләт заказы нигезендә үтәлде (аның дизайнерлары – С.М. Мамлеева, Р.М. Нургалиева; рәссамы – Н.Т. Хаҗиәхмәтов; О. Хәбибуллин һәм А.С. Хөснетдинов җитәкчелегендәге иҗат төркеме). Г. Тукай экиятләре һәм шигырьләре сюжетына нигезләнгән мозаик композицияләр татар халкының кабатланмас колоритын гәүдәләндерә. «Кремль» станциясе диварлары ак мәрмәр белән тышланган, мозаик панно рәвешендәге декоратив эшләнеше белән ул Казанның ханлык дәверен хәтерләтә. Түшәмдәге киң масштаблы «Елан» («Зилант») мозаикасы станция интерьерының төгәлләнүен аңлата.

Шәһәрнең меңьеллыгы уңае белән Республика музейларында да эш җанланды. Музей киңлекләрен бизәүгә монументалистлар җәлеп ителде. 2010 елда рәссам Ф.Вәлиуллин тарафыннан эшләнгән «Болгарларның исламны кабул итүе» дигән мозаик композиция эскизын (ул

шул ук елны тормышка да ашырылды) моның ачык мисалы диярга була. Сюжетның нигезендә Алмыш хан белән Багдадның мөдәррисләрдән, һөнәрчеләр һәм төзүчеләрдән торган илчелеге очрашу сурәтләнә. Күп фигуралы композиция монументның гомум мәгънәгә ия һәм мәһабәт булуын чагылдыра. Мозаика, сәнгати доминанта булarak, музей экспозициясе киңлеген бизәүдә зур роль уйный һәм тамашачыга киңкырлы эмоциональ йогынты ясый.

1990–2000 елларда үсеш алган текстиль панно (гобелен) тенденциясенә нигез 1970–1980 елларда салынган була һәм алар декоратив гамәли сәнгать өлкәсендә танылу яулаган осталардан М.С. һәм Р.А. Килдебәковлар, А.Н. Егоров, Г.Н. Маликова, Г.К. Шәрипова эшчәнлекләре белән бәйле. Әмма хәзерге этапта җәмәгатьчелек биналары интерьерын гобелен белән бизәүгә дәүләт заказлары юк. Әлеге төр бизәлеш формалары хәзер шәхси заказлар нигезендә гамәлгә ашырыла. Шуңа күрә, монументаль сынлы сәнгать әсәрләрендә масштаб, сюжет, максат, монументальлек сыйфат ягыннан үзгәреп, станок алымы өстенлек итә бара.

Рәссамнар конкрет бер интерьер өчен зур булмаган форматтагы гобелен әсәрләр иҗат итәләр. Хәзерге вакытта гобелен сәнгате торгынлык кичерә: дәүләт заказлары юк, ә шәхси интерьерларны бизәүдә дизайнерлар гобелен кулланмый. Әмма декаротив-гамәли сәнгать осталары авырлыклар алдында югалып калмадылар, алар (М.С. һәм Р.А Килдебәковлар, С.В. Большакова, Х.М. Шәрипов һ.б.) эшләрен дәвам итәләр.

Республикада витраж сәнгате үсеше тенденциясенә аерым тукталу урынлы булыр. Төсле пыялалардан иҗат ителгән декоратив паннолар Совет чорында нигездә җәмәгатьчелек биналары интерьерларын бизәүдә файдаланыла. К(П)ФУ (элек КДУ) ның төп бинасындагы «Студентлар» (1977), Сәйдәшев исем. Мәдәният йорты өчен («Шәһәр бүләк итү» («Дарить города») (1981) витражлары В.К. Федоров тарафыннан эшләнгән һәм алар Совет витраж сәнгатенең менә дигән үрнәкләреннән саналалар. Бу авторның витражлары – гармонияле, сыналган композицияләр үрнәкләре, алар билгеле бер даирә (төрки катлам) өчен төзелгән бинаның мәгънәви гәүдәләнешен һәм максатын көчәйтәләр.

1990 еллардагы торгынлык чорыннан соң витраж сәнгате үзенең күтәрелеш стадиясенә күчә, ягъни аңа гомум ихтыяҗ барлыкка килә. Тасвирый сәнгатьнең шушы төре үсешенә ярдәм иткән тенденцияләрнең берсе – хосусый заказлар арту. Бүген бу өлкәдә советлар дәверендә үк үз эшенең осталары булып өлгергән профессионаллардан А. Куртева, К. Акманов, В. Ткаченко, А. Пашин, Ш. Мотыйгуллин һ.б. иҗат итә. Рәссамнар коттеджлар, квартиралар, офислар өчен табигый төсле пыяладан, кургаш һәм кара кургаштан витражлар эшлиләр. Шулай ук «бюджет витражы» дип аталган бизәү төре дә киң тарала бара, ул төсле һәм яктылык үткәрүчән элпәсыман материалны стелопакетка ябыштырып эшләнә. Моның ябыштырылып эшләнгәнен профессионаллар гына аера ала. Сәнгатьнең бу төре хәзер бик

киң кулланыла. Хосусый заказлар да була, әмма алар бик аз. Ш. Мотыйгуллинның мәчет өчен эшләнгән «Тәүбә» витражы (Яр Чаллы, 1989 – 1992) аерым игътибарга лаек. Анда тасвирый телнең үзенә бер шартлылыгы, декоративлык характеры мәчеттәге гыйбадәт залы пространствосында күңелне тынычландыра, канәгатьлек хисе уята.

Соңгы вакытта батик сәнгате дә үзенең чәчәк ату чорын кичерә. Дизайнерлар аны интерьерлар бизәүдә еш куллана. Рәссамнар аны заказ буенча, билгеле бер пространствода эшлиләр. Бу өлкәдә Ф.Харрасова иҗаты үзенә бер урын били. Ул сәнгатькә Казанның атаклы сәнгать көллиятен тәмамлап, 2000 еллар башында гына килде әле. Һәм, шуңа да карамастан, матурлыгы ягыннан гадәти булмаган батиклар иҗат итә. Рәссам үзенең рухи дөньясы белән табигать арасындагы гармоник тәңгәллекне гәүдәләндерә. Төрле чәчәкләрнең төсләре гаммасы, агач кәүсәләре һәм ботаклары ритмы аның үзенең уй-хисләрен чагылдыра.

Шулай ук монументаль сынлы сәнгать үсешенең чираттагы баскычын тәшкил иткән граффити турында дә әйтеп үтү урынлы булыр. Күпләр сәнгатьнең бу төре тыелган дип саныйлар. Әмма бүгенге заманда аны шәһәр культурасының һәм шәһәр яшәү рәвешенең аерылгысыз бер өлеше итеп карарга кирәк. Сиптергеч буяуларның (спрей) матурлык тудыру мөмкинлекләре әлегә хәтле ирешелмәгән биеклекләрне яулады. Без граффитины Казан урамнарындагы вандализм күренеше дип кабул итәргә күнеккән, ә бит ул, декоратив бизәү формасы буларак, интерьер яссылыгына көннән-көн киңрәк үтеп керә бара. Райтерлар (граффити рәссамнары) аерым йортларны бизәүдә әлегә күрелмәгән матурлыкларга ирешәләр. Рәссамнар үз композицияләрендә рәсем белән шрифтлар арасындагы гармоник бәйләнешләрдән файдаланалар. Хәзер безнең башкалабызда ачыктан-ачык иҗат итүче граффити осталары дип, Дамир Дах, Дмитрий Li/Д Кудинов, Рөстәм Qbic Салемгаев һ.б. ны әйтеп үтәргә була. Шулай ук интерьерларның сәнгати бизәлеше белән crew – 2F2, Dd crew, Чаллыда «ATAS» төркеме шөгыльләнә. Аларның һәркайсы хәрефләренең формалары һәм башкару техникасының югарылыгы (ачык композиция, агып төшкән эзләр булмау, шрифтларның бөтенләй укылмавы) белән аерылып торалар.

Хәзерге вакытта монументаль сынлы сәнгать үзенең иң биек ноктасына җитеп килә. Әлбәттә, монда шәхси (хосусый) заказларның роле зур. Рәссамнарның әсәрләре нигездә заказчының зәвыгына йөз тотсалар да, һәр очракта да иҗатларында аларның стиле сизелеп тора. Монументаль сәнгатьнең максаты да үзгәрә, ул элеккечә киңлеккә (масштаблылыкка) омтылмый, ә интерьерны җанландыра, һәм шул ук вакытта үзенә бер эмоциональлек, күңел күтәренкелеге өсти. Бүген орнаменталь, флораль һәм пейзаж күренешләре белән баетылган, ачык төстәге композицияләргә өстенлек бирелә. Сюжетлы, тематик композицияләр икенче планда кала.

**Әдәбият**

*Дульский П.М.* Искусство в Татреспублике за годы революции: выдержки из доклада, прочит. П.М. Дульским на заседании ОАИЭ 12 апр. 1928 г. // Известия ОАИЭ. Казань, 1929. Т. 34, вып. 3–4. С. 209–218.

***Москвина Альбина Ренатовна,***
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре.*

УДК 792

*Д.Р. Фәрдиева*

# «ИНСАНИЯТ» ТРУППАСЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье рассматривается возникновение и деятельность труппы «Инсаният». Проанализированы наиболее важные спектакли, поставленные данной труппой.

**Ключевые слова:** труппа, спектакль, режиссер, художник, сцена, театр.

«Инсаният» фонды 1991 елның август аенда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры каршында оеша. Бу фонд бөтен гомерен сәхнәгә багышлаган ветеран артистларга матди ярдәм күрсәтү өчен оешкан иде. Әлеге игелекле башлангыч икенче бер эшне кабызып җибәрергә этәргеч булды: Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының ветераннары үзләренең аерым труппаларын оештырып, спектакльләр куя башладылар. Спектакльләрдән кергән табышлар «Инсаният» фондына күчә барды. Тагын игътибарга лаеклысы шул: бу труппа оешу белән сәхнәдән аерылган артистлар яңадан яраткан эшләренә кайтты. Димәк, фондның иң зур казанышы – сәхнә ветераннарын кабат иҗатка тарту, аларны үз тамашачыларыннан аермау, ә иң мөһиме – ялгызлыктан коткару. Әлеге труппаның җитәкчесе итеп Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы Рәшидә Җиһаншина билгеләнде. Инсаният – инсан, ягъни «кеше» дигән сүздән алынган. Димәк, әлеге труппа исеменә кешелеклелек, шәфкатьлелек, өлкәннәрне ихтирам итү мәгънәсе салынган. «Театрыбызның җитәкчеләре дә безнең өчен шундый труппа төзеп, нәкъ менә шундый сыйфатларга ия булган кешеләр икәнлеген күрсәттеләр», – дип искә төшерә Татарстанның халык артисткасы Р. Хәйретдинова (2008 елның 22 маендагы әңгәмәдән). Театр ветераннарны үз канаты астына ала, аларның спектакльләрен сәхнәгә чыгаруның барлык чыгымнарын үзе хәл итә.

«Инсаният» труппасы тамашачылар күңелен, иң беренче чиратта, үзенең репертуары белән җәлеп итте. Труппа спектакльләрне дә өлкәннәр яшәешен чагылдырган әсәрләрдән сайлап әзерли. Анда аларның тормышлары киң планда күрсәтелә: узган яшьлекләрен сагыну да, лаеклы яшәлгән гомерләре белән горурлану да яңгыраш таба.

Труппа «Инсаният» утын Флорид Бүләковның «Әбиләргә ни җитми» спектакле белән кабызып җибәрде (режиссеры П. Исәнбәт, рәссамы Р. Газиев). Әлеге спектакльнең премьерасы 1991 елның 8 декабрендә күрсәтелә. Спектакль яңа оештырылган труппага зур уңыш алып килә. Ул сәхнә фидакарьләренең популярлыгы һич тә кимемәвен, тамашачыларның аларны һаман да яратуын, көтеп алуын ачык күрсәтә. Бу әсәр үзе дә өлкәннәр язмышын сурәтли. Эчтәлегенә килсәк, монда вакыйга картлар йортында бара. Спектакль-

дә барлыгы алты кеше катнаша. Колхоз рәисен Һидаят Солтанов, бүлмәдә староста булып торучы беренче карчыкны Рәшидә Җиһаншина, икенче карчыкны Шәхсәнәм Әсфәндиярова, өченче, чукрак булып кыланып, шул ук вакытта бөтенесен ишетеп, тыңлап койкада ятучы карчыкны Вера Минкина, дүртенче карчыкны Рауза Хәйретдинова, бу авылга ат дагаларга дип килгән, күптөрле һөнәр иясе булган карт – Габдулланы Идрис Мәсгутов уйный.

Бу труппа, озакламый кече залда Шәриф Хөсәеновның «Кофер почмагы»н, Александр Галинның «Сагыш» спектакльләрен сәхнәләштерде.

Өлкәннәр уйнарлык сәхнә әсәрләренә кытлык сизелә башлагач, сәхнә кануннарын яхшы белгән Р. Җиһаншина үзе пьесалар язарга керешә. Ул тормышта очраткан яки ишеткән вакыйгаларга таянып, кайсы рольдә кем уйнарга мөмкин икәнен күз алдында тотып яза. Аның «Сөйдергеч бөтие», «Көтелмәгән кунак», «Кодагыйлар», «Улларым» пьесалары катлаулы сюжетка корылмаган булсалар да (барысы да, нигездә, өлкән яшьтәге кешеләр язмышы, проблемалары, әхлак мәсьәләләре турында диярлек), тормышта һәрдаим очрап торган хәлләрне күрсәтеп, тамашачы күңелен яулап алды. 1992 елның бишенче мартында Г. Камал исемендәге театр сәхнәсендә «Сөйдергеч бөтие» дигән премьера куела (режиссеры И. Хәйруллин, рәссамы С. Скоморохов). Рәшидә Җиһаншинаның бу әсәре – аның профессиональ сәхнәдә уйналган беренче уңышы. Бу пьеса «Инсаният» өчен махсус язылган. Һәм андагы образлар да рольне башкарачак һәр актерның иҗади үзенчәлеген исәпкә алып эшләнгән. Ул образларны танылган актерлар Шәүкәт Биктимеров, Вера Минкина, Рауза Хәйретдинова, Әнвәр Гобәйдуллин, Һидаят Солтанов һәм Рәшидә Җиһаншина үзе гәүдәләндерде. Спектакльнең геройлары өлкән яшьтә булуларына карамастан, тормыш авырлыкларыннан, ялгызлыктан котылу өчен, гаилә учагын тергезергә омтылалар, олы, якты мәхәббәт турында хыялланалар. Тамашачыны сөендереп, киләчәккә өметләндереп, һәр герой үзенең парын да таба.

Р. Җиһаншинаның сәхнә геройлары – өлкәннәр. Шулай булуга карамастан, әлеге геройлар яшьләрчә хыялланырга да, тирән хисләр кичерергә дә сәләтлеләр. Аларның күңелендә дәрт, күзләрендә очкын сүнмәгән. Ә иң кыйммәтле сыйфатлары – намуслылык, бурыч тойгысы. 1994 елның 19 февралендә Г. Камал исемендәге театр сәхнәсендә «Улларым» спектакленең премьерасы күрсәтелә (режиссеры И. Хәйруллин, рәссамы С. Скоморохов). Монда мәңгелек темаларга мөрәҗәгать ителә: ана йөрәге, сугыш, югалту, яшьлек мәхәббәтенә тугрылык. Пьеса авторы Р. Җиһаншина үзе сугыш афәтен татыган кеше буларак, әсәрнең хисси тукымасын оста итеп үрә белгән.

«Инсаният» спектакльләренең үзенчәлеге шунда: аларда икенче состав (ягъни дублерлар) юк, чөнки һәр роль конкрет артист өчен билгеләнә. Мәсәлән, Р. Җиһаншина пьесасы буенча 1998 елда куелган «Көтелмәгән кунак» спектакле дә моны ачык раслый (режиссеры П. Исәнбәт, рәссамы С. Скоморохов). Әлеге спектакльдә гыйбрәтле тема – ялгыз яшәүче өлкән кешеләрнең,

бик тиз ышанучан булулары аркасында, җинаятьчеләр тозагына эләгүе тасвирлана. Олы яшьтәге ялгыз кешеләрнең фатирсыз калу очраклары хәзер дә ишетелеп тора бит. Шуңа күрә автор да, режиссер да әлеге спектакль белән «Сак булыгыз! Уяу булыгыз!» дип әйтергә телиләр.

Үзенең ун еллык юбилеена «Инсаният» труппасы Т. Миңнуллин пьесасы буенча «Үзебез сайлаган язмыш» спектаклен әзерләде (режиссеры А. Хафизов). Ни өчен юбилей кичәсенә алар нәкъ менә шушы әсәрне сайлаганнар соң? Беренчедән, «Үзебез сайлаган язмыш» өлкән буын артистлардан торган «Инсаният» труппасы өчен туры килгән бик аз әсәрләрнең берсе. Икенчедән, укытучылар тормышын яктыртырга алынып көн кадагына суккан «Инсаният» труппасының әһәмияте тагын да арта. «Үзебез сайлаган язмыш» спектаклендәге бөтен гомерләрен балалар тәрбияләүгә багышлаган авыл укытучылары ирле-хатынлы Шәмсенур һәм Нариман рольләрен башкарган Рауза Хәйретдинова һәм Әзһәр Шакиров, мәктәп уку-укыту бүлеге мөдире образын башкаручы Гөлсем Исәнгулова, кыска гына эпизодларда оста уйнаган Асия Галиева һәм Әнвәр Гобәйдуллинарны тамашачылар көчле алкышларга күмәләр. Бу «Инсаният» труппасы артистларының әле һаман да сәхнәдән төшмәүләрен, иҗади омтылыш, рухи дәртнең еллар үтүгә карап кына сүнмәгән икәнлеген раслады.

2006 елда «Инсаният» труппасы яшәүдән туктый. Моның сәбәпләрен төрлечә аңлатып була: кайбер артистлар артык олыгаеп китте, өлкән кешеләр өчен яраклы махсус пьесалар язучы юк, Рәшидә Җиһаншина, Шәхсәнәм Әсфәндиярова һәм «Әбиләргә ни җитми», «Көтелмәгән кунак», «Кодагыйлар» пьесаларын куйган режиссер Празат Исәнбәт мәңгелеккә китеп бардылар. Матди яктан та мохтаҗлык кимеде.

Үзенең яшәү дәверендә «Инсаният» труппасы куйган спектакльләрнең һәркайсы яктылыкка, игелеккә, җылылыкка бай иде. Вера Минкина, Рауза Хәйретдинова, Рауза Әхмәрова, Асия Галиева, Һидаят Солтанов, Әнвәр Гобәйдуллин, Шәүкәт Биктимеров, Гөлсем Исәнгулова, Рәшидә Җиһаншина – татар театр сәнгатенең билгеле бер чор тарихын язган шәхесләр. Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының яшь артистлары «Инсаният» труппасы артистларыннан саф татарча, матур әдәби тел белән сөйләшергә генә түгел, сәхнә осталыгына да өйрәнеп калдылар.

***Фәрдиева Динара Радий кызы,*** *филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*

## Б. Корганбеков. «Шора батыр»: нөсхәләре, генезисы, тарихилыгы»

Халыкның киң кырлы эпик иҗатын аның бай тарихыннан, әдәби-мәдәни багланышларыннан аерып карау мөмкин түгел. Фольклорда героик эпос яисә тарихи дастан дип аталган жанр реаль вакыйгалар җирлегендә барлыкка килә, иҗат мәйданына тарихи шәхес образын чыгара. Әлбәттә, эпос-дастаннар чынбарлык вакыйгаларының күчермәсе түгел. Вакытларны кичкәндә төрле үзгәрешләр кичергән мондый ядкарьләр кайвакыт тарих тирәнлегеннән яңгыраган авазның үзенчәлекле аһәңенә әверелгән булырга да мөмкин. Әмма эпоска, бигрәк тә героик эпоска, чорлар кайтавазы сеңми кала алмый. Иң беренче чиратта нәкъ менә шуның белән җәлеп итә дә инде бу гаҗәеп истәлекләр.

Тамыры белән уртак нигезгә барып тоташучы кардәш халыклар иҗатында берсенә генә нисбәтләп булмый торган, бер үк вакытта берничә төрки халыкның әдәби-мәдәни мирасын тәшкил итә торган дастаннар бар. Чура батыр исеме белән бәйле эпос – әнә шундый истәлекләрдән. Әлеге дастаннарның Казан, Кырым татарлары, нугай, казакъ, башкорт, каракалпак һәм кыргыз халыкларының эпик иҗатында киң таралган булуының сере әлеге дә баягы тарихка барып тоташа. Уртак сюжетлы «Чура батыр» дастаннары, кайсы халыкның нинди генә варианты булуына карамастан, күпчелек очракта Идел буендагы Казан шәһәренең рус дәүләте тарафыннан яулап алыну вакыйгалары, шушы чор шәхесләре хакында бәян итә. Ә Казан шәһәре, мәгълүм булганча, 1552 елда яулап алына, димәк, барлыкка килүе белән Чура батыр турындагы бу мәшһүр сюжет тәгаен XVI йөз уртасыннан соңгы чорга карый. Дастанның нәкъ менә югарыда санап үтелгән төркиләрдә популярлыгы исә – замандында Алтын Урда дәүләте составындагы халыкларның уртак рухи ихтыяҗларының, бердәм теләк-идеяләренең бер дастанда гәүдәләнгән чагылышы.

Чура образының төрки халыклар иҗатында популярлыгына галимнәр XX йөзнең 40 нчы елларыннан алып игътибар итә киләләр. А.С. Орлов (1945), В.М Жирмунский (1974), Х.Б. Паксой (1986), А. И.М. Сикалиев-Шейхалиев (1994), Д.Ф. Исхаков (1994), Ф.И. Урманчеев (1995), Л.Х. Ибраһимова (2000, 2002), М.Х. Бакиров (2012) кебек тарихчы-эпос белгечләренең бу мәсьәләгә багышланган төрле елларда дөнья күргән хезмәтләре бар.

2014 елда шушы ук темага фольклорчы галим Болат Сагынбекулы Корганбековның казакъ телендә «Шора батыр» эпосы: нөсхәләре, генезисы, тарихилыгы» [Корганбеков, 2014] дигән өр-яңа саллы монографиясе басылып чыкты. Уртак мираска карата гаять дәрәҗәдә этрафлы игътибар күрсәткән бу хезмәт Чура батыр турындагы моңа кадәрге монографияләрне һич кенә дә кабатламавы, киң масштаблы һәм бай фәнни эчтәлеге, тирән теоретик нигезе, әле дә халык телендә булган «тере» эпик мисалларга

таянуы белән киң колачлы тикшеренү буларак кабул ителә.

Узган ел азагында дастаннар остасы атаклы Морын жырау Сеңгирбек улының 155 еллыгы уңаеннан Казакъстанда үткәрелгән «Ногайлы эпосы һәм Морын жырау феномены» дип аталган халыкара конференциягә чакырылып, киң дала һәм тирән диңгез очрашкан гаҗәеп урындагы Актау каласында казакъ һәм нугай жырауларының Чура батырга һ. б. темаларга багышланган эпосны бүгенге көндә дә телдән башкаруларын үз колакларым белән ишетеп һәм үз күзләрем белән күреп кайту бәхете насыйп булды миңа. Эпосның импровизатор тарафыннан әйтелә торган традицион төре нык үсеш алган биредә, әдәби-мәдәни байлыкка гаять дәрәҗәдә игътибарлы казакъ һәм нугайлар, алай гына да түгел, думбра чиртеп жыру әйтү – кардәшләребезнең табигый халәте, бу эшне башкара алмаган берәр казакъ бар микән ул, дигән сорау да туды миндә хәтта. Шул ук Чура батырга яисә Кұр углына багышланган дастанны жырау ниндидер бер экстаз халәтендә тоташтан әйтә дә әйтә, әйтә дә әйтә. Жырау авазына ияреп, актарылып, әйтерсең тарих үзе кире кайта.... Шунысы игътибарны аеруча җәлеп итте: Казакъстанда эпос әйтү сәнгате махсус колледжларда аерым сабак буларак та укытыла икән. Яшь буын элгәрләре хакында буыннан-буынга килә торган фольклор әсәрләрен ишетеп тә белә, шул дастанны үзе дә көйләп-әйтеп бирә. Онытылган, кайдадыр еракта торып калган шөгыль түгел биредә жыру-эпос әйтү, ә күңел таләбе, рухи ихтыяҗ. 2013 елда, шулай ук халыкара конференциядә, Якутск шәһәрендә саха-якутлар белән аралашу нәтиҗәсендә төньякта яшәүче төрки туганнарыбызның үз телләренә, мәдәниятенә, тарихына, эпик иҗаты – олонхоларына булган җитди мөнәсәбен күреп тәэсирләнеп кайткан булсам, узган ел азагында Актауга сәфәрем минем казакъ кардәшләребезгә булган ихтирамымны бик нык үстерде. Эпос – ул халык тормышын эпик планда тасвирлый торган күләмле әсәр, шушы иҗатка булган мөнәсәбәте халыкның тулаем милли йөзен билгеләүдә катнаша торган зур бер фактор лабаса... Болат Корганбековның төрки «Чура батыр» дастанына багышланган яңа монографиясе дә эпоска карата шушы жылы мөнәсәбәтнең күркәм чагылышы.

Болат Корганбеков – казакъ халкының эпик фольклорын өйрәнүне төп фәнни юнәлеше итеп алган тәҗрибәле белгеч, филология фәннәре кандидаты. Әлеге монография Болатның беренче иҗат җимеше түгел, аның Әхмәт Ясәви һәм казакъ фольклорына багышланган монографиясе (2011, 2012) дөнья күргән, ул берничә коллектив монография, сигез дистәдән артык фәнни мәкалә авторы, күпсанлы жыентыклар, күптомлыклар төзүче дә. Хезмәтләренең барысы да казакъ халык иҗаты өлкәсенә, дастаннарга багышланган, кайбер мәкаләләре инглиз, төрек, рус, үзбәк телләрендә дөнья күргән. Болат 1990 елда Алма-Атада С.М. Киров исемендәге Казакъ дәүләт университетын тәмамлаган, кандидатлык диссертациясен уңышлы яклап, соңгы елларда докторлык диссертациясе әзерләгән, бүгенге көндә Казакъстанның Жетысай шәһәрендәге «Сырдария» университетының казакъ теле һәм әдәбияты кафед-

расы доценты. Казакъ халкының үз эпик мирасына зур ихтирам һәм игътибар шартларында тәрбияләнеп, озак еллардан бирле милли идеология юнәлешендә эшләп килә торган кафедра белән язмышын бәйләгән Болатның төрки «Чура батыр» белән җитди кызыксынуы, әлеге мәшһүр эпосны барлык нөсхәләре, килеп чыгышы, тарихилыгы җәһәтеннән ныклап өйрәнергә керешүе һәм әлеге темага киң колачлы хезмәт башкарып, аны китап рәвешендә дөньяга чыгаруы һич кенә дә гаҗәп түгел, ә гаять тә көтелгән, табигый нәтиҗә.

Төрки «Чура батыр» – фәнни, тарихи, иҗтимагый, тәрбияви, мәдәни әһәмияте ягыннан гомумкешелек мирасы булырлык, дөнья эпосына торырлык рухи байлык. Бу бөек ядкарьнең дәрәҗәсен ачыклап, аның хакында зур тикшеренү эшләү – төрки дөнья өчен дә, гомумән фәндә эпос өлкәсе өчен дә һәрвакыт гаять актуаль мәсьәлә, шуңа күрә казакъ кардәшләребез вәкиле Болат Корганбековның әлеге юнәлештәге эшчәнлеге бик зур мактауга лаек.

Үзенең күркәм тышлыгы белән үк игътибарны җәлеп итеп тора торган зур күләмле, фәнни аппараты камил бу затлы китап Астанада дөнья күргән. Тиражы – 2000 данә. Монография Казакъстанның Жетысай шәһәрендәге «Сырдария» университеты һәм Алма-Атадагы М. Ауэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми советлары карары белән чыгарылган.

Автор Чура батыр тирәсендә барган бетмәс-төкәнмәс сорауларны мантыйкый эзлеклелектә кабат мәйданга чыгара, тарихи чынбарлык белән эпик чынбарлык арасындагы бәйләнешләрне барлый, Чура батыр һәм аңа бәйле вакыйгалар турында барган бәхәсле мәсьәләләргә фәнни чишелеш тәкъдим итә, Чура батырга багышланган эпик истәлекләрдән нугай, кырымтатар, башкорт, казакъ, каракалпак, кыргыз халыкларында табылган 25 вариантын чагыштырып анализ ясый, дастан вакыйгалары, образ-персонажлар системасы белән тарихи чынбарлык арасында параллельләр үткәрә.

Монографиянең кушымчасы итеп бирелгән өлеше турында аерым әйтеп китү таләп ителә. Автор төрле халыкларның Чура батырга багышланган 25 вариантагы дастаннарын, шартлы билгеләр аша таблицага куеп, сюжетларындагы эреле-ваклы вакыйгаларның, теге йә бу эпизодның очравы-очрамавыннан, билгеле эпик мотивларның булу-булмавыннан чыгып, чагыштырып бирә. Дастан вариантларын шушындый яссылыкта карап чыгу – күп вакытны таләп итә торган гаять четерекле вак эш. Шушы таблица үзе генә дә галимнең дастан нөсхәләренең һәркайсына җитди мөнәсәбәтен, аның дастан сюжетында булган һәр детальне нечкәләп белүен күрсәтә торган дәлил. Әлеге таблица Чураның атасы Нарыкның ятим үсүеннән алып, Шора үлгәннең соңында анасы Казанга улын эзләп килеп, сыктау әйтүенә кадәрге – барлыгы 45 сюжет сызыгын үз эченә алган, автор игътибарына алынган барлык 25 вариантта, шул исәптән татар халкының ике вариантында шушы вакыйгаларның чагылыш кимәле эзлекле ачыкланган. Бу әһәмиятле эшне автор күп кенә төрки вариантларга карата җиренә җиткереп эшләгән.

Әмма күңелне тырнап торган бер нечкәлек хакында да әйтеп

китми ярамый. Темасы, сюжеты ягыннан татар «Чура батыр»ының шактый үзенчәлекләргә бай булуы, аның реаль вакыйгаларга да иң якын торган версия икәнлеге мәгълүм [Ибраһимова, 2002]. Бу аңлашыла да: Казан ханлыгының Мәскәүгә көчләп буйсындырылуы иң беренче нәүбәттә татар халкы өчен зур фаҗига булган бит. Казан алынганнан соң барлыкка килгән эпоста да бу моментка игътибар ителми калмаган, әлбәттә. Шуңа күрә дә «Чура батыр»ның татар варианты бер-берсенә тирән керешкән ике зур теманы яктырта, алар – каһарман Чура язмышы һәм Казан җимерелү вакыйгасы. Шул ук вакытта бу әсәр, татар ханлыкларының бер-бер артлы рус дәүләте тарафыннан буйсындырылу фактын искәртеп, теманы тагын да киңәйтә. Б. Корганбеков төзегән чагыштырма таблицада гаять әһәмиятле шушы вакыйгага ни өчендер урын бирелмәгән. Дастанның татар варианты мондый сүзләр белән тәмалана: «Соңра урыс гаскәре галиб булып (өстенлек алып. – *Л.М.*), Казан шәһәрен алды. Урыс падишаһына табигъ булдылар (буйсындылар. – *Л.М.*). Бу Казан шәһәрен алганнан бер ел соңра Хаҗитархан шәһәрен янә алды. Чура батырның хикәяте тәмам булды» [Татар..., 1984, б. 119]. Дастанның тарихи чынбарлыкны чагылдыруы җәһәтеннән бик тә мөһим булган әлеге юлларга Б. Корганбеков монографиясендә артык игътибар бирелмәгән, ә инде кушымта-таблицада бу вакыйганың бөтенләй төшереп калдырылуы гаделсезлек булып аңлашыла. Югыйсә, татар халкының эпик иҗатында Чура батыр образына багышланган әсәрләрнең – китаби дастанмы ул, бәет, риваять, кечкенә хикәятме, йә булмаса шушы ук теманың соңгырак чор иҗатка караган язма характердагы дәвамымы – барысының да умыртка баганасы булып иң беренче чиратта нәкъ менә шушы тарихи вакыйгалар тора.

Хәер, биредә «Чура батыр» дастаннарының башка халык вариантларында татар язмышына кагылышлы фаҗигаләрнең вакыт үткән саен онытыла төшүе, казакъ «Шора батыр»ының каһарман язмышын Казан ханлыгы вакыйгалары белән бәйләүдән читкәрәк тайпылган булуы үз ролен уйнаган булса кирәк. Б. Корганбеков элек язып алынган вариантлардан башлап соңгы чор җыраулары авызыннан язылган вариантлар белән эш итә, төрки вариантларның күпчелегендә зур әһәмият бирелгән вакыйгалар картинасын, образлар гәүдәләнешен ача, Чура батырга багышланган эпос генезисының вакыт чикләрен б.э.к.ге чорларга ук бәйләп, тирәнәйтә. Әлбәттә, дастан вариантларында очрый торган кайбер мотивлар яисә конкрет сарыннар килеп чыгышының бик борынгы чорларга ук барып тоташуы, аларның XVI йөз урталарына кадәр үк күп алда эпик кулланылышта булуы автор тарафыннан нигезле аңлатылган. Чыннан да, хронологик һәм географик яктан Казаннан ераграк торган саен «Чура батыр»ның төрки версияләрендә татар вариантыннан аерылып торган үзенчәлекләрнең күбрәк очравын танырга тиешбез. Шул ук вакытта бик борынгы, хәтта Казан ханлыгындагы трагик вакыйгаларга кадәр үк барлыкка килгән эпосның татар дастанында Казанга якынайтыбрак сурәтләнгән булу

ихтималын да инкарь итмибез. Тик шулай да, дастанның татар версиясендә дә, кырымтатарлары, нугай һәм казакъ версиясе вариантларында да дастан вакыйгаларында Идел буе Казан шәһәренә мөнәсәбәтен кире кагып булмый торган фактлар бик күп һәм аларны очраклылык дип кенә бәяләү дә гаделсезлек булыр иде.

Ничек кенә булмасын, Чура батырга багышланган эпос – тарихыбызның кыйммәтле бер кыйпылчыгы, үткәннәребезнең онытылмас кайтавазы, Чура батыр образы үзе исә – фольклорда төрки халыкларның үзара якынлыгын, туганлыгын һәрвакыт искәртеп тора торган героик образ.

Монографиядә тема 9 бүлеккә аерып тикшерелгән, һәр бүлектә үтә дә әһәмиятле проблема алга чыгарылган. Бүлекләрдә автор әйткән фикерләр гаять масштаблы. Авторның тикшерену ысуллары отышлы, әйткәне төпле, бәян кылу алымнары мавыктыргыч. Фактик материал куллану ягыннан Чура батырга багышланган моңа кадәр билгеле хезмәтләр арасында Болатның монографиясе, шиксез, иң бай хезмәт. Файдаланылган әдәбият исемлегенең тулылыгы да авторның бик мәгълүматлы шәхес булуы хакында сөйли. Китап җиңел укыла, нәтиҗәләр, кайвакыт бәхәс уятсалар да, ышандыра.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Чура батырга багышланган төрки эпик иҗатка казакъ галиме Б. Корганбеков биргән игътибар бик вакытлы һәм урынлы. Болат Корганбеков монографиясе теманы һәм материалны яратып, тирән теоретик әзерлек белән язылган төзек структуралы җитди хезмәт буларак күңелне куандыра. Төрки «Чура батыр»ны шушындый юнәлештә тикшерү һәм аның нәтиҗәсе буларак әлеге китапның басылып чыгуы – казакъ халык иҗаты өчен генә түгел, гомумән төрки халыклар фольклористикасында, эпос-дастаннарны өйрәнү өлкәсендә бик зур казаныш. Казакъ кардәшебез, коллегабыз Болатка яңа иҗат уңышлары телибез. Афәрин!

## Әдәбият

*Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. 190 б.

*Корганбеков Б.С.* «Шора батыр»: нүскалары, генезисы, тарихилыгы. Монография. Астана: Фолиант, 2014. 304 б.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр язучы Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 380 б.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,*** *филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

## З.З. Рәмиев. Әдәбиятчы-текстолог язмалары

Татар әдәбияты белемендә текстология мәсьәләләренә багышланган, нәзари проблемаларны яктырткан хезмәтләр күп түгел. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш гыйльми хезмәткәре Зөфәр Рәмиевнең бу өлкәдәге эшчәнлеге аерым урын алып тора. Аның соңгы вакытларда басылып чыккан китапларыннан «Әдәбиятчы-текстолог язмалары» хезмәте аеруча игътибарга лаек. Әлеге җыентыкта әдәбият галиме, текстолог, филология фәннәре докторы, профессор Зөфәр Рәмиевнең 1990–2013 еллар аралыгында әдәбиятыбызның, мәдәниятебезнең төрле өлкәләрен яктырткан, бөек шагыйребез Габдулла Тукай һәм татар әдәбиятының башка классиклары әсәрләре текстологиясе, татар текстологиясенең кайбер актуаль мәсьәләләрен күтәргән мәкаләләре урын алган.

Зөфәр Рәмиев Институтыбызның иң тәҗрибәле текстологларыннан санала. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, М. Гафури, Г. Камал, М. Җәлил кебек татар әдәбияты класссиклары әсәрләренең күптомлы басмаларын әзерләүдә күп көч куйган галим һәрвакыт актив хезмәттә. Бу өлкәдә күп еллар алып барган эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак, ул 2002 елда «XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре» дигән темага докторлык диссертациясе яклады. Бүгенге көндә Тукай әсәрләрен барлау, текст, авторлык мәсьәләләрен ачыклау, шагыйрь тормышына караган кайбер фактларны торгызу өстендә эш алып бара.

Галим җыентыкка мәкаләләрне биш бүлеккә туплап урнаштырган. I бүлектә Тукай әсәрләре текстологиясенә караган мәкаләләр; II бүлектә татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре, ягъни мирасыбызны кайтару, имза, псевдонимнарны ачыклау, гомумән, татар текстологиясенең торышын яктырткан мәкаләләр; III бүлектә XX йөз башы татар әдипләре әсәрләренең текстларын әзерләү һәм бастырып чыгару мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр; IV бүлектә галимнең үз замандашлары, хезмәттәш дуслары хакындагы истәлекләре; V бүлектә рецензияләр, якташларына һәм туган авылына багышланган язмалар урын алган.

Җыентыкның Тукайга багышланган бүлегенә киңрәк тукталып үтәсе килә. Тукай темасы – галимнең фәнни хезмәт юлында аеруча зур урын алып торган өлкә. Шуңа күрә дә, беренче бүлеккә урнаштырылган, беренчел чыганакларга нигезләнеп эшләнгән мәкаләләр аеруча кызыклы һәм мәгълүматка бай. «Басмаларга кертелергә тиеш» исемле мәкаләсендә Зөфәр Рәмиев моңа кадәр Тукайның күптомлыкларына кертелми калган ике мәкаләсе турында сүз алып бара. Аларның беренчесе, «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 27 нче (11 сентябрь) санында басылган Әхмәт Урманчиев һәм Габдулла Тукаевның Гаед бәйрәме белән котлау сүзләре. Галим моңа кадәр әлеге текстның Тукай күптомлыкларына кертелмәвен болай дип аңлата: «Моның өч сәбәбе булган булуы мөмкин: йә «Ялт-йолт» журналы буенча эзләнүләр үткәргәндә күзгә чалынмый үтелгән, йә текстның авторы икәү булу, йә, дини бәйрәм белән котлау. Укучылар сизенгәннәрдер: кот-

лау сүзен язуда Тукай кулы уйнаган.» Икенче мәкалә – Тукайның «Яшен ташлары» җыентыгына «Шүрәле» имзасы белән (Казан, «Мәгариф» матбагасы, 1912. Беренче җөзьә, икенче басма) кереш мәкалә итеп урнаштырылган «Бер лыгырдау» исемле язмасы. Шунысын да әйтергә кирәктер, Тукайның әлеге «Яшен ташлары» исемле җыентыгының беренче басмасы (1911) белән икенче басмасы (1912) – икесе ике җыентык һәм «Бер лыгырдау» исемле кереш мәкаләсе бары тик икенче басмасында гына урын алган.

Галим Тукайның күптомлыкларына ялгышлык белән башка авторларның әсәрләре урнаштырылу фактлары булуын да ачыклый. «Боларын Тукай язмаган» мәкаләсендә ул шундый ике очракны күрсәтеп уза. Аларның берсе – шагыйрьнең 1943 елгы «Академик басма»сының беренче томына ялгыш кертеп җибәрелгән Сәгыйть Сүнчәләйнең «*** ("Сөй гомерне, сөй халыкны...")» шигыре, икенчесе – биштомлыгының беренче томында «Тукайга нисбәт ителгән һәм өйрәнчек шигырьләр» дигән кушымтага урнаштырылган «Экспромт («Мин катам...»)» дүртьюллыгы.

Җыентык авторы Зөфәр Рәмиев Тукай турында замандашлары истәлекләрен барлау эшен дә дәвам итә. Мәсәлән, С. Сүнчәләйнең «Тукай бәйрәме» язмасы шагыйрь турында язылган истәлекләрне эченә алган өч җыентыкның берсенә дә кертелмәгән.

Вакытлы матбугат битләрендә басылган, Тукайга кагылышлы язмаларда киткән ялгыш фикерләрне дә күз уңыннан читтә калдырмый. Аларны вакытында дөресләп җибәрү максатыннан, хаталарны искәртеп язылган мәкаләләре дә бар. Мәсәлән, «"Әни" шигыренең "Әти"се кем?» мәкаләсе моңа мисал. Зөфәр Рәмиев, бүгенге көндә Габдулла Тукай әсәрләренең алты томлы академик басмасын әзерләүче төркемнең җитәкчесе. Һәм ул, томнарның фәнни мөхәррире буларак, томнарны төзү принциплары, проблемалары хакында фикерләрен матбугатта бастырып килде. Әлеге язмалар да әйтеп үтелгән китапның шактый өлешен алып тора. Шулай ук аның Тукай энциклопедиясен төзү төркеменең җитәкчесе буларак, энциклопедия язмышын кайгыртып язган мәкаләре дә, чит илләрдә һәм чит төбәкләрдә Тукайны өйрәнүнең торышы, Тукайны искә алу хакындагы язмалары да урнаштырылган ул китапка.

Китапның ахырында исемнәр күрсәткече бирелү җыентыкның кыйммәтен тагын да арттыра. Гадәттә исемнәр һәм атамалар күрсәткече язучыларыбызның күптомлыкларын әзерләгәндә генә эшләнә. Әлеге күрсәткечнең файдасы һичшиксез зур. Ул китаптан теге яки бу шәхес хакындагы мәгълүматны бик тиз табарга мөмкинлек бирә.

Китап – галимнәр, Тукай иҗаты белән кызыксынучылар, әдәбиятчы текстологлар өчен бик файдалы хезмәт. Киләчәк буын текстолог-галимнәренең ул өстәл китабы булыр, аларга көндәлек кулланма вазыйфасын үтәр дип ышанабыз.

***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы**, филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

# РЕЛИГИОЗНЫЙ СИНКРЕТИЗМ И ТРАДИЦИОНАЯ ОБРЯДНОСТЬ ТАТАР-КРЯШЕН ВОЛГО-УРАЛЬЯ (XIX – начало XX в.)

***Татар керәшеннәре тарихыннан***

Бүген христиан дине вәкилләре, еш кына, татар керәшеннәре мәнфәгатен яклыйбыз, дип чыгыш ясарга тартынмыйлар һәм аларны, беркайчан да мөселман булмаганнар, дигән тарихи «караш» пропагандалыйлар. Бу караш нигезлеме соң? Сорауга җавапны Ш. Мәрҗани исемен йөртүче Тарих институты хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән «Религиозный синкретизм и традиционная обрядность татар-кряшен Волго-Уралья (XIX – начало XX в.)» дигән, 2015 елда Казанда басылып чыккан тарихи документлар җыентыгыннан табарга була.

Әлбәттә бу темага кагылышлы тарихи хезмәтләр Казанда электән үк басылгалап килгәнен искәртергә кирәк. Мәсәлән, христиан миссионерлары Н.И. Ильминский (1822–1891), Е.А. Малов (1835–1918) кебек галим-тюркологлар христианлыкны кабул иткән татарлар өчен йөзләгән дин өйрәтүче китаплар һәм дәреслекләр бастырдылар. Аларның бер өлеш китаплары традиция буенча гарәп хәрефендә дә нәшер ителгәннәр. Ул китапларның бер әһәмиятле үзенчәлеге – аларның теле. Миссионерлар, башта ук, татар керәшеннәрен биздермәс өчен, аларга төбәлгән әдәбияттагы дини терминнарны ислам дине китапларыннан алганнар. Мәсәлән, Тәңре Бабай, Алла (30 б.), пәри (46 б.) һ.б.

Менә татар керәшеннәренең бер догасы «Эй Алла! Жаматыма-жарыма саулык бир, озон гюмер бир, тынычлык бир, ӓр тӧрлӧ жаманнан катярдян сакла» (58 б.). Бу җөмләдә Алла, жаматыма, жарым (фарсыча; татарча – яр, иптәш), гюмер (гарәпчә), ӓр (фарсыча; татарча – һәр), жаман – йаман (фарсы), катярдян (гарәпчә; татарча – хәтәрдән) дигән сүзләр бар. Әгәр татар керәшеннәре беркайчан да мөселман булмаган булсалар, алар телендә бу сүзләрнең саклануы икеле булыр иде. Әстерханда 1819 елда татар керәшеннәре өчен миссионерлар тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, гарәп графикасында басылган бу китаптагы гарәптән кергән дини терминнарның санын, кем дә булса санап карады микән? Әгәр алар элек ислам динен тотмаган булсалар, нигә алар арасында христиан динен сеңдерү өчен язылган басмалар бар да, 1860 елларга кадәр гарәп язуында басылганнар һәм ислам дине терминнары белән тутырылганнар соң?

Мөселман татарларны христиан диненә көчләп кертү тарихы турында галим А.Н. Григорьевның «Христианизация нерусских народностей, как один из методов национально-колониальной политики царизма в Татарии (с половины XVI в. до февраля 1917 г.)» дигән хезмәтеннән таныша аласыз.

Татарларны чукындыру идеяләре белән йөргән миссионер Е. Малов көндәлекләре дә бу темага бай фактик материал бирәләр. Керәшеннәр арасында махсус таратыла торган матбугатта чыккан тарихи чыганаклар текстларында борынгыдан килгән христианнар дигән сүзләрнең һичбер нигезе юк. Хәтта христиан динен тотучы татарлар арасыннан чыккан фәннәр кандидаты Максим Глухов та бу темага пропаганда алып барса да, халык аны кабул итмәде. Мәр-

хүм М. Глухов бу ялгыш фикерләрен үзе төзеп чыгарган «Татарика. Энциклопедия (Казань, 1997)» китабында игълан иткән иде.

Тарих институты фәнни хезмәткәрләре Х.З. Бәһаветдинова һәм Р.Р. Исхаков тарафыннан төзеп чыгарылган, алда искә алынган документлар җыентыгы татар керәшеннәренең тарихын дөрес күз алдына китерергә юнәлеш бирә. Бу җыентык архивлардан җыелган язма тарихи документлардан һәм вакытлы матбугатта басылган, шулай ук 1917 елгы инкыйлабка кадәрге кечкенә китапчыклардагы хезмәтләрдән гыйбарәт. Китап «2014–2020 елларда Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» программасы буенча бастырылган.

Татар керәшеннәренең татар милли-мәдәни традицияләрен һәм ислам кабул итүнең баштагы чорларына хас күренешләрне саклап, аларга табынуларын аларның нәкъ менә гомумтатар мәдәнияте традицияләрен саклавы итеп караулары бу хезмәт авторларының кыйбласы дөрес булуын раслый.

Мәсәлән, китап авторлары әлеге этник төркемдә исламның башлангыч чордагы формасы булып торган кирәмәтләрнең, мари, чувашларда гына түгел, христиан диненә күчкән татарларда да саклануы тарихи факт булып тора.

Китапның беренче бүлегендә тикшерелә торган «дини мифология һәм милли йолалар» сәхифәләре шушы юнәлешне тәфсилле тасвирлый.

Татар керәшеннәре, этнографик яссылыктан караганда, йорт корылмаларында, телдә, киемнәрдә, азык-төлек кулланууда мөселманнардан аерылмыйлар. Әмма христианлык кабул иткән татар ирләре, руслар кебек, чәчләрен озын итеп үстереп йөртәләр. Антропологик йөзләре дә мөселман динендәге татарлар кебек төрлечә: каратутлылар, ак йөзлеләр. Чәчләре дә төрле төстә. Физик күнекмәләрдә, эштә – тиңдәшләр.

Ләкин татар керәшеннәр христианлык кабул итсәләр дә, XIX йөзнең беренче яртысында да әле русча белмәгәннәр. Шул сәбәптән аларның «керәшенлеге» бик чамалы гына булган, чөнки чит дин нигезләре нигездә китаплап аркылы керәләр бит.

Татар керәшеннәренең хатын-кызлар киемнәрендә татарның урта гасырдан калган милли мәдәният реликтлары саклану, аларны XIX йөз татар мөселман хатын-кыз киемнәре фасоныннан нык аерган, чөнки беренчеләрнең киемнәрендә урта гасыр традицияләре сакланган, алар чуваш хатын-кыз киемнәренә якынрак.

Хезмәттә тасвирланган бу сәхифәләр авторлар тарафыннан язма документаль чыганаклар ярдәмендә ныгытыла. Татар керәшеннәрендә мөселманнар бәйрәмнәрен үткәрү традицияләре дә сакланган. Мәсәлән, бәйрәмнәрне авыл белән күмәкләп оештырганда аш өстәлләре өчен һәр хуҗалыктан он, сөт, май, йомырка җыеп, зәрә боткалары пешереп, уртак мәҗлесләрдә сыйланганнар. Мондый аш-боткаларны әзерләүдә татар мөселманнары традициясенә нигезләнгән. Аларны зур казаннарда пешергәннәр, соңыннан ат чабышлары уздырганнар һ.б.

Шулай ук татар мөселманнарының Тәңречелек замананарыннан ук килгән сабан (туй), корбан/хорбан бәйрәмнәре дә борынгыдан килгән бердәм милли традицияләр саклануына дәлил булып тора.

Татарның мөселман һәм христиан төркемнәрендә борынгы мифологик образлар XXI гасырга хәтле сакланып килә. Мәсәлән,

шүрәле, йорт ияләре, су ияләре, Тәңре бабай, шайтан, Аллаһ, абзар ияләре, урман ияләре, пәриләр, албастыларга ышану – бар да татар керәшеннәренең мөселман булган чактагы ышанулары икәне бәхәссез бер аксиома.

Китап авторлары бу мөһим мәдәни тормыш традицияләре турындагы мәгълүматларны татар керәшеннәрнең үз араларыннан чыккан каләм осталары М. Апаков, Б. Гарилов, Н. Одигитриевский, Е.А. Бектеева, Р. Даулей һ.б.ның этнографик хезмәтләренә таянып тасвир итәләр.

Хезмәтнең икенче бүлеге «Религия «откровения» в культурной традиции кряшен» дип атала. Бу бүлектә татар керәшеннәре арасына христианлыкны көчләп сеңдерү өчен миссионер Н.И. Ильминский өйрәткән ысуллар, Тимофей Тимей, Филипп Гаврилов һәм башкаларның әлеге татар авылларында йөреп, аларны өйрәнеп язган (XIX йөзләрдә һәр өяздәге татар керәшеннәре авылы җәмәгатьләреннән тупланган материаллар басылган).

Бу материаллар татарлар арасында рус миссионерлары һәм аларга зур теләктәшлек күрсәтеп ярдәм иткән Тимофей Тимей кебек имансызларның бик зур пропоганда алып баруын, ислам диненә каршы 1552 елдан бирле дәвам иткән агрессиянең тукталмавын дәлилли.

Китап бик уңышлы, логик эзлеклелектә язылган. Аның беренче һәм икенче өлешләре арасында тирән эзлеклелек барлыгын тоясың. Бу басма заманыбызның әлеге темага багышланган иң камил хезмәте булып саналырга лаек.

Материалларга исемнәр күрсәткече, территориаль-географик күрсәткечләр өстәлү басманың кыйммәтен тагын да күтәргән. Әлеге китапны татар керәшеннәре тарихына караган беренче махсус басма – документлар җыентыгы дип тә әйтергә мөмкин.

***Марсель Әхмәтҗанов,***
*филология фәннәре докторы,*
*профессор*

**2014 елның 16–17 декабрендә** Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында уздырылган Халыкара фәнни конференциядә «Россиядә һәм БДБ илләрендә сәнгать белеме үсешенең актуаль мәсьәләләре» каралды. Ул Казан сәнгать фәне өлкәсендә танылган белгеч, педагог, музей белгече, рәссам Петр Максимилианович Дульскийның (1879–1956) тууына 135 ел тулуга багышланган иде.

Конференциядә Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Молдовадан, Германия, Голландия, Польша, Төркиядән, Казакъстаннан белгечләр, галимнәр катнашты. Ә Россия вәкиллеген илнең төп сәнгать үзәкләре саналган Мәскәү белән Санкт-Петербургтан, Кабардино-Балкария, Калмыкия, Мари Эл, Чувашстан кебек милли республикалардан һәм Омск, Киров, Ярославль өлкәләреннән килгән кунаклар тәшкил итте.

Конференция эшендә катнашучы фәнни-тикшеренү учреждениеләре белгечләре, югары һәм махсус урта уку йортлары укытучылары, музей хезмәткәрләре сәнгать белеме теориясе һәм методологиясе, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать, театр, музыка һ.б. юнәлешләр буенча чыгышлар тыңладылар, алар буенча фикер алыштылар, киләчәккә үзара хезмәттәшлек юлларын билгеләделәр.

**Февраль аеның соңгы көннәрендә** язучы, әдәби тәнкыйтьче, Г. Ибраһимов исемендәге институтның текстология бүлеге мөдире М.Х. Вәлиев, Татарстан Язучылар союзы рәисе Р.Х. Корбан белән бергә, Алексеевский районы үзәгендә мәктәп укучыларының Әдәбият елына һәм Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган Республика конференциясендә катнашты һәм чыгыш ясады. Конференциягә Татарстанның төрле төбәкләреннән укытучылар һәм укучылар, район хакимияте һәм мәгариф бүлеге җитәкчеләре килгән иде.

**Март аенда** Алманиянең китапчылык башкаласы – Лейпциг шәһәрендә узган Халыкара ярминкәдә Казаннан «Мәгариф – Вакыт» нәшрияты да катнашып, Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТФАнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты грифы белән бастырган хезмәтләрне тәкъдим итте. Алар арасында И. Мегизерның «Төрки тел нигезләре» (латин, төрек, татар, рус телләрендә), «Без – бер тамырдан» (татар, төрек һәм рус телләрендә) дигән затлы китаплар бар. Төрле илләрдән килгән наширләр, Алмания Милли китапханәсе һәм Лейпциг мэриясе вәкилләре дә әлеге басмаларга зур кызыксыну күрсәттеләр һәм аларга югары бәя бирделәр.

XVII гасырдан ук оештырыла торган әлеге китап күргәзмәсе быел 251 мең кешене җыйган. «Вакыт – Мәгариф» нәшрияты стендыннан дүрт көн буе халык өзелмәгән. Берничә галим ул тәкъдим иткән басмаларны әзерләүче Институт белән хезмәттәшлек итәргә теләген белдергән һәм Казанда үз китабын бастыру мөмкинлеге белән кызыксынган.

**Март уртасында** Язучылар союзының Тукай клубында Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты Җ.Ш. Сөләймановның татар, рус һәм чуваш

телләрендә басылган «Вакыт касәсе» исемле өчтомлыгын тәкъдим итү булды. Анда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан М.Х. Вәлиев тә чыгыш ясады.

**2015 елның 10–12 февраль көннәрендә** Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты белән берлектә, «Идел буе халыкларының традицион мәдәнияте» дигән темага Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе уздырды.

Конференция кысаларында Идел буе халыкларының традицион мәдәниятенә, аерым алганда, төрки халыкларның традицион мәдәниятенең хәзерге хәле; кыр фольклористикасы; Идел буе халыкларының матди һәм рухи мәдәниятен өйрәнү; музыкаль фольклорның жанр типологиясе; халык бию сәнгатенә кагылышлы мәсьәләләр каралды. Пленар утырыштан соң конференция кунаклары эшләрен түбәндәге секцияләрдә дәвам иттеләр: «Идел буе халыкларының матди һәм рухи мәдәнияте», «Этномузыкология, этнохореология һәм фольклор башкару проблемалары», «Социаль мәдәни өлкәдә традицион мәдәниятне саклау һәм халыкка җиткерү мәсьәләләре», «Традицион мәдәниятне дисциплинаара аспекта тикшерү мәсьәләләре», «Этник тарих һәм төрки халыкларның традицион мәдәнияте».

http://www.tatfolk.ru/test/index.php?content=podr&id=480

**2015 елның 24–26 февраль көннәрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының йомгаклау конференциясе булып узды. Әлеге конференция Россиядә игълан ителгән Әдәбият елы ачылуга багышланды.

Конференциянең пленар утырышында Россиядә әдәбият елына багышланган чаралар циклы кысасында «Татар әдәбияты тарихы» басмасының 1 нче һәм 2 нче томнырын презентацияләү булды. Әлеге чара Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге вәкилләре һәм журнал-газета мөхәррирләре катнашында узды.

Конференциядә «Татарстан сәнгатенең тарихы һәм үсеш проблемалары»; «XIX гасыр прозасы. Бүгенге караш. (Муса Акъегетзадәнең тууына 150 ел булу уңаеннан)» (түгәрәк өстәл); «Чыганаклар белән эшләү һәм текстология мәсьәләләре»; «Әдәбият һәм фольклорда тәрҗемә мәсьәләләре»; «Иске татар чыганакларын һәм татар диалектларын өйрәнүнең методологик нигезе һәм актуаль проблемалары»; «Хәзерге татар әдәби тел нормаларын камилләштерү проблемалары»; «Татар теленең сүзлек составы: өйрәнү проблемалары һәм лексикографик тасвирланышы» дигән темалар буенча фикер алышулар оештырылды.

**2015 елның 26 февралендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан «Бүгенге көн контекстында татар иҗтимагый фикере мәсьәләләре» дигән тема буенча түгәрәк өстәл оештырылды. Әлеге чара мәшһүр татар галиме – Абдуллин Яхъя Габдулла улының тууына 95 ел тулуга багышланды. Я.Г. Абдуллин татар

иҗтимагый һәм фәлсәфи фикере тарихы фәнни юнәлешенә нигез сала; җәдитчелек кебек катлаулы татар иҗтимагый фикере күренешенә тарихи-фәлсәфи анализ ясый.

http://www.tataroved.ru/actions/kstolabdul/

**2015 елның 17–18 мартында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты «Алтын Урда һәм Алтын Урдадан соңгы пространство тарихы» буенча дүртенче Халыкара Алтын Урда форумы үткәрде. Әлеге форум кысаларында «Алтын Урда һәм төрки-татар ханлыклары тарихы чыганаклары: традиция һәм яңалыклар»; «Чыганакларны өйрәнү кысаларында Алтын Урдада һәм төрки-татар ханлыкларында акча әйләнеше мәсьәләләре» буенча ике конференция уздырылды.

http://www.tataroved.ru/actions/zforum4/

**2015 елның 25 мартында** Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге «Яшь фольклорчы мәктәбе» укулары үткәрде. Гадәттәгечә, март укулары «Кыр фольклористикасының актуаль мәсьәләләре» темасына багышланган иде. Аның программасына түбәндәге юнәлешләр кертелде: фольклорны комплекслы җыю мәсьәләләре; кыр фольклористикасы, диалектология һәм этнография: фәнни синтез мәсьәләләре; традицион мәдәнияткә кагылышлы материалларны җыю методикасы һәм программалары; кыр фольклористикасында картага төшерү проблемасы; кыр фольклористикасында мәдәни ландшафт мәсьәләләре; кыр фольклористикасында этнолингвистик метод; кыр фольклористикасын өйрәнү тарихы.

http://www.tatfolk.ru/test/index.php?content=podr&id=482

**2015 елның 31 мартында** Казан шәһәрендә «Урта һәм югары белем бирү системасында татарча укыту: тарих, бүгенге көн һәм киләчәк» дигән фәнни-гамәли конференция булып узды. Әлеге чара мәшһүр татар мәгърифәтчесе, галим, татар телендәге дәреслекләр авторы – К. Насыйриның (1825–1902) тууына 190 ел тулуга багышланды. Конференциядә түбәндәге мәсьәләләр каралды: К. Насыйриның фәнни-педагогик эшчәнлеге; К. Насыйриның татар телендә укыту һәм дәреслекләр төзү өлкәсендәге эшчәнлеге; бүгенге көндә татар телендә белем бирү; татар телендә мәктәп дәреслекләре төзү мәсьәләләре; туган телдә югары белем бирү: тарихы һәм бүгенге торышы; татар телен укытуның актуаль мәсьәләләре.

http://www.tataroved.ru/actions/konfNasyri/

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2015. № 1

Бизәлеш авторы
*Э. Бәшәрова*

Компьютерда биткә салучы
*Н.Абдуллина*

Басарга кул куелды: 12.03.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru